
Марк Твейн
Том Сойер
мажаралары
«Мәгариф» нәшрияты


Бөек пират
Томас Сойерның
хәзиналәр картасы
N
W
Z
O

«ДӨНЬЯ
КЛАССИКАСЫН
ТАТАРЧА УКЫЙБЫЗ»
сериясе



Mark Twain

Марк Твейн

Том Сойер маҗаралары

Роман



КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2003

Библиотека
Таткнигоиздата
№ 31481

УДК 821.111(73)-31-93
ББК 84(7)-44
Т30

Twain M.
The adventures of Tom Sawyer. The adventures of Huckleberry Finn.— Foreign Languages Publishing House: Moscow, 1960.

Инглизчәдән *Саимә Ибраһимова* тәрҗемәсе

Рәссамы *Наталья Граханцева*

Тәрҗемә итүдәге зур ярдәме өчен кызым Гөлнарга ихлас рәхмәтемне белдерәм.

Твейн Марк

Т30 Том Сойер мажаралары: Роман.— Казан: Мәгариф, 2003.— 271 б.
ISBN 5-7761-0753-9
Америка язучысы Марк Твейнның (1835—1910) күп кенә телләргә тәрҗемә ителгән «Том Сойер мажаралары»н бөтен балалар да бик яратып укый. Романның татар телендә чыккан әлеге басмасы безнең укучыларга да ошар дип өметләнәбез.

БЗ—10(69)—125—2003/2004

ISBN 5-7761-0753-9

© Татарчага тәрҗемә,
«Мәгариф» нәшрияты, 2003

Сүз башы

Китапта сурәтләнгән маҗараларның күбесе чынлыкта булган хәлләр; аларның бер-икесе үзем белән, калганнары сабакташларым белән булды. Һак Финн чыннан да дөньяда яшәгән бер малай. Шулай ук Том Сойер да. Әмма ул үзе аерым бер кеше булып яшәмәгән: Том Сойерда минем өч таныш малаемның сыйфаты берләштерелгән, бәс шулай икән — аның образы катлаулы бер архитектура конструкциясен хәтерләтә.

Монда өстән-өстән генә сурәтләнгән төрле сәер хорафатлар ул заманнарда балалар һәм Көнбатыштагы негрлар арасында чыннан да яшәп килгән. Сөйләнә торган әлеге хикәя дә моннан утыз-кырык еллар элек булган.

Гәрчә китабым бала-чага күңелен күрер өчен дип атап язылса да, аңардан өлкән яшьтәге ирләр һәм хатын-кызлар йөз чөерер дип уйламыйм, чөнки мин аларның үзләренең дә сабый чакта нинди булуларын, нинди хисләр кичерүләрен, ничек сөйләшүләрен, фикерләүләрен, ничек итеп төрле вакыйгаларга юлыгып торуларын исләренә төшереп алуны күңелле бер бурыч итеп санадым.

Автор
Һартфорд
1876







I бүлек

— Том!

Җавап юк.

— Том!

Җавап юк.

— Кая китеп олакты соң бу малай?.. Том!

Юк кына бит җавап бирүче!

Карчык күзлеген борын очына таба шудырып төшерде дә бүлмәне күзлеге өстеннән карарга тотынды, аннары аны маңгаена таба күтәреп, пыяла астыннан күз йөртеп алды. Бала-чага ише вак-төякне эзләгәндә аңа күзлек аша бик сирәк карарга туры килә, чөнки ул аны рәешкә генә кия һәм күзлекне ул кирәк булганга түгел, матурлык өчен генә алган иде. Күзлекнең аңа бөтенләй хаҗәте юк, пыяла аша карады ни дә, мич капкачы аша карады ни — аңа барыбер. Башта ул каушап калгандай булды һәм бик ачуланмыйча, шулай да, бүлмәдә качып утыручы берәр малай була калса дип, аңа ишетелерлек итеп әйтеп куйды:

— Эләкмәссең микән әле! Мин синең...

Карчык, әйтер сүзен әйтеп тә бетермәстән, иелде дә идән себерә торган щеткасы белән караватт астына тыгып болгарга тотынды, үзе исә әледән-әле туктап тын алды. Караватт астыннан песидән гайре бүтән нәрсә чыкмады.

— Гомеремдә мондый баланы күргәнем юк иде!



Карчык, шар ачык ишек төбенә килеп, чүп үлән баскан помидор бакчасына күз салды. Анда да юк иде Том. Шуннан соң ул тавышын күтәрә төшеп тагын бер тапкыр:

— То-о-ом! — дип кычкырды.

Аның артында җиңелчә генә кыштырдаган тавыш ишетелде. Карчык борылып кына карады да таярга җыенган малайның куртка итәгеннән эләктереп алды.

— Шулай булмыйни! Нишләп чоланнан карарга оныттым соң әле мин? Нишләдең син анда?

— Эшләмәдем.

— Шулайдыр шул! Күр әле ул кулларыңны! Авызыңа гына кара! Нәрсәгә буялды ул иреннәрең?

— Белмим, түткәй!

— Аның каравы мин беләм. Вареньега буялган ул, беләңме! Кырык тапкыр әйттем бит инде мин сиңа, кагылма вареньега, дидем, югыйсә тиреңне тунармын, дидем. Китер әле әнә шул чыбыкны!

Чыбык һава ярып «чыж» итеп куйды — аның сыртка килеп төшәчәге көн кебек ачык иде.

— Әй, түткәй, дим! Карагыз әле, ни ул анда?

Карчык коты алынып артына борылды, итәкләрен җыя төште, малай исә шул мәлдә томырылып читкә атылды һәм биек койма аша сикереп күздән дә юк булды. Ай күрде, кояш алды!

Полли түткәй бер мәлгә аптырап калды, аннары:

— Ах сине, малай актыгы! — дип, йомшак кына көлеп куйды.— Шуклыгына күптән күнегергә вакыт инде югыйсә. Ничә тапкыр түп башына утыртты инде ул мине! Бу юлы акыллырак булырга кирәк иде дә бит. Дөньяда карт юләрдән дә ахмаграк кеше юктыр шул.

Карт этне яңа һөнәргә өйрәтеп булмый дип юкка гына әйтмиләрдер, күрәсең. Хәер, бу малайның этлекләре дә төрледән-төрле бит: таң аттымы — яңа шуклык! Уенда ниләр барын каян белеп бетерәсең аның? Әйтерсең лә ул ничек итеп мине чыгырымнан чыгарырга икәнен дә, ничек итеп фикеремне чуалтып елмаерга мәҗбүр итәргә икәнен һәм шуннан соң кулларым хәлсезләнеп, аны чыбык белән яра алмас хәлгә килүемне дә белеп тора. Өстемә төшкән бурычымны үтәмим шул инде, анысы хак, анысы өчен мине Ходай үзе ярлыкасын. Баланы чыбыкламаган кеше аны боза гына, дип язылган бит изге китапта. Мин, гөнаһлы бәндә, иркәләп бозам шул инде малайны, моның өчен теге дөньяда эләгәчәк әле — миңа да, аның үзенә дә. Иблиснең иблисе бит ул, мин моны яхшы беләм, ләкин нишләмәк кирәк? Мәрхүм апамның улы бит, бичаракаем, шул ятимне кыйнарга ничек итеп кулым күтәрелсен? Тукмак төшүдән качарга ирек биргән саен әйтеп бетергесез дәрәҗәдә вөҗданым газаплана, кыйнадым исә — карт йөрәгем парә-парә килеп телгәләнә. Кешенең кып-кыска гомере дә кайгы-хәсрәт белән тулы, дип, дөрес язганнар китапта. Чыннан да шулай булып чыга бит! Мәктәпкә бармаячак ул бүген, кичкә хәтле эт сугарып йөриячәк, ә минем бурыч — аңа җәза бирү. Һәм мин ул бурычымны үтиячәкмен, әлбәттә,— иртәгә менә дигән эш кушам үзенә. Бу инде шәфкатьсезлек була булуын, ник дисәң — иртәгә балаларның бәйрәм көне, әмма башка чара юк. Аның дөньяда иң сөймәгәне — эш, әмма бу юлы малайга ирек куярга хакым юк, югыйсә ул тәмам юлдан язачак.

Том бүген, чыннан да, мәктәпкә бармады һәм вакытын бик тә күңелле үткәрде: Джим атлы негр малаена иртәгәге өчен утын кисешеп, чыра телешеп куярга өлгерерлек итеп кенә кичке ашка көчкә кайтып җитеште. Һәрхәлдә, Джим эшнең дүрттән өч өлешен башкарган арада ул үзенең күргән-белгәннәрен аңа сөйләргә өлгергән иде инде. Томның энесе Сид исә (бертуган энесе түгел, үги энесе) бу вакытта инде үзенә кушылган бөтен эшне бетергән иде (бөтен чыраларны җыештырып ташып куйган), чөнки ул сүз тыңлаучан малай, шаярмый-шукланмый, өлкәннәргә каршы сүз әйтми, аларга борчу китерми.

Том, кичке ашын тәмләп ашап, җае килгән саен шикәр савытыннан шикәр чәлдергән арада Полли түткәй аңа төрле хәйләкәр сораулар бирә торды, ул аны җәтмәгә эләктереп тел яздырырмын, дип өметләнде. Беркатлы кешеләрнең күбесе кебек, ул үзен бик оста дипломат дип уйлый һәм беркатлы ниятләрен искиткеч зирәклек дип саный иде.

— Том,— диде ул,— бүген мәктәптә бик эссе булмагандыр?

— Юк, түткәй.

— Әллә бик эссе идеме?

— Әйе, түткәй.

— Бер дә коенасың килмәдеме, Том?

Том нинди дер яманлык сизгәндәй булды — аның күңелен үзенә бертөрле шикләнү һәм курку хисе тырнап үтте. Ул, сагаеп, Полли түткәйнең йөзенә карап алды, ләкин аның йөзендә Томны шикләндерерлек нәрсә сизелми иде.

— Юк, түткәй,— дип җавап бирде Том,— коенасым килмәде...

Полли түткәй кулын сузып Томның күлмәген тотып карады.

— Тирләмәгәнсең дә хәтта,— диде ул.

Карчык үз-үзеннән бик канәгать булып уйлап куйды: менә ничек оста гына итеп ул Томның күлмәге юешме-түгелме икәнне ачыклый алды; аның күңеленә шундый хәйлә барлыгы беркемнең дә башына килмәде. Хәлбуки Том җилнең кая таба искәнен чамалап алды һәм яудырылачак сорауларга җавапны биреп тә куйды:

— Мәктәптә без малайлар белән башыбызны кое суына чылаттык. Әнә күрәсезме, чәчләрем әле хәзер дә кипмәгән.

Полли түткәйнең кәефе кырылды: ничек инде ул шундый әһәмиятле дәлилне кулдан ычкындырган! Ләкин шундук аның башына яңа фикер килде:

— Том, башыңны кое суына чылатканда син күлмәгеңнең якасын мин теген куйган җиреннән сүтеп алмагансыңдыр бит? Яле, ычкындыр әле куртканны!

Томның йөзе яктырып китте. Ул курткасын чишеп җибәрде. Күлмәкнең якасы шәп итеп теген куелган иде.

— Йә, ярар, ярар. Аңламассың сине. Мин сине мәктәпкә бармыйча

су коенып яткансыңдыр дип уйлаган идем. Ярар, ачуланмыйм үзеңне, шыр ялганчы булсаң да, алай ук юньсез малай түгел икәнсең әле.

Корган хәйләсенең барып чыкмавына ачуы килсә дә, Томның һич югында бу юлы тәүфыйклы малай булып калуына Полли түткәй күңеленнән сөенә иде. Әмма шул чакны сүзгә Сид килеп кушылды:

— Сез аның якасын ак җеп белән теккән идегез кебек, ә монда, күрәсезме, кара җеп белән тегелгән.

— Әйе шул, мин ак җеп белән теккән идем! Том!

Ләкин Том әңгәмәнең ахырын көтеп тормады. Бүлмәдән йөгереп чыгып китешли Сидка:

— Моның өчен кирәгеңне бирермен әле мин синең!..— диде.

Бер аулак урынга посып ул куртка якасы астына кадап куелган ике юан энәне капшап карады. Энәләрнең берсенә — ак, икенчесенә кара җеп сапланган иде.

— Сид әйтмәсә, түткәй искәрми дә иде аны. Их, хәерсез! Шуны бер теккәндә ак җеп белән тегә, икенчесендә — кара белән. Бер генә төрле җеп белән тегәргә ярамый торгандыр, күрәсең; ялгышмас җиреңнән ялгышырсың... Сидның арт сабагын укытам әле мин! Мәңге онытмаслык итәм әле.

Том, әлбәттә, бөтен шәһәр горурланырдай үрнәк малай түгел иде. Аның каравы ул кемнең үрнәк малай икәнен яхшы белә һәм аны бөтен күңеле белән күрәлмый иде.

Хәер, ике минуттан, бәлки әле тизрәктер дә, ул инде үзенең барлык кайгы-хәсрәтләрен оныткан иде. Зурлар тарыган көенечләргә караганда кайтышрак булганга түгел, ә бәлки күңелен тагын да куәтлерәк яңа бер мавыгу биләп алганга күрә онытты ул аларны. Өлкәннәр дә, берәр төрле яңа эшкә тотынганда мавыгып китеп, үзләренең борчуларын оныталар бит. Томның яңа мавыгуы — үзенә бертөрле итеп сызгыру осталыгына өйрәнү иде. Мондый сызгыруны ул бер таныш негрыннан отып алды. Ә хәзер шул яңалыкны аулакта гына кабатлап, яхшылабрак үзләштермәкче иде.

Негр кош сайраган кебек чут-чут итеп, өзеп-өзеп сызгыра иде. Шундый сызгыру килеп чыксын өчен телне әледән-әле аңкауга тидереп алырга кирәк. Әгәр укучы, малай кеше булып, үзенең бәләкәй

чакларын онытмаган булса, моның ничек эшләнгәнен хәтерли торгандыр. Үҗәтлеге һәм тырышлыгы Томга бу һөнәрне бик тиз үзләштерергә ярдәм итте. Ул башы күккә тияр дәй булып урам буйлап китте, авызы ләззәтле музыка белән, күңеле хозурлык белән тулды. Том үзен яңа планета ачкан астроном кебек хис итте, тик аның сөенүе самимирәк, тирәнрәк, тулырак иде.

Җәйге кичләр озын була. Көн әле һаман якты иде. Кинәт Том сызгыруыннан туктады. Аның каршысында үзеннән бераз гына калкурак буйлы таныш булмаган бер малай басып тора иде. Бу Сент-Питерсберг дигән шәһәр аламасында һәрбер ят кеше, ничә яшьтә һәм нинди җенестән булуына карамастан, яңалык исәпләнә иде. Җитмәсә тагын бу малай менә дигән костюм кигән, гап-гади эш көнендә бәйрәмчә киенгән! Исең китмәслек тә түгел шул! Башында — менә дигән эшләпә; өстендә — пөхтә итеп төймәләнгән өр-яңа, чип-чиста зәңгәр сукно куртка белән шундый ук чалбар. Әле бүген җомга көн генә булуга карамастан, аягына да бәйрәмчә башмак кигән. Аның хәтта галстугы да бар — муенына чуп-чуар тасма таккан. Гомумән, ул бик купшы киенгән кала көязен хәтерләтә һәм шуның белән Томның җен ачуларын китерә иде. Шушы ташкурчакка озаклап карап торган саен Томга үзенең костюмы бик мескен булып күренә барды, әмма ул сер бирергә теләмәде, борынын күтәрәрәк төште. Малайларның икесе дә авызларына су капкандай беравык тын тордылар. Берсе алай-болай кымшанып куйды исә, икенчесе шундук янтаеп калырга тырышты. Әнә шулай йөзне-йөзгә, күзне-күзгә терәп, алар озак кына дәшми тордылар. Ниһаять, Том теген ә:

— Измәңне изимме? — диде.

— Кагылып кара! — диде малай.

— Әллә кагылмас дисеңме?

— Кагыла алмыйсың шул!

— Әгәр теләсәмме?!

— Булмый!

Авыр тынлык урнашты. Аннары Том сүзен болай дип дәвам иттерде:

— Исемең ничек?

— Минем исемемдә синең ни эшең бар?
— Ни эшем булганын күрсәтермен мин сиңа!
— Йә, күрсәт! Ник күрсәтмисең?
— Тагын бер генә сүз әйтеп кара!
— Бер сүз! Ике сүз! Булдымы? Йә!
— Кара ничек кылтайган була! Теләсәм сыңар кул белән дә җиңәм бит мин сине. Икенче кулымны ник шунда бәйләп куймыйлар.
— Ник җиңмисең соң? Сөйләнгән буласың тагы!
— Күп бәйләнсәң кирәгеңне аласың бит!
— Һи! Синең ишеләрне генә күргән бар инде!
— Киендем-ясандым дигәч тә, кирәкле кишер яфрагы дип белдеңме әллә үзеңне? Эшләпәсен генә күр әле!
— Ошамыймы әллә? Ошамаса, бәреп төшер! Башың ике булса!
— Әллә куркып торыр дисеңме?
— Кагылып кына кара!
— Үзе куркыткан була, үзе шыр җибәрә!
— Әйдә бар, юлыңда бул, алдыңнан артың матур!
— Әй син, яхшы чакта телеңне тыймасаң башыңны сугып ярырга да күп сорамам!
— Ярганые ди берәү!
— Ярырмын шул!
— Нәрсә көтәсең соң? Үзең һаман янаган буласың, үзеңнең кулыңнан берни килми. Шүрлисеңме?
— Син йолкыштан да шүрләсәң!
— Шүрлисең шул!
— Исем китте ди менә!
— Шүрлисең!
Тагын тынлык урнашты. Малайлар, бер-берсен күзләре белән ашардай булып, урыннарында таптаналар, бер-берсен янбашлары белән эткәлиләр. Менә алар иңне иңгә куеп бастылар. Шуннан Том:
— Ычкын моннан! — диде.
— Үзең ычкын! — диде тегесе.
— Нишләп мин ычкынырга тиеш?

— Ә нишләп мин?

Алар йөзгә-йөз килеп, аяк терәп басып тора бирделәр. Аннары, бер-берсенә нәфрәт тулы караш ташлап, бар көчләренә этешергә тотындылар. Ләкин берсе дә җиңә алмады. Алар шулай кызарынып, кайнарланып озак кына этештеләр дә, ниһаять, ипләп кенә бер-берсеннән читенә төштеләр, шулай да һәрберсе элеккечә сагайган хәлдә кала бирде.

— Абыйга әйтеп дөмбәсләтәм әле мин синең ише куркак көчекне,— дип сүз башлады Том.— Ул сине чәнти бармагы белән дә борып ата ала.

— Курыкканнарые ди синең абыеңнан! Минем дә абый бар ул, синекеннән дә олырак, синең абыеңны ул әнә теге койма аша гына томыра. (Чынлыкта исә берсенең дә абыйсы юк.)

— Ышанырлар дисең инде, шыттыр әйдә!

— Бер дә шыттырмыйм!

Том аягының баш бармагы белән тузанга бер сызык сызды.

— Менә шушы сызыкның бу ягына чыкмыйсың! Шундый итеп измәңне изәрмен, гәүдәңне дә күтәрә алмассың! Чыгып кына кара!

Малай исә шундук сызыкны атлап чыкты.

— Яле, ничек итеп измәмне изәрсең икән?

— Этешмә дим сиңа, кирәгеңне бирәм югыйсә!

— Син бит кирәгемне бирәм дисең. Йә карап карыйк, нишләмәкче буласың икән?

— Ике цент бирсәң кыйныйм.

Малай кесәсеннән ике бакыр акча чыгарды да мыскыллап Томга сузды.

Том аның кулына сугып җибәрүгә бакыр тәңкәләр тәгәрәшеп җиргә барып төште. Сугыша торган мәчеләр сыман әләгешеп, малайлар тузан эчендә ауный башлады. Алар, берсен-берсе чәчләреннән тартып, киемнәреннән әләктереп, борыннарын тырнап, берсен-берсе тукмый-тукмый, үзләрен тузанга һәм данга күмделәр. Ниһаять, бу матавык басыла төште, һәм сугыш өермәсе эчендә Томның, малай өстенә атланып, дөмбәсләгәне күренде.

— Кичер мине, диген! — диде малайга Том.

Ләкин малай ычкынырга тырышып бәргәләнә һәм ачуыннан кычкырып елый башлады.

— Кичер мине, диген! — Том малайны яңадан дөмбәсләргә тотынды.

Ахыр чиктә малай мескен тавыш белән аны кичерүен үтенә.

— Сабак булсын,— ди Том, малайны кулыннан ычкындырып,— башка вакытта кемгә бәйләнергә икәнне белерсең.

Костюмыннан тузанын кага-кага малай китеп барды. Ара-тирә артына борылып карый-карый мышкылдап борынын тартты, «берәр туры китереп» Томның «кирәген бирергә» вәгъдә итте. Җиңүенә горурланып, малайдан көлә-көлә Том кайту ягына юнәлде. Ләкин ул борылуга теге малай аның артыннан таш тондырды. Таш Томның ике калак сөяге арасына килеп тиде. Малай исә кыр кәҗәседәй чабарга тотынды. Том хыянәтчене өенә хәтле куа барды һәм, шулай итеп, аның кайда яшәгәнен белде. Дошманын сугышка чакырып ул берникадәр вакыт аның капка төбендә таптанып торды, ләкин тегесе Томның чакыруына каршы тәрәзә аша гына маймылланды. Ниһаять, дошманының әнкәсе чыгып, Томны әшәке, бозык, тупас малай дип әрләде, аңа бу тирәдән табанын ялтыратырга кушты. Том китте, ләкин, туры китереп, малайның кирәген бирәчәген әйтте.

Өйгә Том бик соң кайтты һәм шыпырт кына тәрәзәдән кергәндә үзенең капкынга эләгүен аңлады: каршысында түткәе басып тора иде; Томның өс-башының ни кыяфәттә икәнен күргәч үк карчык «малайның шимбә ялын каторга хезмәтенә әйләндерергә кирәк», дигән катгый карарга килде.





II бүлек

Шимбә иртәсе җитте, җәйге дөньяда һәр нәрсәдән чисталык, сафлык аңкый, һәр тарафта тормыш кайный иде. Һәр йөрәктә җыр яңгырап тора, ә инде ул йөрәк яшь тә булса, җыр күңелдән тышка агыла. Һәркайсының йөзе шатлык белән балкый, һәркем дәртле итеп атлый. Ак чәчәккә күмелгән сәрви агачлары тирә-юньгә хуш ис тарата.

Һәр тарафтан күренеп торган Кардиф тавы яшеллеккә төренгән. Ул ерактан ук үзенә чакырып торган тынлык һәм тынычлык иле булып күренә.

Акшарлы чиләк белән озын саплы пумала күтәреп Том урамга чыкты һәм, күзе коймага төшүгә, малайның шатлык хисләре шундук очып юкка чыкты, аның урынына күңеленә кара сагыш кереп урнашты. Менә бу утыз ярдлы[1] такта койманың биеклеге тугыз фут[2] иде! Тормыш аңа коточкыч мәгънәсез һәм дөньяда яшәү гаҗәп авыр йөк булып тоела башлады. Ул тирән сулап пумаласын акшарга манып алды да койманың иң өстәге тактасын буяп куйды, аннары пумаласын тагын бер кат йөртеп чыкты да туктап калды: буяган тактаны буялмаган өлеше белән чагыштырып караганда эшләгән кадәресе бигрәк аз иде шул әле! Тәмам өметсезлеккә бирелеп, Том койма буенда үсеп утырган агач күләгәсенә килеп сөялде.

---

[1] *Ярд* — 91,4 см га тигез үлчәү берәмлеге.

[2] *Фут* — 30,48 см га тигез үлчәү берәмлеге.

Капкадан сикергәли-сикергәли Джим килеп чыкты. Кулында — су чиләге. Үзе борын эченнән генә «Буффало кызлары»н көйли. Шәһәр коесына суга баруны Том, гомумән, күңелсез шөгыльгә саный, ләкин шушы мизгелдә бу эшкә мөнәсәбәте башкачарак иде. Кое буена һәрвакыт күп кеше җыелганын исенә төшерде: ак тәнлеләр дисеңме, мулатлар, кара тәнлеләр дисеңме; чиратлары җиткәнне көтеп, малайлар-кызлар утырып ял итеп торалар, уенчыклар алмашалар, ачуланышып-үпкәләшеп тә, сугышып-шаярышып та алалар. Тагын ул шуны исенә төшерде: кое белән ике ара йөз илле адымнан артык булмаса да, Джимнең бервакытта да өйгә бер сәгатьсез әйләнеп кайтканы юк. Анда да әле артыннан эзли барырга туры килә.

— Карале, Джим,— диде Том,— мә, буйыйсың килсә койманы буйый тор, ә суга мин үзем барып килим.

Джим башын гына чайкады:

— Булмый, Том әфәнде,— диде ул.— Өлкән хуҗабикә миңа тиз генә барып кайтырга кушты, юлда беркем янында да туктап торма, диде. Ул әле миңа болай дип тә әйтте: «Мөгаен, Том әфәнде сине койма буярга чакырыр, син, кеше эшенә тыгылмыйча, үз эшеңдә бул,— диде.— Койма мәсьәләсен мин үзем кайгыртырмын», диде.

— Аның сүзенә карама син, Джим. Ни әйтмәс ул. Китер чиләгеңне, «ә» дигәнче барып кайтам үзем. Белми дә кала ул аны.

— Юк, куркам, Том әфәнде. Өлкән хуҗабикә моның өчен башымны бетерәчәк. Валлаһи дип әйтәм!

— Түткәйме? Кит аннан! Ул бит бервакытта да кыйнамый. Уймак белән маңгаеңа чиртсә генә инде! Сөйләнә генә бит ул. Ә сөйләнү ул синең бер җиреңне дә авырттырмый. Елап җибәрсә генә кызганыч була инде. Шарымны бирәм мин сиңа, Джим! Ак сызык төшкән алебастр шарымны!

Джим икеләнә калды.

— Ак сызыклы шар бит ул, Джим! Каян табасың син андыйны?

— Шулаен шулай да анысы! Хуҗабикәдән куркам шул, Том әфәнде...

— Күрәсең килсә, мин сиңа авырткан бармагымны да күрсәтәм.

Бары тик адәм баласы гына булганлыктан, Джим бу вәсвәсәгә бирелми кала алмады: чиләген җиргә куйды да ап-ак шарны кулына алды һәм, дөньясын онытып, Томның авырткан бармагын сүткәнне карап тора башлады. Икенче мизгелдә инде Джим, авырткан җирен уа-уа, чиләген шалтыр-шолтыр китереп урам буйлап чаба, Том тырышып-тырышып коймасын буый, кулына сыңар туфлиен тоткан Полли түткәй исә горур кыяфәт белән сугыш мәйданыннан китеп бара иде.

Ләкин Томның тырышлыгы күпкә бармады. Бүгенге көнен шундый күңелле итеп үткәрергә җыенган иде бит ул! Ә нәрсә килеп чыкты?! Тиздән бөтен малайлар урамга чыгар. Алар төрле уеннар уйнар һәм интегә-интегә койма буяган Томны мыскыллап көләр. Башына килгән шушы уйдан Том гарьләнеп үлә язды. Малай кесәсеннән бөтен булган байлыгын: уенчык ватыкларын, төрле шарларын һәм башка шуның ише юк-барын чыгарып салды; Томның исәбе — шушы юк-барны малайларга биреп, аларны койма буярга җигү иде. Ләкин ул белеп тора — мондый хакка гына алар алданмаячак. Шуңа күрә ул бар булган байлыгын кесәсенә кире тутырды.

Һәм менә шушындый өметсез бер мизгелдә Томның күңеленә илһам килде. Илһамның да нинди бит әле — менә дигән даһи фикер!

Ул пумаласын кулына алды да бик мавыккан кыяфәт белән эшкә тотынды. Күп тә үтмәстән урам чатында Бен Роджерс күренде. Томның иң курыкканы — шул малайның мыскыллавы иде. Йөгерә-атлый килүенә караганда, Бенның күңеле күтәренке, кәефе шәп булырга охшый: үзе алма ашый, үзе калын тавыш белән әледән-әле «дин-дон-дон, дин-дон-дон» дип сузып куя, янәсе, пароход булып кычкыра. Килеп җитәрәк ул тизлеген киметте һәм, урамның урта бер җирендә туктап, ашыкмыйча гына, эре кыяфәт белән борылырга тотынды: тугыз фут тирәнлектә «Олы Миссури» пароходының килүен күрсәтә, янәсе. Бер үк вакытта ул үзе пароход та, капитан да, сигнал бирә торган кыңгырау да иде. Янәсе, капитан күперчегенә менеп баскан да үзенә үзе команда бирә һәм шул команданы үзе үк үти дә.

— Тукта, машина! Тинь-линь-линь! — Машина туктады да, пароход салмак кына итеп тротуарга таба килде.— Артка чик!

Тинь-линь-линь! — Малай, ике кулын да төшереп, янбашына кысты.

— Артка чик! Рульне уңга! Тш-ш, тинь-линь-линь. Чшш-чшш-чшш!

Аның уң кулы мәһабәт хәрәкәтләр белән зур түгәрәкләр ясый: янәсе, ул кырык фут зурлыгындагы тәгәрмәч булып әйләнә иде.

— Рульне сулга! Тинь-линь-линь! Чшш! Чшш! Чшш! Хәзер инде ул сул кулы белән шундый ук түгәрәкләр ясый башлады.

— Тукта, уңъяк борт! Дилинь-динь-динь! Тукта, сулъяк борт! Алга һәм уңга! Тукта! Йөрешне әкренәйтергә! Динь-дилинь! Чу-у-у! Арканның очын ыргыт! Кайда арканыгыз, нәрсә мыштырдыйсыз? Субайга эләктер әйдә! Шулай, шулай, хәзер ычкындыр! Машина туктады, әфәндем! Тинь-линь-линь! Шт-шт-шт! (Янәсе, пароход парын чыгара.)

Том, пароходка бөтенләй игътибар итмәстән, койма буявын дәвам итте. Бен аңа карап-карап торды да:

— Әһә! Эләктеңме,— диде,— арканлап алдылармы үзеңне?

Җавап бирүче булмады. Том буяган җиренә рәссам кыяфәтендә карап тора иде. Аннары ул иплəп кенә пумаласы белән тагын бер кат буяп җибәрде дә, үз эшенә соклангандай, читкәрәк китеп кабат коймасына текәлде. Бен да Томның янәшәсенә килеп басты. Бенның алма ашаганын күрүгә Томның авызыннан сулар килде, әмма ул, берни булмагандай, эшен дәвам иттерде.

— Нәрсә, агай-эне, эш куштылармени? — диде Бен. Том кинәт аңа таба борылды:

— Ә-ә, син мени әле бу, Бен! Күрми дә торам.

— Карале, мин су коеныргa төшәм... Әйдә, бергә төшәбезме? Хәер, синең эшең бар шул! Эшләү кызыграк, әлбәттә.

Том текәлеп аңа карап торды.

— Нәрсәне эш дисең син?

— Ә бу, синеңчә, эш түгелмени?

Том яңадан коймасын буярга тотынды һәм илтифатсыз гына:

— Әллә эш, әллә түгел, кемгә ничек бит. Әмма Том Сойер аны бик тә яратып башкара,— дип җавап бирде.

— Сөйләмә юкны! Күңеленә хуш килә дип әйтүең түгелдер бит?

Пумала койма өсләтеп арлы-бирле йөрүендә булды.

— Ә нишләп ошамаска тиеш әле ул? Теләсә нинди малайга койма буяу эләгә дисеңме әллә?

Эш гел икенче юнәлеш ала башлады. Бен алма ашавын да онытты. Том, рәссамнарча ләззәтләнеп, пумаласын бер алга, бер артка таба шудырды, берничә адым читкә китеп үзенең эшенә сокланып карап торды, әле тегә, әле бу җирен төзәткәләп куйды, эшенә яңадан тәнкыйть күзе белән карады. Бен исә аның һәр хәрәкәтен күзәтте, һәм Томның койма буявы аңа бик мавыктыргыч булып тоела башлады. Кинәт ул:

— Бир әле, Том, мин дә буяп карыйм әзрәк,— дип куйды.

Том уйга калгандай булды, инде ризалашам дигәндә генә кире уйлады:

— Юк, Бен, буята алмыйм. Полли түткәй бу койманы бик шәп итеп буярга кушты: ул бит урам якка карый. Ишегалдына карый торган ягы булса бер хәл иде әле, ә бу якны бик тә, бик тә тырышып буярга кирәк шул. Мең малайдан... юк, ике мең малайдан берсе буйый алыр, алса...

— Нишләп алай булсын?! Йә инде, буяп кына карыйм инде... Әз генә... Синең урында булсам, мин уйлап та тормас идем. Ә, Том?

— Мин буятыр идем дә, Полли түткәй нишләтер соң? Бая Джим дә буяп карамакчы иде, түткәй рөхсәт итмәде. Сид та бик кызыккан иде — аңа да рөхсәт булмады. Беләеңме инде хәзер ни өчен буятмаганымны? Буйый башларсың да берәр җирен бозып куярсың...

— Нишләп бозыйм ди! Әйбәтләп буярмын. Алмамның яртысын биримме. Том?

— Бир әйдә. Ә юк, кирәкми, Бен. Куркам.

— Бөтенләе белән биримме соң?

Том теләр-теләмәс кенә пумаласын биргән сыман булып күренергә тырышты, ә күңеленнән ул бик шат иде. Әле генә «Олы Миззуэри» пароходы кыяфәтендә килгән Бен, эссе кояш кызуында шабыр

тиргә батып, койма буяган арада мәшһүр рәссамыбыз мичкә өстендә күләгәдә аякларын селки-селки алма кимереп утырды, тагын кемнәрне җәтмәгә эләктерергә икән дип хәйлә корды. Ачыкавызлар җитәрлек иде — малай-шалай койма буена җыела торды: мыскыллап көләргә дип килгән берсе койма буяучы булып кала барды. Бен арыгач чиратны Том өр-яңа очыргыч бәрабәренә Билли Фишерга сатты; Фишер да хәлдән тайгач, аны Джонни Миллер алыштырды. Моның өчен ул Томга озын бау очына тагылган күсе үләксәсе бирде — һәм башкалар, һәм башкалар, сәгать саен шундыйрак маллар ява торды. Көн урталары җиткәндә инде Том бичара хәерчедән черегән байга әйләнде. Әле санап үтелгән хәзинәдән кала аның тагын унике шары, ватык авыз гармуны, күзгә куеп кояшка карый торган зәңгәр пыяла ватыгы, буш кәтүге, берни ачарга ярамый торган ачкычы, акбур кисәге, бәллүр графин бөкесе, кургашын солдаты, ике чукмарбашы, алты шапылдавыгы, сыңар күзле песи баласы, бакыр ишек тоткасы, этка кигерә торган муенчак, пәке сабы, дүрт кисәк әфлисун кабыгы һәм какшап беткән ватык тәрәзә рамы бар иде.

Том берни эшләмичә, иптәшләре белән уйнап-көлеп, бик күңелле итеп вакытын үткәрде, шул арада аның коймасы да өч кат буялган иде инде. Әгәр дә Томның акшары бетеп китмәсә, шәһәрдәге бөтен малайларны ул бөлдереп бетергән булыр иде.

Болай булса, дөньяда яшәүнең яме бөтенләй үк юк түгел икән әле, дип уйлады Том. Үзе дә искәрмәстән, ул кешеләрне билгеле бер гамәл үтәргә мәҗбүр итә торган бөек закон ачты: әгәр дә теге яки бу кеше яисә берәр малай-шалай нәрсәгә булса да ирешергә тели икән, ул аңа ансат кына ирешә алмаска тиеш. Әгәр дә Том, шушы китапның авторы шикелле үк, зирәк акыллы бөек фикер иясе булса, шундый нәтиҗә ясаган булыр иде: эш дигән нәрсәне без үтәргә мәҗбүрбез, ә уенны үтәү мәҗбүри түгел. Бу аңа кәгазь чәчәкләр ясауның яисә иләк белән су ташуның — эш икәнен, ә шар сугуның яисә Монблан түбәсенә менүнең күңел ачу икәнен аңларга ярдәм итәр иде. Англиядә шундый байлар бар: эссе җәй көннәрендә алар омнибуска дүртәрләп җигелгән атлар белән идарә итүдән тәм табалар,

моның өчен алар хәтта коточкыч күп акчалар да түлиләр, ә менә шушы бик үк җиңел булмаган шөгыль өчен аларга эш хакы тәкъдим итсәләр, әлеге күңел ачу эшкә әйләнер һәм аның бер кызыгы да калмас иде.

Тормышында килеп туган үзгәреш турында уйланып Том беравык урыныннан кузгала алмый утырды, аннары эшнең бетүе хакында рапорт бирергә дип төп штабка таба юнәлде.



III бүлек

Том ачык тәрәзә каршында утыручы Полли түткәе бүлмәсенә кайтып керде. Бу бүлмә кирәк чакта йокы бүлмәсе, кирәксә кунак бүлмәсе дә, аш бүлмәсе дә яисә эш бүлмәсе дә булып хезмәт итә иде.

Җәйге рәхәт һава, борчусыз тынлык, чәчәкләрнең хуш исе һәм бал кортларының йокымсырата торган безелдәве карчыкка нык тәэсир иткән: бәйләмен кулына тоткан килеш ул каныгып утыра; бердәнбер гәптәше булган мәчесе дә аның алдына кереп яткан да мерләп йокыга киткән. Төшеп-нитеп ватылмасын дип карчык күзлеген маңгаена менгезеп куйган.

Томны ул әллә кайчан эшен ташлап качкандыр инде дип уйлый иде, шунлыктан малайның үз аягы белән җәза эзләп кайтып керүенә бик тә гаҗәпләнде.

Килеп керүгә үк Том:

— Хәзер уйнарга чыгарга ярыймы инде, түткәй? — дип сорады.

— Ничек? Хәзер үкме? Эшеңнең күпмесен эшләдең соң әле?

— Эшләп бетердем инде.

— Алдашма, Том. Алдашкан кешене җенем сөйми.

— Алдашмыйм, түткәй. Бетердем дим бит инде.

Полли түткәйнең сүзгә генә ышанмый торган гадәте бар иде. Шул арада ул эшнең беткәнме-бетмәгәнме икәнен үз күзе белән күрергә дип чыгып та китте. Том әйткәннең чиреге генә дөрескә чыкса да, ул бик шат буласы иде, әлбәттә. Койма баштанаяк буялу

гына түгел, ике-өч кат акшарланып, җиргә дә ак сызык сызылып куелганын күргәч, Полли түткәйнең исе китте.

— Менә бит, теләсәң эшли аласың син, Том,— диде ул. Шунда ук, артыгын мактамас өчен, өстәп тә куйды:

— Мондый хәлнең сирәк булуы гына бик кызганыч. Анысын да әйтми булмый. Ярар, бар инде, чык уйнарга. Тик кара аны, өйгә быел кайтасы икәнне онытма. Югыйсә күп сорап тормам.

Томның эшләгән эшенә Полли түткәй шулкадәр таңга калды ки, ул хәтта чоланга ияртеп чыгып,Томга, иң матур алманы сайлап бирде; үзе шул арада хәләл хезмәт куеп алган әйбернең ничек кадерле, татлы булуы турында бер гыйбрәтле вәгазь дә сөйләп ташлады.

Полли түткәй, инҗилнең бер бик җайлы өзеген әйтеп нотыгын тәмамлаган арада Том прәннек чәлдерергә өлгерде.

Ишегалдына чыгышлый ул Сидны күреп алды. Сид икенче каттагы арткы бүлмәләргә алып менә торган баскычтан атлый иде. Том җирдән балчык кисәкләре алып Сид өстенә яудырырга тотынды. Аптырап калган Полли түткәй аңышып ярдәмгә килеп җиткәләгәнче биш-алты кантар Сидның сыртына барып та тиде. Ул арада Том, коймa аркылы сикереп төшеп, күздән югалды. Ишегалдыннан чыгам дигән кешегә кече капка да бар

иде югыйсә, тик аңа барып җитәр өчен вакыты кирәк бит әле аның! Кара җеп мәсьәләсендә Полли түткәйгә әләкләшкәне өчен Сидтан үч алгач, Томның күңеле тынычланып калды.

Том, үзләренең кварталыннан чыгып, Полли түткәйнең сыер абзары буеннан караңгы тыкрыкка таба борылды. Хәзер инде аңа тотып алып җәза бирерләр дип куркасы юк иде. Ул, алдан сөйләшенү буенча, кара-каршы килеп сугышыр өчен ике гаскәр тезелгән җиргә — шәһәр мәйданына таба китте. Әлеге гаскәрнең берсенә — Том, икенчесенә аның җан дусты Джо Һарпер командалык итә иде. Бу ике бөек полководец шәхсән бер-берсе белән көрәшеп вакланмый; андый нәрсә вак-төяк халыкка гына килешә бит ул; сугыш хәрәкәтләре белән болар калкулык өстенә янәшә утырып адъютантлары аша боерык биреп кенә җитәкчелек итәләр иде. Озакка сузылган каты сугышлардан соң Томның гаскәре зур җиңүгә ирешәте. Ике гаскәр дә үлгән кешеләрен исәпкә алды, әсирләрен алмашты, аннары киләсе сугышның ни сәбәпле буласы, кайчан игълан ителәсе ачыкланды һәм хәлиткеч көрәшнең ни көнне башланачагы билгеләнде. Шуннан соң гаскәрнең икесе дә, сафларга тезелеп, тантаналы марш атлап сугыш кырыннан китеп барды. Том исә, берьялгызы гына калып, өенә кайтырга чыкты.

Джеф Тэтчерлар өе яныннан узганда ул аларның бакчасында таныш булмаган бер кыз күрде. Өстенә җәйге ак күлмәк, чигелгән панталон кигән зәңгәр күзле бу гүзәл зат алтынсу төстәге озын чәчен ике толым итеп үреп салган. Данга күмелеп сугыш кырыннан кайтып килүче баһадир һич тә каршылык күрсәтмичә шундук күңеле белән әсир төште. Эмми Лоуренс исемле кыз, шул минутта ук онытылып, аның йөрәгеннән юкка чыкты. Югыйсә Том үзе Эмми Лоуренсны өзелеп сөям, дип, хыялланып йөри иде! Ул нибары узгынчы гыйшык кына булган икән. Малай айлар буена кызда мәхәббәт уятырга тырышып йөрде. Нибары бер атна элек кенә әлеге кыз аны сөюе турында әйткән иде. Шушы кыска гына җиде көн эчендә Том үзен дөньяда иң бәхетле малай санап йөрде, һәм менә бер мизгел эчендә шул кыз, кыска вакытка килгән очраклы кунак сыман, тиз генә аның күңеленнән юкка чыкты да куйды.

Том үтә дә бер диндарлык белән, урлап кына әлеге яңа фәрештәгә исе китеп карап торды. Фәрештә дә аны искәреп алгач, малай күрмәмешкә салышты, кызга ошар, аны шаккатырыр өчен төрлечә маймылланырга, якланырга тотынды. Шактый вакыт Том һәртөрле мәзәкләрен күрсәтеп маташты. Кинәт, хәвефле бер акробатик трюк ясап азапланганда, кызның өйләренә таба китеп барганын шәйләп алды. Том сөмсере коелып коймага сөялде; аның тагын беразга гына булса да кызны бакчада тоткарлыйсы килде... Кыз чыннан да беравык баскычта басып торды, ләкин шундук туптуры ишеккә таба юнәлде. Кыз тупсаны атлагач, Том авыр сулап куйды, ләкин шундук аның йөзе яктырып китте: ишектән кереп югалганчы кызый аңа таба борылды да койма аркылы миләүшә чәчкәсе ыргытты.



Чәчкә янына җитәргә бер-ике адым кала Том тукталды, аннары, кулын каш өстенә куеп, каядыр еракка текәлеп карап торды, әйтерсең лә урамның икенче башында нindidер бик кызык тамаша күрсәтәләр иде. Аннары җирдән бер салам кисәге алды һәм, башын артка ташлап, шуны борын өстенә бастырып куярга маташты. Әкренләп ул чәчкә янына якынайды һәм сыгылмалы бармаклары белән чәчкәне эләктереп алды. Шуннан, сыңар аяклап титаклый-титаклый, урам чатына таба китеп югалды. Том, курткасын ычкындырып, чәчкәсен куенына, әллә йөрәге әллә ашказаны янына (анатомия белән аның алыш-биреше чамалырак иде һәм мондый нәрсәләрне ул бик үк аера алмый иде) яшергәнче бер генә мизгелгә юк булып торды.

Аннары Том әлеге кызларның коймасы буена яңадан әйләнеп килде, маймылланып, төрлечә кыланып кичкә хәтле шунда буталды. Ләкин кыз башка күренмәде. Том исә, бәлки ул тәрәзәдән килеп карыйдыр, аның газапларын күрәдер, дип уйлап үзен үзе юатты. Ахыр чиктә малай, төрле хыялларга чумып, теләр-теләмәс кенә өенә юнәлде.

Кичке аш вакытында Том бөтенләй алып узды, хәтта ки Полли түткәй дә, ни булган бу балага дип, аптырашка калып утырды.

Сидның өстенә балчык яудырганы өчен аңа шактый гына эләкте эләгүен, ләкин моңа Томның тамчы да исе китмәде. Тутасының борын төбеннән үк диярлек шикәр чәлдерергә маташканы өчен аның кулына суктылар, ул моңа да үпкәләмәде, бары тик:

— Түткәй, шикәр урлаган өчен сез бит Сидны кыйнамыйсыз,— дип кенә куйды.

— Синең кебек кеше интектерми бит ул. Карап тормасаң син бер дә шикәр савытыннан чыкмас идең югыйсә.

Менә Полли түткәй кухняга чыгып китте, ә Сид, җәзаламауларына иреп, Томны мыскыл иткән сыман, шикәр савытын шундук үзенә таба тартты. Хәттин ашкан оятсызлык иде бу! Шикәр савыты исә Сидның кулыннан ычкынып китте дә идәнгә төшеп челпәрәмә килде. Том моңа шулкадәр сөенде, шатлыгыннан кычкырып җибәрәсе урында бер генә сүз дә әйтмәде, телен тыйды. Том шундый карарга килде: Полли түткәй әйләнеп кергәч тә ул дәшмәячәк, кем эше бу дип сораганчы шым гына утырачак. Ә сорагач инде ул әйтеп бирәчәк һәм «сөйкемле сөяккә» ничек эләгәсен шатланып карап торачак. Шуннан да рәхәтрәк нәрсә бармы соң бу дөньяда! Томның ачуы шулкадәр ташыган иде ки, хәтта тутасы әйләнеп кергәч тә ул көчкә генә тыелып утырды. Ә Полли түткәй, күзлек өстеннән шикәр савытының кыйпылчыкларына карап, ачудан гайрәт чәчте. Том эчтән генә тынып: «Менә әйтәм, хәзер әйтәм!» дип ашкынып утырды. Әмма икенче мизгелдә инде идәнгә әйләнеп барып төште! Көчле кул Томга тагын сугарга дип күтәрелүгә малай елый-елый:

— Туктагыз әле, туктагыз! Нишләп сез мине кыйныйсыз? Аны бит Сид ватты! — дип кычкырды.

Полли түткәй уңайсызланып туктап калды. Том аны, кызганыр һәм шуның белән гаебен йолар, дип көтте. Ләкин Полли түткәй, телгә килүгә:

— Һм! Шулай да мин сиңа юкка эләкте дип уйламыйм. Мин юкта барыбер нинди дә булса этлек эшләгәнсеңдер әле,— дип кенә куйды.

Әмма Полли түткәйнең вөҗданына көч килде, ахрысы, малайга ул нинди дә булса җылы сүз әйтергә теләде, ләкин курыкты: әгәр

дә аңа ягымлы сүз әйтсә, Томның, түткәй үз гаебен таныды, дип уйлавы бар, ә мондый эшне китап кушмый иде. Шулай итеп, Полли түткәй бер сүз дә әйтмәде һәм, күңеле газапланса да, үзенең гадәттәге эшенә тотынды. Том исә бер почмакта үпкәләп, ярсып утырды. Тутасының инде, күңеленнән генә, аның алдына тезләнгәнен аңлый иде малай, һәм шуны белү Томга җиңеллек китерә иде. Ул мондый нәтиҗәгә килде: тутасының куштанланырга маташуларын, вөҗдан газабы кичерүләрен күрмәмешкә салышырга кирәк... Полли түткәйнең вакыт-вакыт аның ягына таба моңаеп карап алуларын, күзләренә яшь бөртекләре килүен Том белә, ләкин моңа берничек тә игътибар итәргә теләми. Ул үзен авыру итеп, үләргә җиткән хаста итеп күз алдына китерә, шунда, имеш, тутасы аның өстенә иелә дә, кичерсәң иде мине, дип ялвара, ләкин Том, гафу сүзен әйтмичә стенага таба борылып ята да үлеп китә, имеш; бик рәхәт булырмы әллә Полли түткәйгә шул чакта? Ул үзен үле хәлендә өйгә алып кайталар икән дип күз алдына китерә; аны әле генә су астыннан тартып чыгарганнар, имеш тә аның бөдрә чәчләре чыланган, күп газаплар чиккән йөрәге мәңгегә тынып калган. Шунда тутасы күз яшьләрен агыза-агыза аның мәете өстенә капланыр, Ходайдан Томны кайтаруын сорап ялварыр, ул аны яңадан бервакытта да нахакка рәнҗетмәскә сүз бирер, имеш! Әмма Том тәннәре суынган, йөзләре агарынган килеш бернинди җан әсәре булмаган хәлдә ята бирер. Бәхетсез сабый үлеп үзенең барлык җәфаларыннан котылган! Шушы кайгылы саташулар аның кәефен җибәрә, һәм ул тамагына килеп тыгылган күз яшьләрен йотып куя. Аның күзләренә яшь тыгыла, яшь тамчылары Томның яңакларыннан тәгәрәп төшә, борын очыннан тама. Шушы татлы сагышларыннан аңа искиткеч рәхәт иде, шуңа күрә ул күңеленә вак-төяк сөенечләр килеп керүенә юл куярга теләмәде. Һәртөрле хозурлык аны ярсытты гына — кайгысы аңа шундый да изге булып тоелды. Шуңа күрә, авылда озак торып, өйгә кайтып төшкәненә чиксез куанган туганнан туган апасы Мэри бии-бии бүлмәгә килеп кергәч тә Том урыныннан торды һәм күңелсезләнеп, кара коелып икенче ишектән чыгып китте.

Том, гадәттә, малайлар җыелышып уйный торган урамнарны әйләнеп узарга тырышып, үзенең кәефенә туры килгән аулаграк тыкрыклар буйлап йөрде. Яр буена килеп тукталган сал аңа иң уңайлы урын булып тоелды: сал читенә утырып елганың моңсу, талгын агымын тамаша кылды. Ә үзе тик бер генә нәрсә турында уйлады: аның җәфа чикмичә генә, минут эчендә сизмичә генә суга батып үләсе килә иде. Аннары ул баягы чәчкәсен исенә төшерде, аны куеныннан тартып алды,— ул инде шиңгән, таушалып беткән иде,— аның болай булуы малайның кайгысын тагын да көчәйтә төште. Томның күңелендә авыр хәсрәт барлыгын белсә, кыз аны кызганыр иде микән? Әллә елап ук җибәрер идеме, муеныннан кочып алып юатырга теләр идеме? Әллә шушы буш һәм салкын дөнья кебек ваемсыз кыяфәт белән йөз чөерер идеме? Шушындый уйлар аның күңелен биләп алды, шул уйларын ул әле тегеләй, әле болай әйләндереп уйлап карады. Ахыр чиктә Том, утырган җиреннән кузгалып китеп, караңгылык эченә кереп югалды.

Кичен, сәгать уннар тирәсендә, бушап калган урам буйлап ул баягы гүзәл кыз яши торган өйгә таба атлый иде. Өй турына килеп җиткәч ул бер мәлгә туктап колак салды: бернинди тавыш-тын ишетелмәде. Икенче каттагы тәрәзә пәрдәсенә тоник кына булып шәм яктысы төшкән иде... Аның күзгә күренми торган ят кызы шунда түгелдер бит? Том иплəп кенә койма аша сикереп төште дә, чәчәк түтәлләре яныннан үтеп, тәрәзә турысына килеп басты. Тәрәзәгә ул бик озак итеп әсәрләнеп карап торды, аннары чалкан китеп җиргә ятты да шиңеп беткән бичара чәчкәсен тоткан

килеш кулын күкрәгенә куйды. Менә шушылай гына итеп үлеп китсәң иде дә бит! Туң йөрәкләр дөньясында сыеныр урыны булмаган башкаен ул кая куярга да белми шул. Соңгы минутларында аның ирененә су тидерердәй, маңгаендагы әҗәл тирләрен сөртеп алырдай бер генә якын кешесе дә булмас. Иртәгә иртән шушы тәрәзә янына килеп, хозурланып таң атканын караганда кыз аны шушы хәлдә күрер, шулай ук Томның бичара гәүдәсе өстенә аның күзеннән бер генә тамчы да яшь таммас микәнни, шушы кадәр дә рәхимсезлек белән кыелган гүзәл яшь гомерне күргә аның авызыннан бер генә тапкыр да көрсенү авазы чыкмас микәнни?

Кинәт тәрәзә ачылып китте. Чәрелдәвек тавыш төнге тынлыкны бозды, һәм җан тәслим кылып ятучының өстенә шыбырдап югарыдан су коелды.

Аптыраган героебыз сукрана-сукрана яткан җиреннән сикереп торды һәм өс-башларын кагынды. Шул арада аңлашылыр-аңлашылмас кына итеп сүгенгән сүзләр ишетелгәндәй булды, һавадан нидер сызгырып үтте, чылтырап тәрәзә пыяласы коелып төште, һәм кечерәк кенә бер шәүлә, койма аркылы сикереп төшеп, караңгыга кереп юк булды.

Том, чишенеп, шәм яктысында кием-салымын караштырган арада Сид йокысыннан уянып китте; абыйсын шелтәләргә яисә битәрләргә исәбе булса да, кире уйлады, чөнки Томның күз карашы бернинди яхшылык та вәгъдә итми иде.

Дога укып мәшәкатьләнмичә генә Том йокларга ятты, Сид исә аның бу кимчелеген күңеленә беркетеп куйды.





IV бүлек

Кояш ваемсыз гына йоклап яткан җир өстенә күтәрелде дә, иминлек сөюче шәһәрнең бөтен кыласы эшләренә фатиха биргәндәй, аны якты нурларына коендырды. Иртәнге ашны ашаганнан соң гаиләсенең һәммә кешесен Полли түткәй гыйбадәт кылырга чакырды. Гыйбадәт кылу дога укудан башланып китте, ә дога исә Тәүраттан[1] алынган өземтәләргә Полли түткәйнең булыр-булмас аңлатмаларын китереп кушудан гыйбарәт иде; Синай[2] тау түбәсенә менеп баскан шикелле, әнә шул югарылыктан торып, Полли түткәй Муса пәйгамбәр канунының кырыс сүрәсен бәян итте.

Аннары Том, билләрен буып дигәндәй, эшкә тотынырга булды: Тәүраттан сүрәләр ятлый башлады. Сид ул дәресен әллә ничә көн элек үк өйрәнеп куйган иде инде. Ярты дистә сүрәне истә калдыру өчен Том җан көченә тырышты. Ул, бөтен Тәүратны актарып чыкканнан соң, иң кыска сүрәләрне Тау вәгазеннән сайлап алды. Ярты сәгать үтүгә ул сабагын элем-чалым гына хәтерли алды, чөнки күңеле белән әллә кайларда йөрде, ә куллары өзлексез хәрәкәтләнеп торды.

Дәресен әйттерергә дип, Мэри аның китабын алды. Том исә, сүрәләрне юньләп ятлый алмагайлыктан, адым саен төртелә башлады:

---

[1] *Тәүрат* — яһүдләрнең һәм христианнарның дини китабы.

[2] *Синай* — Сүәеш култыгы буендагы тау массивы; Библиядә сурәтләнгәнчә, борынгы яһүд пәйгамбәре Муса, имештер, Аллаһының ун канунын яһүдләргә шунда бәян иткән.

килеш кулын күкрәгенә куйды. Менә шушылай гына үтеп үлеп китсәң иде дә бит! Туң йөрәкләр дөньясында сыенырурыны булмаган башкаен ул кая куярга да белми шул. Соңгы минутларында аның ирененә су тидерердәй, маңгаендагы әҗәл тирләрен сөртеп алырдай бер генә якын кешесе дә булмас. Иртәгә иртән шушы тәрәзә янына килеп, хозурланып таң атканын караганда кыз аны шушы хәлдә күрер, шулай ук Томның бичара гәүдәсе өстенә аның күзеннән бер генә тамчы да яшь таммас микәнни, шушы кадәр дә рәхимсезлек белән кыелган гүзәл яшь гомерне күрүгә аның авызыннан бер генә тапкыр да көрсенү авазы чыкмас микәнни?

Кинәт тәрәзә ачылып китте. Чәрелдәвек тавыш төнге тынлыкны бозды, һәм җан тәслим кылып ятучының өстенә шыбырдап югарыдан су коелды.

Аптыраган героебыз сукрана-сукрана яткан җиреннән сикереп торды һәм өс-башларын кагынды. Шул арада аңлашылыр-аңлашылмас кына үтеп сүгенгән сүзләр ишетелгәндәй булды, һавадан нидер сызгырып үтте, чылтырап тәрәзә пыяласы коелып төште, һәм кечерәк кенә бер шәүлә, койма аркылы сикереп төшеп, караңгыга кереп юк булды.

Том, чишенеп, шәм яктысында кием-салымын караштырган арада Сид йокысыннан уянып китте; абыйсын шелтәләргә яисә битәрләргә исәбе булса да, кире уйлады, чөнки Томның күз карашы бернинди яхшылык та вәгъдә итми иде.

Дога укып мәшәкатьләнмичә генә Том йокларга ятты, Сид исә аның бу кимчелеген күңеленә беркетеп куйды.





IV бүлек

Кояш ваемсыз гына иоклап яткан җир өстенә күтәрелде дә, иминлек сөюче шәһәрнең бөтен кыласы эшләренә фатиха биргәндәй, аны якты нурларына коендырды. Иртәнге ашны ашаганнан соң гаиләсенең һәммә кешесен Полли түткәй гыйбадәт кылырга чакырды. Гыйбадәт кылу дога укудан башланып китте, ә дога исә Тәүраттан[1] алынган өземтәләргә Полли түткәйнең булыр-булмас аңлатмаларын китереп кушудан гыйбарәт иде; Синай[2] тау түбәсенә менеп баскан шикелле, әнә шул югарылыктан торып, Полли түткәй Муса пәйгамбәр канунының кырыс сүрәсен бәян итте.

Аннары Том, билләрен буып дигәндәй, эшкә тотынырга булды: Тәүраттан сүрәләр ятлый башлады. Сид ул дәресен әллә ничә көн элек үк өйрәнеп куйган иде инде. Ярты дистә сүрәне истә калдыру өчен Том җан көченә тырышты. Ул, бөтен Тәүратны актарып чыкканнан соң, иң кыска сүрәләрне Тау вәгазеннән сайлап алды. Ярты сәгать үтүгә ул сабагын элем-чалым гына хәтерли алды, чөнки күңеле белән әллә кайларда йөрде, ә куллары өзлексез хәрәкәтләнеп торды.

Дәресен әйттерергә дип, Мэри аның китабын алды. Том исә, сүрәләрне юньләп ятлый алмагайлыктан, адым саен төртелә башлады:

---

[1] *Тәүрат* — яһүдләрнең һәм христианнарның дини китабы.

[2] *Синай* — Сүәеш култыгы буендагы тау массивы; Библиядә сурәтләнгәнчә, борынгы яһүд пәйгамбәре Муса, имештер, Аллаһының ун канунын яһүдләргә шунда бәян иткән.

— Фәкыйрьләр... э-э-э...

— Рухи яктан...

— Әйе, рухи... Фәкыйрьләр рухи яктан... э-э-э...

— Бәхетлеләр.

— Фәкыйрьләр рухи яктан бәхетлеләр, чөнки аларны... чөнки алар...

— Чөнки аларны...

— Чөнки аларны... чөнки аларны... Нишләтәләр соң аларны? Үтерсәң дә белмим нишләткәннәрен! Нишләп әзрәк әйтеп җибәрмисең, Мэри? Ничек оялмыйча үртәп утырасың?

— Их, Том! Нишләп үртим ди инде мин сине! Ятла син сабагыңны башыннан ахырына кадәр. Шушы дәресеңне яхшылап өйрәнсәң, мин сиңа бик шәп бер әйбер бирәм.

— Ярар, ятлармын... Ни бирәсең, Мэри, әйт әле? Әйт инде...

— Ни булса да барыбер түгелмени? Әйттем бит инде шәп нәрсә дип. Шәп дигәч шәп инде!

— Алдамасыңны беләм инде мин синең, Мэри. Ярар, ятларга киттем!

Чыннан да, малай дәресен бик тырышып ятларга кереште: бер яктан, ни булып бетәсен беләсе килсә, икенче яктан, вәгъдә ителгән бүләк тә кызыктыра иде; һәм Том сабагын менә дигән итеп өйрәнде. Шуның өчен аңа Мэри унике ярым центлык ике яклы өр-яңа пәке бүләк итте; Томның куанычы эченә сыймады. Пәке әле бөтенләй үткенләнмәгән дә, аның каравы ул Барлоу фирмасы чыгарган чын пәке иде — аның кыйммәте дә нәкъ менә шунда инде! Көнбатыш штатларда яшәүче малайлар мондый пәкене рәтсез дип һәм аны үзең дә ясап була дип саныйлар. Каян килгәндер инде аларның башына мондый фикер,— бу, мөгаен, мәңгелек сер булып каладыр. Шулай да бүләк пәке белән Том бөтен буфетны юнгалап бетерде, инде комодка тотыныргга дип торганда аңа киенергә куштылар. Якшәмбе мәктәбенә барыр вакыт җиткән иде.

Мэри аңа ләгән белән су, кисәге белән сабын тоттырды; Том ишегалдына чыгып ләгәнне эскәмия өстенә куйды да сабынын суга манып алды, аннары, җиңен сызганып, ләгәннең суын ипләп

кенә җиргә түкте. Кухняга керәп, ишек артында эленеп торган сөлге белән тырышып-тырышып битен ышкырга тотынган иде, Мэри аның кулыннан сөлгесен тартып алды.

— Ничек оялмыйсың, Том! Әйбәтләп юын! — дип кычкырып җибәрде ул.— Юынганнан сиңа берәр зарар буламы әллә?!

Том уңайсызланып калды. Ләгәнгә яңадан су салдылар; бу юлы Том берникадәр вакыт ләгән өстендә кыюлыгын җыеп торгандай итте дә тирән сулыш алып юына башлады. Ул, күзләрен йомган хәлдә кухняга кабат кереп, капшанып сөлге эзләгәндә бите буйлап агып төшкән сабынлы су аның чыннан да бик тырышып юынган булуында шик калдырмый иде. Шулай да, сөлгесен битеннән алгач, аның бит очлары гына чистарган булып чыкты, бүтән җирләре юылмаган килеш калган иде. Мэри ныклап торып аны үзе юындырырга тотынды, шуннан соң инде малайның чырае ап-ак булып калды; юеш чәчләрен щетка белән шома итеп тарадылар, кыска бөдрәләрен типтигез итеп икегә аерып салдылар. (Том шундук бөдрәләрен шомартырга тотынды; моңарга ул шактый күп көч куйды; бөдрә чәч аны кызларга охшата дип уйлый иде ул һәм шуңа аның бик тә эче поша иде.) Аннары Мэри шкафтан аның костюмын алып бирде. Бу костюмын Том, менә ике ел инде, якшәмбе көннәрендә генә кия. Ул «теге костюм» дип кенә йөртелә, шуннан чыгып инде без аның киеменең күпме булуын күз алдына китерә алабыз. Том киенеп беткәч, Мэри аның өс-башын рәтләштерде, курткасының бөтен төймәләрен төймәләде, күлмәгенең киң якасын кайтарып куйды, башына бөрчекле салам эшләпәсен кидертте.

Хәзер Томның кыяфәте менә дигән югыйсә, ләкин ул чистарынып, матур киенеп йөрергә бер дә яратмый, мондый хәлдә аның тыны кысыла. Мэри башмакларны кигертергә онытыр дип уйлаган иде дә, әмма алай булып чыкмады. Әйбәтләп майлап, Мэри аның башмакларын кулына китереп тоттырды. Шунда ул, тәмам сабырлыгын җуеп, нишләп әле мине гел генә үзем теләмәгәнне эшләргә мәҗбүр итәләр, дип зарлана башлады. Ләкин Мэри аны иркәләп кенә үгетләргә тотынды:

— Йә инде, Том, киреләнмә инде!

Том мыгырдана-мыгырдана аягына башмакларын киде. Мэри үзе дә тиз генә киенде, һәм алар өчәүләп якшәмбе мәктәбенә киттеләр. Бу якшәмбе мәктәбен Томның җене сөйми, Сид белән Мэри исә анда бик яратып йөриләр иде.

Якшәмбе мәктәбендә тугыздан унберенче яртыга хәтле дәрес укыйлар, аннары вәгазь сөйләү башлана. Балаларның икесе вәгазь тыңларга үзләре теләп кала, Том да кала калуын, ләкин ул башка, хикмәтлерәк сәбәпләр аркасында тоткарлана иде.

Чиркәүдәге биек артлы агач эскәмияләргә өч йөзләп кеше утыра ала; чиркәү кечкенә, үзе бөтенләй бизәлмәгән, түбәсендә агач әрҗәгә охшаган тар гына манарасы да бар. Ишек төбенә килеп җитәрәк Том, бер дусты белән сөйләшеп алырга ниятләнеп, арткарак калды. Дусты да өстенә-башына матур итеп киенгән иде.

— Карале, Билли,— диде Том,— синең сары билетың бармы?

— Бар.

— Әйдә алышабыз.

— Ни бирәсең?

— Татлы тамыр белән кармак бирәм.

— Күрсәт.

Том әйберләрен күрсәтте. Дусты каршы килеп тормады, алар әйберләрен алмашып та куйдылар. Аннары Том ике ак шарын өч кызыл билетка алыштырды, шуннан соң җыен юк-бар нәрсәләрен биреп ике зәңгәр билет алды. Ул, чиркәүгә килгән малайларны саклап торып, алардан төрле төстәге билетлар сатып алды. Аннан үзе кебек үк пөхтә киенгән бала-чага белән бергә чиркәү

эченә керен, үз урынына барып утырды һәм шундук бер малай белән әрләшергә дә тотынды. Җитди кыяфәтле картрак бер укытучы аңа кисәтү ясады; укытучы икенче якка борылган арада Том алдагы рәттәге бер малайның чәченнән тартты да үзе, малай аңа таба борылган арада, башын иеп китабына текәлде. Берәр минуттан инде ул икенче бер малайның аркасына булавка белән төртте, чөнки малайның ничек итеп кычкырып җибәргәнен ишетәсе килә иде. Укытучы аңа тагын шелтә белдерде. Хәер, Томның бөтен классташлары бериш: җыенысы шаян, тынгысыз, тыңлаусыз иде. Малайлар дәрес әйтә башлагач, сүрәләрне берсенең дә юньләп белмәве ачыкланды, укытучыга гел әйтеп торырга туры килде. Әмма укучыларның һәрберсе, дәресне ничек кирәк шулай ерып чыгып, Тәүратның бер сүрәсе язылган зәңгәр билетны алырга тырыша, ә ул зәңгәр билетны алыр өчен Тәүратның ике сүрәсен яттан белергә кирәк. Ун зәңгәр билет бер кызыл билетка тора, аларны бер кызыл билетка алыштырырга да була. Ун кызыл билет исә бер сары билетка бәрабәр, ә инде ун сары билеты булган кешегә директор арзанлы Тәүрат китабы бүләк итә. (Ул чактагы бәя белән бу китап кырык цент тора.) Бүләккә Доре[1] рәсемнәре белән бизәлгән кыйбатлы Тәүрат китабы вәгъдә итсәләр дә, ике мең сүрә ятларга ничә укучының сабырлыгы җитәр иде икән? Ә менә Мэри, ике ел буена армый-талмый сүрә ятлап, бүләккә инде ике тапкыр Тәүрат китабы алды. Бер немец малае исә дүртнеме әллә бишнеме алган. Берсендә ул, тын да алмыйча, рәттән өч мең сүрә әйткән. Әмма бу кадәр тырышу аның баш миенә зәгыйфьлек китергән — шул көннән башлап малайның зиһене чуалган. Аның үзе өчен генә түгел, бөтен мәктәп өчен бик зур бәхетсезлек була бу — чөнки элек, тантаналы очракларда,

[1] *Доре Гюстав* (1833—1883) — француз рәссамы. Франсуа Рабленың «Гаргантюа һәм Пантагрюэл», Дантенең «Иләһи комедия», Сервантесның «Дон Кихот», Дж.Мильтонның «Югалган җәннәт» һәм дөнья әдәбиятының башка җәүһәрләренә, Библиягә ясаган иллюстрацияләре белән танылган рәссам.

халык җыелган чакларда, директор, гадәттә, (Том әйтмешли) «чүбек чәйнәргә» гел шушы малайны чыгара торган булган. Билетларны саклау әмәлен өлкән укучылар гына белә, һәм бүләккә Тәүрат алырлык итеп сүрә ятлауны да алар гына булдыра иде, шуңа күрә мондый бүләкне алу бик сирәк һәм онытылмаслык вакыйгага була торган иде. Рухи халәте ягыннан караганда Том бәлки бу бүләккә омтылырга тиеш тә булмагандыр, шулай да ул күптән инде Тәүратны алырга бик тә кызыга иде.

Билгеләнгән вакыты җиткәч, кулына гадәтенчә догалыгын тотып, директор кафедрага чыгып басты. Имән бармагын ул, битләрен аралау өчен, китап арасына кыстырган иде. Директор үзе сөйләгәнне бик игътибар белән тыңлауларын үтенде. Эстрада җырчысы кулына нота тотып сәхнәгә чыккан шикелле, кыска гына нотык сөйләргә кирәк булган саен якшәмбе мәктәбе директоры кулына догалык тотып чыга, ләкин моның нәрсә өчен кирәк булуын һич кенә дә аңлап булмый, чөнки бу ике мәхлукның берсе дә ни догалыгына, ни нотасына бервакытта да күз төшерми.

Директор кыска итеп алдырган җирән чәчле, кәҗә сакаллы, утыз биш яшьләрдәге сөйкемсез бер кеше иде; каты итеп крахмалланган якасының чите колагына ук терәлеп тора, ә якасының очы авыз читенә кадәр барып җитә. Бу яка аның башын койма ярыгына кереп кысылган кебек тота, ул алга таба гына карап торырга тиеш, читкә карыйсы булса ул бөтен гәүдәсе белән борылырга мәҗбүр иде; укытучының ияге киң чуклы галстугына терәлеп тора; ботинкасының башы, чаңгы очы кебек, югарыга караган,— бу мода ул вакыттагы яшьләр арасында киң таралган иде. Модага ияреп, алар ботинка башын сәгатьләр буена стенага терәп утыралар иде. Күрер күзгә Уолтерс әфәнде бик җитди күренә, әмма ул бик тә кече күңелле, ихлас кеше иде, изге дип исәпләнгән һәр нәрсәне ул тирән хөрмәт итә һәм рухи гамәлләрне дөньяви эшләрдән шулхәтле дә нык аерып карый, хәтта ки якшәмбе мәктәбендә сөйли торган нотыгын да ул икенче төрле тавыш белән сөйләргә тиеш дип таба иде. Нотыгын ул бүген болай дип башлады:

— Хәзер, балалар, сезнең мөмкин кадәр тынычрак, төзрәк утыруыгызны һәм мине бер-ике генә минут мөмкин кадәр игътибар беләнрәк тыңлавыгызны үтенер идем. Менә шулай. Бөтен тәрбияле балалар үзләрен шулай тотарга тиеш. Мин бер кечкенә кызның тәрәзәгә карап утырганын күрәм; мин шунда агач ботагына утырганмындыр да нотыгымны кошчыкларга сөйлимдер кебек тоеладыр инде аңа. (Хихылдашкан тавышлар ишетелә.) Әйбәт гадәтләргә өйрәнер өчен шушы изге бинага җыелган саф күңелле, ачык йөзле балаларны күрүемә мин бик тә куанам.

Һәм башкалар, вә башкалар. Бу нотыкның ничек тәмамланганын китереп торуның кирәге юк. Ул һаман да шул үзгәрми торган бер өлге буенча төзелгән, без аның ничек бетәсен барыбыз да алдан ук беләбез.

Бу нотыкның ахыргы өлешен малай-шалай арасында яңадан башланып киткән сугыш-кыйнашлар һәм башка төрле бәхәсләр ямьсезли иде. Кыбырсынган, пышылдашкан балаларның азынуларына кайчакларда хәтта Мэри белән Сид кебек тәүфыйк ияләре дә кушылып киткәли иде. Әмма Уолтерс әфәнде соңгы сүзен әйтеп бетерүгә һәртөрле тавыш-гауга тынып калды, һәм нотыкның ахырын бөтенесе дә зур канәгатьләнү белән, тын калып каршы алдылар.

Балалар арасындагы пышылдашу гадәттә сирәк очрый торган вакыйга — кунаклар килү белән аңлатыла иде: чиркәүгә ниндидер бер бетерешкән карт белән Тэтчер дигән адвокат килеп керде. Алар артыннан чәчләренә чал керә башлаган, урта яшьләрдәге, озын буйлы бер әфәнде белән мәһабәт кыяфәтле бер ханым күренде. Бу ханым, һичшиксез, әлеге әфәнденең җәмәгате булырга тиеш. Ул бер кызны җитәкләгән иде. Том Сойер урынында тыныч кына утыра алмады, ул бик борчылган һәм әсәрләнгән, өстәвенә вөҗдан газабы да кичерә иде. Эмми Лоуренсның күзләре белән очрашырга кыймый, аның назлы карашын күтәрә алмый иде ул. Әмма яңа килеп кергән ят кызны күргәч аның күңеле күтәрелеп китте. Том шундук малайларны төрткәли, чәчләреннән тарткалый башлады, төрлечә маймылланды — бер сүз белән әйт-

кәндә, теге кызның игътибарын җәлеп итәр, аны шаккатырыр өчен кулыннан килгәннең барын да кылана башлады. Аның куанычын тик бер нәрсә: фәрештәнең тәрәзәсе каршында кичергән ким-хурлык күңелсезли иде. Хәер, ул турыдагы хатирә дә инде сәнәк белән суга язылган сүзләр кебек кенә калды. Том кичергән бәхет дулкыннары бу күңелсезлекнең эзен дә калдырмыйча басып китә иде.

Кунакларны иң кадерле урынга утырттылар, һәм Уолтерс әфәнде нотыгын сөйләп бетерүгә укучыларны алар белән таныштырырга тотындылар.

Урта яшьләрдәге адәм бик зур дәрәҗәле кеше булып чыкты — округ судьясының үзе икән. Мондый да зур түрәне балаларның моңарчы әле бервакытта да күргәннәре юк иде; бу кеше нинди балчыктан әвәләнгән икән дигән сыман, алар аны бик кызыксынып карап утырдылар; әле алар аны ырылдап җибәрмәсме дип тә көттеләр. Моннан унике миль чамасы булган Константинополь дигән шәһәрдән килгән икән ул, димәк, сәяхәт кылган, дөнья гизгән: үз күзе белән округ судының бинасын күргән; ул бинаның түбәсе тутыя белән ябылган дип сөйлиләр. Менә шул уйлардан килеп туган олылау хисен класста урнашкан тантаналы тынлык һәм зур игътибар белән кунакка текәлгән күзләр күрсәтә иде.

Бу бит данлыклы судья Тэтчер, мондагы адвокатның туганы. Джеф Тэтчер дигән укучы, әлеге бөек кеше белән якыннан таныш булуын күрсәтер өчен, бөтен балаларны көнләштереп, алга таба китте. Иптәшләренең пышылдашуын ишетә алса, аның өчен бу иң татлы музыка авазлары белән бер булыр иде.

— Карале, Джим, ул шунда таба бара бит! Кара инде! Әллә инде кулын да кысмакчы! Ай-яй-яй! Шуның урынында буласың килмиме?

Гадәттән тыш өлгерлек, җитезлек һәм оештыру сәләте күрсәтеп, Уолтерс әфәнде төрле боерыклар, күрсәтмәләр бирде, кемгә туры килсә шуңа үнлы-суллы кисәтү өләшергә тотынды. Китапханәче дә китапларын кочаклаган килеш арлы-бирле чапты, вак түрәләргә хас булганча, бер дә кирәкмәс ыгы-зыгы тудырды. Укытучы хатын-кызлар укучыларның кайсына бармак янап, кайсының башын-

нан сыйпап, ир-атлар исә каты шелтә ясап, төрлечә үзләренең көчләрен күрсәтергә, эшлекле булып күренергә тырыштылар. Укытучыларның барысына берьюлы диярлек кафедра янындагы китап шкафыннан кинәт кенә нидер алырга кирәк булып чыккан, алар шунда икешәр-өчәр тапкыр барып килсәләр дә, теләр-теләмәс кенә атлаган булып кыландылар. Кызлар да бик тырышты, малайлар да кимен куймады, хәтта ки кәгазь чәйнәп ыргыту, колак төбенә менеп төшү кебек этлекләр дә кабатланып торды. Боларның барыннан да өстен булып, үзенең судья икәнен истә тоткан хәлдә, әлеге бөек кеше һавалы елмаеп үзенең кем икәнлеген күрсәтергә тырышты.

Бәхете түгәрәк булсын өчен Уолтерс әфәндегә бер генә нәрсә — Тәүрат бүләк итү йоласын башкару һәм укучыларының гыйлеме белән мактану мөмкинлеге генә җитми иде. Кайбер укучыларның сары билетлары бар-барын, ләкин берсендә дә җитәрлек түгел,— яхшылардан саналган бөтен укучыларыннан сораштырып чыккан иде ул моны. Теге немец малаена зиһенен кайтарыр өченниләр генә бирмәс иде ул хәзер! Өмете тәмам өзелгән бер мәлдә кулына тугыз сары билет, тугыз кызыл һәм ун зәңгәр билет тотып алга Том Сойер килеп чыкты. Ул үзенә Тәүрат таләп итте. Бу — аяз көнне яшен суккан кебек булды. Уолтерс әфәнде якындагы ун елларда гына әле Томны Тәүрат алырлык дәрәҗәгә җитәр дип көтми иде. Әмма берни эшләр хәл юк, исәп-хисап кәгазьләре кулда, аларга инде кул куелган — эше беткән, һәм аларга инде түлисе генә калган. Томны судья һәм башка шуның ише олы кешеләр утырган җиргә чакырдылар, һәм әлеге олы хәбәр кафедрадан игълан ителде. Бу — соңгы ун ел эчендәге иң шаккатыргыч вакыйга иде, һәм моның тәэсире хәйран калырлык булды: безнең яңа героебыз шундук судья белән бер дәрәҗәгә менде, һәм бөтен мәктәп бер могҗиза урынына берьюлы ике могҗиза тамаша кылды. Малайлар көнләшүдән үлә язды: Том бит коймасын буяткан өчен малайларның бар булган уенчыкларын алды, аннары, шул уенчыкларны кире биреп, шул ук малайларның сары, кызыл, зәңгәр билетларын җыйды. Әлеге искиткеч уңышка ирешергә аңа үзләре булышканга күрә малайларның җен ачулары чыкты. Шул

нәрсә аларның аңнарына хәзер генә барып житте. Бу мәкерле алдакчы шулай ансат кына түп башына утырткан өчен алар үзүзләренә нәфрәтләнделәр.

Директор Тәүратны кулыннан килгән хәтле тантаналы итеп тапшырырга тырышты тырышуын, ләкин аның нотыгы артык хисле булмады,— ник дигәндә, ул монданиндидер этлек булуыннан шикләнә иде: шушы малайның хәтер сандыгында Тәүраттан ике мең гакыл көлтәсе жыелырга мөмкин дип уйлау — үзе үк ахмаклык иде, чөнки уникесен хәтерендә калдыру да Томның хәленнән килә торган эш түгеллеген ул белә иде.

Томның Тәүрат алуы белән Эмми Лоуренс чын-чынлап горурлана иде. Аның ничек шатлануын Том да күрсен иде дип теләде ул, ләкин малай аңа таба борылып та карамады. Эммига бу бик сәер тоелды; ул беркадәр борчыла төште; аның күңеленә шом керде, аннары кызый тагын тынычлангандай булды, ләкин бу тынычлану озакка бармады. Эмми тирә-юнен күзәтә башлады — як-ягына өстән-өстән генә карап алу да аңа күп нәрсәне сөйли иде; аның йөрәге парә-парә килде; көнләшүеннән һәм ачуыннан ул елап жибәрә язды, аның күңелендә бөтен дөньясына нәфрәт уянды. Аның иң күрә алмаган кешесе Том иде... һәрхәлдә, Эмми үзе шулай дип уйлады.

Томны судья белән таныштырдылар, әмма малайның теле аңкавына ябышты, йөрәге дөп-дөп итеп тибәргә тотынды, ул көчкә тынын ала иде; моның шулай булуы өлешчә әлеге кешенең бөеклегеннән килсә, нигездә исә — судьяның Эмми атасы булудан иде. Әгәр дә мәктәп эче караңгы булса, Том сөенә-сөенә судья алдында тез чүгәр иде. Судья кулын Томның башына куйды, аны әйбәт малай дип мактады, исемен сорады, Том авызын ачып тотлыгып калды, ниһаять, көч-хәл белән:

— Том,— дип әйтә алды.

— Ә юк, Том түгел...

— Томас...

— Менә шулай. Исемең шулай бераз озынрактыр дип уйлаган идем шул. Бик әйбәт. Фамилияң дә бар инде синең, әйе бит? Син аны миңа әйтеп тә бирерсең әле?

— Әфәндегә фамилияңне әйт, Томас,— дип сүзгә кушылды Уолтерс,— аннары, өлкәннәр белән сөйләшкәндә «әфәнде» сүзен кушарга онытма. Үзеңне тота белергә кирәк.

— Томас Сойер... әфәнде.

— Менә шулай! Булды! Әйбәт малай икәнсең. Бик әйбәт! Ике мең сүрә — бик күп бит ул, бик күп! Һәм син аларны өйрәнүеңә бервакытта да үкенмәссең, чөнки белем дөньяда һәммә нәрсәдән дә өстен санала. Шул белем бит инде кешене бөек һәм күркәм итә. Син үзең дә, Томас, берәр вакыт бөек һәм гүзәл кеше булырсың; шул чакта үткән юлыңа әйләнеп карарсың да болай диярсең: «Боларның барысы өчен дә мин бала чагымда йөргән кадерле якшәмбе мәктәбемә бурычлымын; боларның барысы өчен дә мин китап белән эш итәргә өйрәткән кадерле остазларыма бурычлымын; боларның барысы белән дә мине дәртләндергән, миңа көч биргән, һәрвакыт янымда үз Тәүратым булсын өчен шушы затлы Тәүратны биргән шәфкатьле директорыма бурычлымын; боларның барысы өчен дә мине бик дөрес итеп тәрбияләгән кешеләргә бурычлымын». Менә нәрсәләр әйтерсең син, Томас, һәм, әлбәттә, ул ике мең сүрә синең өчен әллә нихәтле акчадан да кадерлерәк булыр, әйе, әйе, кадерлерәк булыр. Ә хәзер син миңа һәм менә бу ханымга ятлаганнарыңнан ни дә булса әйтеп күрсәтмисеңме? Әлбәттә күрсәтерсең, чөнки без шулай әйбәт укый торган малайларыбыз белән горурланабыз. Унике пәйгамбәрнең уникесенең дә исемнәрен беләсең инде син? Һич югы баштагы икесенең исемен әйтеп бирә алмассыңмы икән?

Том, төймәләрен тарткалап, баскан җирендә оялып кына судьяга таба карап тора бирде. Аннары, кызарынып, башын аска иде. Уолтерс әфәнденең йөрәге өзелеп төшкәндәй булды. «Малайның иң гади сорауга да җавап бирергә хәленнән килми бит,— дип уйлады ул,— судьясы да ник дип кенә сораштыра инде?» Шулай да ул сүзгә кушылуны үзенең бурычы дип санады:

— Бир инде җавабыңны әфәндегә, Томас, курыкма!

Том аягын аякка алыштырып эндәшмичә генә басып торуында булды.

— Хәзер миңа әйтеп бирә ул,— дип, сүзгә кушылды әлеге ханым да.— Баштагы ике рәсүлнең исеме ничек иде әле?..

— Давыт белән Голиаф...[1]

Без артык шәфкатьсез булмыйк инде, пәрдәне шушы урында төшереп торыйк.



[1] *Давыт белән Голиаф* — Тәуратта язылганча, Давыт — филистимлы баһадир Голиафны үтергән көтүче. Беренче рәсүлләр итеп Тәурат Петр белән Андрейны атый.

V бүлек

Унберенче яртылар тирәсендә кечкенә чиркәүнең ярык чаңы кагарга тотынды да, мәхәллә кешеләре иртәнге гыйбадәткә җыела башлады. Якшәмбе мәктәбе укучылары, чиркәү эченә кергәч, төрлесе төрле якка таралышып беттеләр, өлкәннәр күзендә булсын өчен аларны ата-аналары утырган эскәмияләргә утырттылар. Менә Полли түткәй килеп керде, Сид белән Мэри аның янына утырдылар; Томны исә, ачык тәрәзәдән җәйге урамга карап мавыкмасын дип, ике арага утырттылар. Тора-бара мәхәллә кешеләре ян бинага да кереп тулдылар: менә үз гомерендә бәхетле көннәр дә кичергән үтә дә карт, фәкыйрь почтмейстер; менә мэр белән аның хатыны,— бу шәһәрдә кирәкмәс нәрсәләр рәтендә мэр дигәне дә бар иде; менә мировой судья; менә матур итеп киенгән Дуглас дигән чибәр ханым. Яхшы күңеллелеге, юмартлыгы белән танылган, шәһәрдәге бердәнбер иң бай йортның хуҗасы булган бу ханымны монда белмәгән кеше юк. Аның йортында бөтен Сент-Питерсберг шәһәре мактана алырдай мул табынлы мәҗлесләр үткәрелә. Менә бөкшәеп беткән Уорд дигән хөрмәтле майор белән аның хатыны; бу якларга каяндыр ерактан килгән Риверсон дигән бер адвокат; әнә шушы шәһәрнең атаклы гүзәле, аның тирәсендә — батистка төренгән, тасмалар таккан сокландыргыч чибәр яшь кызлар төркеме. Кызлар артыннан бер төркем яшь егетләр — шәһәр чиновниклары килеп керде, кызлар чиркәү эченә кереп беткәнче алар, хуш исләр бөркеп, кулларындагы таякларын болгаштырып, бер җирдә өелешеп басып

тордылар. Ниһаять, барысыннан да соңгарак калып, әнисе белән бергә чиркәүгә Вилли Мафферсон дигән малай — Тәүфыйк Иясе килеп керде. Әнисенә карата ул ифрат дәрәҗәдә яхшы мөгамәләдә иде. Әнисе чиркәүгә килгән чакта Вилли һәрвакыт анык белән бергә була. Тәүфыйк Иясен шәһәрнең бөтен ханымнары үлеп ярата. Аның каравы Виллины малайлар күрәлмый, ник дисәң — ул искиткеч яхшы малай, җитмәсә аны һәрвакыт бүтәннәргә үрнәк итеп куялар. Башка якшәмбеләрдәге кебек, аның арткы кесәсеннән чем-ак яулык очы күренеп тора, әйтерсең лә ул ялгыш кына шулай чыгып калган. Томның үз гомерендә кульяулыгы булмады, шуңа күрә кульяулыгы булган малайларны ул көязгә саный иде.

Бөтен мәхәллә халкы җыелып беткәч, ялкауларны һәм ачык авызларны чакырып, чиркәү чаңы тагын берне сугып куйды да, бина эчендә тантаналы тынлык урнашты. Бу тынлыкны чиркәү хорында җырлаучыларның хихылдашулары һәм пышылдашулары гына боза иде. Хорда җырлаучылар гыйбадәтнең буеннан-буена хихылдаштылар да пышылдаштылар. Кайчандыр бар иде ул үзен әдәпле тотучы бер чиркәү хоры, тик мин аның кайда икәнен генә оныткамын. Бу бик күптән булган хәл инде, һәм ул минем бөтенләй хәтеремдә юк диярлек, тик, минемчә, ул бездә түгел, кайсыдыр бер чит илдә иде.

Вәгазь сөйләүче бер мәдхиянең исемен атады да шуны артык кычкырмый гына укый башлады һәм әкренләп тавышын күтәрә барды, аннары, мәгълүм бер урынына җиткәч, соңгы сүзгә нык кына басым ясады да, трамплиннан сикереп төшкән төсле итеп, укуын тәмамлады.

Бу вәгазьче вәгазь уку остасы дип санала иде. Чиркәүгә халык җыелган чакларда аннан һәрвакыт шигырь укуын сорыйлар иде, һәм ул шигырь укуын тәмамлауга ханымнар кулларын югары күтәреп торалар да, кинәт кенә хәлсезләнгән шикелле кире төшерәләр, күзләрен гарешка терәп, башларын чайкый башлыйлар, әйтерсең лә: «Моны сөйләп тә, язып та аңлатып бетереп булмый, бу шундый әйбәт, безнең гөнаһлы җиребез өчен бөтенләй төс түгел!» дип, соклануларын белдерергә телиләр иде.

Мәдхияне җырлап бетерүгә хөрмәтле Спрэг әфәнде белдерү

тактасына таба борылды да җыелышлар, һәртөрле җыеннар һәм башка шуның кебек нәрсәләр булачагы турында язылган белдерүләрне укырга тотынды. Ул аны шулхәтле озак итеп укыды, үлгәнче укыса да укып бетерә алмас кебек тоела башлады. Белдерү тактасына язу күп санлы газеталар чыга торган Америка өчен бигрәк тә сәер гадәт иде инде. Аның бит әле шунысы да бар: элек-электән килгән гадәт нихәтле мәгънәсезрәк булса, аннан котылу шулхәтле кыенрак була.

Аннары вәгазьче дога кыла башлады. Бу бик озын һәм бик әйбәт дога иде, аннан бер кеше дә онытылып калмады: ул дога чиркәүгә багышлап та, бу чиркәүгә караган кечкенә балаларга багышлап та, шәһәребездәге башка чиркәүләргә багышлап та, шушы шәһәрнең үзенә багышлап та, үзеңнең штатыңа, штатындагы чиновникларга һәм бөтен Кушма Штатларга багышлап та, Кушма Штатлардагы бөтен чиркәүләргә, конгресс, президент һәм дәүләт хезмәтендәге барлык кешеләргә багышлап та, Европа монархлары һәм көнчыгыш деспотлары тарафыннан изелгән халыкларга багышлап та, инҗил хакыйкатенең яктысы белән мәгърифәтле ителеп тә, күрер өчен күзләре булган хәлдә дә күрмәүчеләргә, ишетер өчен колаклары булган хәлдә дә ишетмәүчеләргә багышлап та, ерак диңгез утрауларындагы мәҗүсиләргә багышлап та кылынды бу дога, һәм ул догадагы сүзләр, уңдырышлы туфракка төшкән орлык кебек шытып, мул игелек уңышы бирсен өчен ялкынлы ялвару сүзләре белән тәмамланды. Амин!

Итәкләрнең кыштырдаганы ишетелде — дога кылганда аягүрә торып баскан мәхәллә кешеләре яңадан урыннарына утырыштылар. Шушы китап битләрендә тәрҗемәи хәле хикәя ителгән малай дога кылып маташуны кирәк санамады — ул аңа көчкә генә түзеп торды. Доганың буеннан-буена Том урынында боргаланып утырды; ул доганың эчтәлегенә төшенеп азапланмады, искә алынган багышлауларны гына саный барды, моның өчен аңа тыңлап утыру да кирәк түгел иде, чөнки вәгазьченең шушы юлдан баруына ул күптән күнеккән иде инде. Әмма вәгазьче үзенең гадәттәге дога текстына бер генә яңа сүз өстәсә дә, бу өстәмәне Томның колагы шундук

эләктереп ала, һәм аның ачуы кабара иде: мондый өстәүләрне ул алдашу, хәрәмләшү дип саный иде. Доганың яртысы укылгач, Том каршындагы урындык аркасына бер чебен килеп кунды да аның дөньясын оныттырды — чебен йә тәпиләрен бер-берсенә ышкыды, йә шул тәпиләре белән башын эләктереп алып гәүдәсен өзеп чыгарырдай итеп уды, аның җеп кебек нечкә муены аермачык булып күренеп тора иде, йә ул канатларын арт тәпиләре белән сыпыргалап, фрак итәген төзәткәләгән шикелле итеп тарткалап куйды, һәм, гомумән, ул һич кенә дә каушамыйча, бернидән дә курыкмыйча тазарынып-чистарынып утыруын белде. Ә нәрсәдән куркырга иде аңа? Томның ничек кенә кулы кычытмасын, ул аны тота алмый иде: ник дисәң, дога кылган чакта мондый эшкә омтылса, шул мизгелдә үзенең җанын харап итәчәгенә ышана иде ул. Әмма ләкин вәгазьче соңгы сүзләрен әйтеп, «амин» дигән арада чебен Томның учына әсирлеккә төшкән иде инде. Полли түткәй исә, Томны җинаять өстендә тотып, чебенне хәзер үк иреккә чыгарып җибәрергә кушты. Вәгазь сөйләүче Тәүрат китабыннан бер өзек укыды да эчпошыргыч дәрәҗәдә кызыксыз итеп ниндидер бер күңелсез нәрсә турында сүз куертырга тотынды; мәхәллә кешеләре оеп-калыгып китә башладылар, хәлбуки, асылда, сүз җәһәннәм турында һәм мәңгелек газаплар турында бара иде, ә оҗмахка керергә лаеклы гөнаһсыз кешеләр санын рухани тора-бара бик азга калдырды. Том вәгазьнең ничә бит булуын саный иде: чиркәүдән чыкканда ул һәрвакыт ничә бит вәгазь укылганын белә иде, әмма вәгазьнең нәрсә турында икә-

нен бервакытта да әйтә алмый иде. Шулай да бу юлы ул беразга гына булса да вәгазь белән кызыксынасы итте. Вәгазь сөйләүче бик тәэсирле бер мәһабәт күренешне тасвир итте: бөтен дөньядагы тәкъва кешеләр оҗмахта бергә җыелырлар икән дә шунда сарык бәтие арслан белән янәшә ятыр икән, нәни генә бер сабый исә аларны үзе артыннан ияртеп алып китәр икән. Бу олуг тамашаның пафосы һәм морале Томга тамчы да тәэсир итмәде, әлбәттә, аны бары тик дөньядагы барлык халыклар алдында сабый бала үтиячәк отышлы роль генә кызыксындырды һәм, әлбәттә, арслан кулга ияләшкән булса, әлеге бала урынында аның үзенең буласы килде.

Шуннан соң тагы коры сүз куертулар китте, һәм Том янадан интегә башлады. Кинәт ул кесәсендәге хәзинәсен исенә төшерде һәм тиз генә аны чыгарып салырга омтылды. Бу — куркыныч авызлы бик зур кап-кара коңгыз иде. Том аны «тешләк коңгыз» дип атады. Коңгызны ул пистоннан бушаган тартмага салган иде. Тартманы ачып җибәрүгә коңгыз аның бармагына кадалды. Әлбәттә инде, Том аны читкә алып ыргытты, һәм коңгыз эскәмияләр арасына барып төште; малай бармагын авызына капты. Коңгыз чалкан яткан җиреннән әйләнә алмыйча тыпырчынып ята иде. Том, әләктереп алмакчы булып, аңа таба карап торды, ләкин ара ерак иде шул. Аның каравы коңгыз вәгазь белән кызыксынмаучы башка балаларның да күңелен ачты.

Шул чакны чиркәү эченә җәйге челләдә әлсерәп хәлдән тайган бер йөнтәс эт килеп керде; ул, бәйдә яшәүдән туеп, иркенлек

эзләргә чыккан иде. Идәндә аунап яткан коңгызны күреп алуга эт моңсуланып салынып төшкән койрыгын болгарга тотынды. Йөнтәс маһмай, коңгыз белән танышырга теләп, аның тирәли әйләнеп чыкты, читкәрәк китеп курка-курка гына иснәштереп алды; тагын бер кат әйләнеп чыкты; аннары кыюлана төшеп якынрак килде һәм тагын бер кат иснәде, тешләрен ыржайтып, коңгызны эләктереп алмакчы булган иде дә — булдыра алмады; аны эләктерергә ул кат-кат омтылып карады; күрәсең, бу шөгыль аңа ошап китте; эт корсагы өстенә яткан иде, коңгыз аның алгы аяклары арасына туры килде, маһмай шаяруын дәвам итте, бераздан бу уен аны туйдырды, ул, бер нәрсәгә дә игътибар итмичә, йокымсырый башлады; әкренләп-әкренләп башы күкрәгенә таба салынып төште, шунда коңгыз аның борынына кадалды. Маһмай ачы итеп чинап җибәрде, башын селеккәләп алды, коңгызны бер читкә очырып җибәрде, һәм коңгыз тагын чалкан барып төште. Якын-тирәдә утыручылар тавыш-тынсыз гына көлүдән гаҗиз иделәр, күпләр йөзләрен җилпәзә яисә борын яулыгы белән капладылар; Том исә чиксез бәхетле иде. Маһмай бик аңгыра кыяфәттә иде — күрәсең, ул үзен шыр ахмактай хис итте, ләкин шул ук вакытта аның күңеле рәнҗи, һәм аның үч аласы килә иде. Шуңа күрә маһмай иплән кенә коңгыз янына барды да алгы тәпиләре белән кагылыр-кагылмас кына коңгызга төрле яктан һөҗүм итә башлады, тешләрен шыкылдатты, колаклары шап та шоп килерлек итеп башын селеккәләде. Ахыр чиктә болар да аны туйдырды; ул чебен белән күңел ачмакчы булды, ләкин чебен белән бернинди кызык та килеп чыкмады; борынын идәнгә тидерердәй итеп ул кырмыска артыннан йөреп карады, әмма монысы да бик тиз аның гайрәтен чигерде; ул авызын ачып иснәде, тирән итеп сулады, коңгызның бар икәнен дә онытып, аның өстенә барып утырды. Шундук котсыз итеп чинап җибәргән тавыш ишетелде. Маһмай эскәмияләр арасында чапкынлый башлады һәм, чинавыннан туктамыйча, чиркәү буйлап бәргәләнергә тотынды, алтарь алдыннан каршы яктагы ишеккә таба ук булып томырылды, ишектән тагын кирегә таба чабып китте; ул бөтен чиркәү эчен тутырып чинады, ныграк чапкан саен авыртуы көчәя генә барды; ниһаять, эт

яктылык тизлеге белән диярлек хәрәкәт итүче йонлач кометага әйләнде. Шашар дәрәҗәгә җиткән эт чиркәү буйлап өтәләнеп чабачаба хуҗасының алдына барып менде, ә тегесе аны ачык тәрәзәдән алып кына ыргытты. Чиксез газапланып өргән тавыш әкренәйгәннән-әкренәя барды һәм, ниһаять, еракка китеп тынып калды. Бу вакытта чиркәүдәге кешеләр тыелып-тыелып көлүләреннән туктый алмыйча кызарынып-бүртенеп беткәннәр иде. Хәтта вәгазь уку да беразга туктап калгандай булды. Гәрчә ул шундук дәвам иттерелсә дә, адым саен диярлек өзелеп, бутәләнеп кенә барды, шулай булгач, аның әхлакый тәэсире турында сүз дә булу мөмкин түгел иде. Мәхәллә кешеләре, чиркәүдәге эскәмияләр артына кача-поса, гөнаһ булыр дип тә уйлап тормыйча, буыла-буыла көләләр, әйтерсең лә вәгазьче ниндидер бик кызык бер мәзәк сөйли иде. Бу көлү газабының вәгазьче биргән фатиха белән тәмамлануы барысы өчен дә ихлас күңелдән көтелгән җиңеллек булды.

Том Сойер өенә бик тә күтәренке күңел белән кайтты; беркадәр төрләндерү чарасы кертеп җибәргәч, чиркәүдәге гыйбадәт тә алай ук кызыксыз булмый икән, дип уйлады малай. Аның кәефен бер генә нәрсә боза иде: йөнтәс этнең коңгыз белән уйнавы кызык хәл иде, әлбәттә, ләкин нигә инде ул юньсез маһмайга коңгызны бөтенләйгә алып китәргә? Моңа аның бер дә хакы юк иде югыйсә...



VI бүлек

Дүшәмбе көнне иртән уянуга Том үзен бик тә бәхетсез хис итте. Дүшәмбе көнне һәрвакыт шулай була ул, чөнки бу көнне мәктәптәге газаплар атнасы өр-яңадан башланып китә.

Том яткан җиреннән уйланып ятты. Кинәт кенә аның башына, авырып китсәң яхшы булыр иде бит, дигән фикер килде; ул чакта мәктәпкә дә бармыйсың инде. Өмет бик аз, билгеле, ә шулай да нигә сынап карамаска! Ул үзенең барча әгъзасын тикшереп чыкты, бер генә җире дә авыртмый иде. Том яңадан бөтен җирен капшап карады. Бу юлы аңа эче авыртадыр сыман тоелды, һәм ул авырту көчәймәсме дип өметләнә башлады. Авырту, киресенчә, кими төште һәм тора-бара бөтенләй басылды. Том тагын уйга калды. Кинәт аңа бер өске теше какшаган сыман тоелды. Бик зур уңыш иде бу; ул ыңгыраша башларга исәпләгән иде, ләкин шундук шәйләп алды: әгәр дә тешем сызлый дип әйтсә, Полли түткәй аның тешен суырып кына атачак, ә теш алганда бик тә авырта шул. Шуңа күрә Том, теш сызлавын запаста калдырып, ни дә булса башка нәрсә эзләргә тотынды. Берникадәр вакытлар буена бернинди әмәле дә чыкмый торды; аннары ул табибның бер чир турында сөйләгәнен исенә төшерде, шул чир аркасында әлеге пациент икеме, өчме атнага урын өстендә яткан һәм бармаксыз кала язган. Малай зур өметләр белән аягын җәймә астыннан чыгарды да авырта дигән бармагын тикшерергә тотынды. Бу чирнең билгеләрен ул һич кенә дә башына китерә алмады. Шулай да сынап карарга ярый бит, дип, бик тырышып ыңгыраша башлады.

Сид йоклый иде. Томның ыңгырашканын бөтенләй ишетмәде.

Том ныграк ыңгырашырга тотынды, һәм аңа бармагы тора-бара чыннан да авыртадыр кебек тоела башлады.

Сид ичмасам кыймылдап кына да карамады.

Тырышудан Томның хәтта тыннары кысылды. Ул бераз хәл алды да аннары, көчен җыеп, әйбәт кенә иттереп тагын ыңгырашып җибәрде. Сид исә гырлый-гырлый йоклавында булды.

Томның инде ачуы кабарды. Ул берничә кат: «Сид! Сид!» дип, эндәшеп тә карады, селкетеп тә алды үзен. Селкетүгә тәэсир итте, әлбәттә, һәм Том өр-яңадан ыңгырашырга тотынды. Сид уянгач авызын ачып иснәде, киерелеп алды, терсәгенә таянып сукранып куйды да Томга карап шаккатты. Том ыңгырашуында булды.

— Том! Карале, Том, дим! — диде Сид. Том җавап бирмәде.

— Ишетәсеңме, Том? Том, дим. Ни булды сиңа, Том? — Сид аны җилкәсеннән тотып селкетте, коты очып йөзенә текәлде. Том ыңгырашып алды:

— Кагылма әле...

— Ни булды, Том? Түткәйне чакырыйммы әллә?

— Кирәкми. Үтәр әле. Берәүне дә чакырма.

— Ничек инде чакырма? Син бит шулхәтле куркыныч итеп ыңгырашасың. Кайчан башланды ул?

— Берничә сәгать бар инде. Ой! Боргаланма әле, Сид, үтерәсең бит.

— Нишләп соң син мине баштук уятмадың? Әй, Том, тукта инде. Ыңгырашуыңнан бала йоннарым кабара. Кай җирең авырта соң синең?

— Мин сиңа барысын да кичерәм, Сид! (Ыңгыраша.) Нинди гаебең бар, барысын да... Мин үлгәч...

— Том, син чынлап та үләсеңмени? Үлмә инде. Том... Том, дим! Бәлки...

— Мин барысын да кичерәм, Сид. (Ыңгыраша.) Әйт син аларга, Сид. Минем сыңар күзле песи баласы белән тәрәзә рамын шәһәребезгә килгән теге яңа кызга бирерсең. Син аңа болай диген...

Әмма Сид киемен генә эләктерде дә ишектән чыгып ычкынды. Хәзер Том чын-чынлап газап чигә иде, аның хыялы шундый да шәп эшләде — ыңгырашуы да шактый ук табигый чыга иде.

Сид баскычтан йөгереп төште дә:

— Полли түткәй, дим, әйдәгез әле тизрәк! Том үлә бит,— дип кычкырды.

— Үлә дисеңме?

— Әйе! Әйе дим! Нишләп торасыз инде, әйдәгез!

— Сөйләмә юкны! Ышанмыйм!

Ләкин шулай да ул бар көченә йөгереп баскычтан өскә таба менеп китте. Сид белән Мэри аның артыннан иярделәр. Полли түткәйнең йөзе агарынган, ирелнәре дерелди. Томның ятагына барып җитүгә ул көчкә генә:

— Том! Том! Ни булды? — дип сорый алды.

— И, түткәй, мин...

— Ни булды, ни булды соң, балакаем?

— И түткәй, минем бармакка гангрена булган!

Полли түткәй урындыкка авып төште дә башта көлә башлады, аннары елап җибәрде, аннары елый-елый көләргә тотынды. Шуннан соң ул бераз хәл алгач, исенә килеп:

— Ну, куркыттың да соң, Том! — диде.— Ә хәзер җитте, шаяруыңны ташла һәм моннан соң яңадан кабатлыйсы булма!

Ыңгырашкан тавыш тынды, бармак авыртудан туктады. Том үзен бик уңайсыз хис итте.

— Чынлап менә, түткәй, бармагым гел үлгән кебек тоелды миңа, ул шулхәтле нык авыртты, мин хәтта тешемне дә онытып җибәргәнмен.

— Тешеңне? Тешең нишләде соң?

— Бер өске тешем какшый да, бик нык авырта да, чыдый торган түгел менә...

— Ярар, ярар, яңадан ыңгырашасы булма. Ач әле авызыңны!.. Әйе, тешең чыннан да какшый икән, әмма теш какшаганнан әле берәүнең дә үлгәне юк. Мэри, бар ефәк җеп алып кил, кухнядан бер кисәү башы да ала кил.

— Түтәкәем, зинһар дип әйтәм, тешемне ала күрмәгез, ул инде хәзер бөтенләй авыртмый башлады! Шушы урынымда чәчрәп китим менә! Түтәкәем, дим, кирәкми! Мин болай да барам мәктәпкә...

— Мәктәпкә барам дисеңме? Менә нәрсәдә икән хикмәт! Мәктәпкә бармыйча су буена чыгып ычкынмакчы булгансың икән әле син! Их, Том, Том, мин бит сине шундый яратам, ә син мине шул кыргый гадәтләрең белән тәмам үтерәсең!



Ул арада теш алырга дигән кирәк-яракны китереп тә җиткерделәр. Полли түткәй ефәк җепне элмәкләп какшаган тешкә кидертте дә, җепнең икенче очын караватка бәйләп куйды. Аннары янып торган кисәү башын малайның йөзенә үк диярлек китереп төртте. Теш суырылып килеп чыкты да җеп очында асылынып калды.

Башыннан кичергән читенлекләр кешенең үзенә нинди дә булса игелек булып кайтырга тиеш. Иртәнге аштан соң мәктәпкә дип чыгып киткән Томга очраган бөтен малайлар кызыгып карады: чөнки суырып алынган теш арасыннан үзенә бертөрле искитмәле итеп чирттереп төкерергә була иде. Шул күренешкә кызыгып аның тирәсенә бер өер малай җыелды; арадан берсе, бармагы киселгәнгә кәпрәеп йөргәне, хәзер инде бөтенләй игътибар үзәгеннән төшеп калды. Бу хәл малайның үтә дә хәтерен калдырды, һәм ул, бер дә исе киткәндәй итеп, Том Сойер кебек итеп төкерү берни түгел, дигән булды, ләкин икенче бер малай моңа каршы: «Синең хәлеңнән килми бит әле ул!» — дип җавап бирде, һәм чын йөзе ачылган каһарманга, хурлыкка калып, болар яныннан китәргә туры килде.

Шуннан соң Том Һаклберри Финн дигән яшь бер пария[1] белән очрашты. Аның атасы Сент-Питерсбергның беренче исереге иде. Шәһәрдәге бөтен аналар Һаклберрины күрә алмыйлар, аңа җирәнеп, чирканып карыйлар, чөнки ул ата ялкау, тәрбиясез һәм берниндиi кагыйдәләрне танымый торган әшәке бер малай иде. Балалары аңа

[1] *Пария* — кимсетелгән, хокуксыз, кагылган-сугылган кеше.

сокланып карагаң өчен, аның белән аралашырга омтылган һәм бөтен яктан да аңа охшарга теләгән өчен дә әниләр әлеге һакны яратмый иде. Мөхтәрәм гаиләләрдән чыккан башка малайлар кебек, Том да хокуксыз һаклберрига кызыга иде, Томга да шулай ук ул йолкыш белән эш итмәскә дигән катгый кисәтү ясалган иде. Нәкъ менә шуның өчен дә Том аның белән уйнау җаен ычкындырмаска тырыша иде. Һаклберри өлкәннәр өстеннән төшкән иске-москыга киенгән булыр; ул кием дигәне төрле төстәге тапларга буялып, чуарланып, ертылып беткән булыр. Баш киеме дә аның эшләпә икәнен аерып булмый торган ямьшәеп беткән бер нәрсәдән гыйбарәт; пинҗәк кисә, ул аның үкчәсенә тиеп торыр, артындагы төймәләре биленнән әллә никадәр түбәнрәк булыр; арттан капчыкка охшаган ыштаны исә подтяжкасына гына эләгеп торыр; әгәр сызганып куймаган булса, чукланып-чачакланып беткән балаклары саздан сөйрәлеп йөрер иде...



Һаклберри, ирекТәге кош кебек, кайда тели, шунда йөри иде. Көннәр аяз торса, ул берәр өйнең баскычында йоклый, яңгыр яуса, берәр буш мичкә эченә кереп куна. Аның мәктәпкә дә, чиркәүгә дә йөрисе юк, ул берәүнең дә сүзен тыңларга тиеш түгел, берәү дә аңа хуҗа була алмый. Тотасы килсә ул балык тота, теләгән җирендә теләгән хәтле су коена. Берәү дә аны сугышудан тыймый. Тели икән ул иртәнгә хәтле йокларга ятмый — моның өчен аңа беркем бер сүз әйтми. Яз җитсә, ул малайлар арасында беренче булып яланаяк йөри башлый, көзен исә соңгы кеше булып аягына киенә. Аңа юынырга да, чиста кием кияргә дә кирәк түгел, аның каравы ул менә дигән итеп сүгенә белә. Бер сүз белән әйткәндә, тормышны гүзәл итә торган бөтен шартлары да бар

иде бу йолкышның. Һәрхәлдә, Сент-Питерсбергтагы әдәпле гаиләләрдән чыккан, «яхшы тәрбия» алган, кул-аяклары бәйле малайлар шулай уйлый иде.

Бу хыялый сукбайны Том:

— Әй, Һаклберри! Исәнме! — дип сәламләде.

— Саумы,..

— Нәрсә ул кулыңда?..

— Үлгән мәче...

— Каяле, Һак, карыйм әле! Катып беткән бит бу! Каян алдың син аны?

— Бер малайдан сатып алдым.

— Ә аңа ни бирдең?

— Зәңгәр билет белән үгез куыгы... Куыкны мал суя торган җирдән алдым.

— Зәңгәр билетын каян?

— Бен Роджерстан сатып алдым. Кыршау йөртә торган таякка алыштым.

— Карале, Һак, ул үлгән песи нәрсәгә ярый соң?

— Ничек нәрсәгә? Кулдагы сөялне бетерергә!

— Шулаймыни? Мин аның тагы да шәбрәк чарасын беләм.

— Белерсең инде! Нинди чара ул?

— Тынчыган су белән бетерәсең.

— Тынчыган су белән? Бернигә дә ярамый ул синең тынчыган суың!

— Ярамас! Сынап карадыңмы әллә?

— Мин карамадым. Боб Таннер сынап караган.

— Ә сиңа кем әйтте?

— Кем әйтсен! Ул Джеф Тэтчерга әйткән, Джеф — Джонни Бэккерга, Джонни Джим Һоллиска әйткән, Джим — Бен Роджерска, Бен бер негрга әйткән, ә негр миңа әйтте. Менә шуннан беләм мин аны.

— Шуннан ни булган? Алар барысы да алдалыйлар. Негрны әйтмим мин. Ул негрны мин белмим. Әмма минем әле алдашмый торган бер негр да күргәнем юк. Болар барысы да буш сүз! Менә син миңа Боб Таннерның ничек итеп сөялен бетергәнен сөйләп бир.

— Ничек итеп булсын инде! Черегән агач төбенә җыелып торган яңгыр суына китергән дә тыккан кулын.

— Көпә-көндезме?

— Көндез булмый!

— Туп-туры агач төбенә карапмы?

— Башкача ничек булсын инде! Мин шулайдыр дип уйлыйм.

— Ә үзе берәр сүз әйткәнме соң шул чакта?..

— Бер нәрсә дә әйтмәгән бугай... Кем белә инде аны!

— Нинди ахмак шулай итеп бетерсен ди инде сөялне! Алай гына бетми шул ул! Япа-ялгызың урман ешкынлыгына керәсең дә җиде төн уртасында черек агачка таба артың белән борылып, кулыңны суга тыгасың һәм:

Арпа, арпа, һинд азыгы булып чәчел,
Тынычлан, су, кулымдагы сөялемне бетер...—

дип такмаклый башлыйсың. Аннары күзеңне йомып төгәл унбер адым читкә китәргә һәм баскан җиреңдә өч тапкыр әйләнеп алырга. Ә өйгә кайткан чагында юлда беркемгә бер сүз дәшмәскә. Берәрсе сүз кушса, тылсымның бернинди тәэсире дә калмый.

— Әйе, бу дөрес булырга охшый, тик менә Боб Таннер... ул бит сөялне алай итеп бетермәгән.

— Алай түгелдер шул! Шуңа күрә дә аның сөялләре дөнья кадәр, малайлар арасында иң күп сөял аныкы инде. Әгәр дә тынчыган су белән ничек эш итәргә икәнен белсә, аның инде бер сөяле дә калмаган булыр иде. Шул юл белән мин үзем дә бик күп сөялемне бетердем, һак. Мин бит бака белән күп чуалам, шуңа күрә минем кулымда сөял дә күп була. Кайчакта мин аны борчак кузагы белән дә бетерәм.

— Әйе шул, борчак кузагының да файдасы тия. Минем үземнең дә сынап караганым бар.

— Кит аннан! Ничегрәк итәсе аны?

— Кузакны ярып борчакларын аласың, сөялеңне каны чыгарлык итеп пычак белән кисәсең дә канын кузакның яртысына тамызасың; шул ярты кузакны җиде төн уртасында чокыр казып күмәсең, ә икенче яртысын утта яндырасың. Беләсеңме, кузакның кан тамган

өлеше икенче яртысын үзенә таба тартып тора икән, кан исә сөялне үзенә таба тарта, шуңа күрә ул тиз бетә, ди.

— Әйе шул, Һак, дөрес сүзгә җавап юк, ди, тик менә кузакның яртысын җиргә күмгән чакта: «Кузакны чокыр алсын, сөял кулдан юк булсын, яңадан әйләнеп кайтмасын!» — дип әйтергә дә кирәк. Шулай итсәң әйбәтрәк була. Джо Һарпер да шулай эшли. Беләсеңме, аның бит бармаган җире юк. Хәтта Кунвиллгә кадәр барып җиткән ул. Ә соң сөялне песи үләксәсе белән ничек итеп бетерәләр?

— Менә ничек. Мәчеңне аласың да җиде төн уртасы алдыннан зиаратка, яңа гына җирләнгән бер юньсез кешенең кабере янына барасың. Төп-төгәл җиде төн уртасында синең яныңа бер убыр килеп чыгар, бәлки ул бер генә дә булмас, икәү яисә өчәү булыр, ләкин син аларны күрмәссең, тик шунда җил шаулагандай тоелыр, бәлки әле сөйләшкәннәрен дә ишеткән кебек булырсың. Алар мәетне өстерәп алып китә башлагач, артларыннан мәчеңне ыргытасың да: «Убыр — мәет артыннан, мәче — убыр артыннан, мин — мин түгел, сөял минеке түгел!» — дип такмаклыйсың. Шулай итсәң бер сөялең дә калмас.

— Чынга охшаган болай үзе. Синең үзеңнең шуны сынап караганың булдымы, Һак?

— Юк, сынаганым булмады. Һопкинс дигән карчыктан ишеткән идем мин моны.

— Алайса дөрес инде бу. Аны бит сихерче диләр.

— «Диләр!» Аның шулай икәнен мин үзем беләм. Ул минем әткәйне сихерләгән. Әткәйнең миңа үзенең сөйләгәне бар. Бервакыт кайтып килә икән бу, ә теге моңа сихер җибәрә икән. Әткәй бер таш алган да томырган моңа таба, көчкә генә бер читкә тайпылып калган теге. Шуннан ни булган дип уйлыйсың? Шул төнне үк әткәй салган баштан лапас түбәсеннән егылып төшә дә кулын сындыра.

— И Ходаем, менә бит нинди хәлләр була! Ә ул аның сихерләгәнен каян белгән?

— Әткәй өчен бу бик ансат эш булган. Ул болай ди: әгәр дә сихерче сиңа таба күзен тондырып карап тора икән, бел дә тор —

сихерләве ул аның, ди. Әгәр дә ул шул вакыт ни дә булса мыгырдана икән, монысы инде бөтенләй дә юньлегә түгел: бу — сихерче «Отче наш»ны арттан алга таба укый дигән сүз, аңлыйсыңмы?

— Карале, Һак, син мәчеңне кайчан сынап карамакчы буласың?

— Бүген төнлә. Минемчә, бүген төнлә убырлар Уильямс дигән карт шайтанны алырга киләрләр.

— Соң аны шимбә көнне үк җирләделәр бит инде. Шимбә төнендә алып китмәделәр микәнни?

— Юк ла. Төн уртасына кадәр алар аны алып китә алмадылар, ярты төннән соң инде якшәмбе туды. Якшәмбе көнне убырлар теләсә кайда йөри алмыйлар.

— Карале, дөрес бит. Мин анысын уйламаганмын да... Мине дә ияртәсеңме соң?

— Әйдә, курыкмасаң.

— Курка ди! Әйттең сүз! Мияулап чакырырга онытмассыңмы?

— Онытмыйм... Әгәр чыгарга ярaса, син үзең дә мияулап җавап бир. Югыйсә үткәнендә мияуладым-мияуладым да теге карт Гэйс миңа таш ыргыта башлады. Җитмәсә әле: «Каһәр төшкән мәче!» дип сукрана үзе. Ә мин аның тәрәзәсенә таш ыргыттым, тик син кара аны, сөйләп йөрисе булма тагы.

— Юк инде, нишләп сөйлим. Ул төнне мин мияулап җавап бирә алмадым: мине түткәй күзәтеп торды. Бүген мияулармын инде... Карале, Һак, ни ул синең анда?

— Болай, талпан гына.

— Каян алдың соң син аны?

— Урманнан таптым.

— Берәр нәрсәгә алышмыйсыңмы?

— Белмим әле. Бик алышасым килеп тормый.

— Алышмасаң тагы! Бик кирәге бар иде. Талпаны да кеп-кечкенә әле аның.

— Кеше талпанын хурлау ансат ул. Мин үзем бик канәгать. Миңа шул да ярый.

— Талпан теләсәң кая бар ул. Кирәк икән мин аны меңне тотам.

— Нигә тотмыйсың соң? Берне дә таба алмасыңны бик яхшы беләсең бит. Бу бик иртә чыга торган талпан. Быел яз беренче очраган талпан әле ул.

— Карале, Һак, әйдә мин сиңа шуның өчен тешемне бирим.

— Күрсәт әйдә.

Том тешен төреп куйган кәгазен тартып чыгарды. Һаклберри кызыксынып тешне карарга тотынды. Ул аңа бик тә кызыкты. Ниһаять, малай:

— Чын тешме соң бу? — дип куйды.

Том авызын ачып тешенең урынын күрсәтте.

— Ярый алайса,— диде Һаклберри,— килештек!

Том талпанны пистон тартмасына салды, әле кайчан гына ул тартма коңгыз өчен зиндан хезмәтен үти иде; малайлар шунда аерылыштылар, аларның һәрберсе үзен баеган дип хис итте.

Башка йортлардан читтәрәк торган агач мәктәп бинасына якынлашуга Том, дәрескә ашыккан кеше сыман, адымын кызулатты. Ул эшләпәсен чөйгә элеп куйды да бик эшлекле кыяфәт белән үз урынына таба юнәлде. Үрелгән биек креслога утырган укытучы классның салмак кына гүләвенә йокымсырап утыра иде. Томның килеп керүе аны уятып җибәрде.

— Томас Сойер!

Үзенең исемен тутырып әйтсәләр Том нинди дә булса күңелсезлек килеп чыгасын белә иде.

— Мин монда, әфәнде.

— Якынрак килегез. Гадәтегез буенча сез тагын соңга калдыгыз. Ни сәбәпле?

Җәзадан котылыр өчен ул ялганламакчы булган иде, әмма шушы мәлдә аның күзенә алтынсу озын толымнар чалынды, бу толымнарны ул мәхәббәт көче аркасында шундук танып алды. Бөтен класста берданбер буш урын шушы кыз янында иде. Бер генә мизгелгә дә уйланып тормыйча, Том:

— Мин бер генә минутка Һаклберри Финн белән сөйләшеп алырга дип тукталган идем,— диде.

Укытучы шаккатудан нишләргә белмәде, аптырап Томга

текәлде. Класс гүләвеннән туктады. Укучылар, бу башсыз малай әллә акылыннан шаштымы, дип уйлап куйдылар. Укытучы кабатлап сорады:

— Нишләдем... дисез?

— Һаклберри Финн белән сөйләшеп алырга дип тукталым.

Бу сүзләрне ялгыш аңлау мөмкин түгел иде.

— Томас Сойер, кайчан да булса мин ишеткән сүзләрнең иң гаҗәбе шушыдыр. Моның өчен бер генә линейка аз. Салыгыз курткагызны!

Кулы арыганчы, чыбыклар сынып беткәнче тырышты укытучы. Аннары түбәндәге фәрман яңгырады:

— Ә хәзер, әфәндем, барыгыз, кызлар янына утырыгыз! Бу сезгә сабак булсын!

Укучылар пырхылдашып алдылар. Бу Томны уңайсызландыргандай итте. Чынында исә аның уңайсызлануына башка хәл сәбәп булды: серле алиһәне ул чиксез ихтирам итә иде һәм өстенә ишелеп төшкән бу зур уңышыннан газаплы бер куаныч кичерде. Том нарат эскәмиянең читендә шәфталуны күреп алды. Кызый шәфталуны читкәрәк этеп куйды. Том йомшак кына итеп аны тагын кызга таба шудырды. Кызый тагын кире этте, ләкин бу юлы инде ул әллә ни нәфрәтләнмәде. Том сабыр гына итеп шәфталуны элекке урынына күчерде, кызый бу юлы аңа кагылмады. Том грифель тактага: «Зинһар, алыгыз инде, минем тагын бар»,— дип язып куйды. Кызый тактага күз төшереп алды, ләкин берни дә җавап бирмәде. Том тактага нидер ясый башлады, үзе рәсемен сул кулы белән каплап торды. Кызый башта кызыксынмаган атлы булып кыланды, ләкин тора-бара аның кызыксынганы сизелә башлады. Малай, берни дә искәрмәгәндәй, рәсемен ясавында булды. Кызый аның нәрсә ясавын астан гына карап алмакчы булган иде, Том яңадан да аның кызыксынуын күрмәмешкә салышты. Ниһаять, кызый түзмәде, кыяркыймас кына:

— Миңа карарга ярыймы? — дип сорап куйды.

Том аңа түбәсенә ике уенчык ат ясап куелган, торбасыннан бормаланып-бормаланып төтен чыгып торган карикатура сыман

шыксыз өен күрсәтте. Кызый, Томның рәсем ясавы белән мавыгып, бөтен дөньясын онытты. Том ясап бетергәч, ул тагын бер кат рәсемгә карап алды да:

— Нинди матур! Кеше дә ясап куегыз әле! — дип куйды.

Рәссам өй каршына күтәргеч кранга охшаган бер кеше бастырып куйды. Ул шундый озын иде, хәтта өйне атлап чыгарга исәпләсә дә аңа берни тормас иде. Әмма кызый бик үк таләпчән түгел иде, шул карачкыдан канәгать булып:

— Нинди матур! Хәзер мине ясагыз инде! — дип пышылдады.

Том тулган ай эченә ком сәгате ясап куйды, шуңа нечкә генә итеп кул-аяклар сызды, кулның тырпайган бармакларына биниһая зур җилпәзә тоттырды.

— Их, нинди әйбәт! — диде кызый.— Мин дә шулай ясый белсәм иде!

— Нәрсәсе бар аның, бер дә читен эш түгел ул! Өйрәтимме соң?

— Чынлапмы? Кайчан?

— Озын тәнәфестә сез ашарга өйгә кайтып йөрисезме?

— Телисез икән, мин кайтмыйм.

— Бик әйбәт. Сезнең исемегез ничек?

— Бекки Тэтчер. Ә сезнең? Хәер, беләм бит — Томас Сойер.

— Кыйныйсы булсалар минем исемне гел шулай тутырып әйтәләр. Тәртип бозмаганда Том дип кенә эндәшәләр. Сез мине Том дип кенә йөртегез, яме?

— Ярар.

Том яңадан мактага нидер яза башлады, ә язганын Беккидан яшерде. Кызый бу юлы уңайсызланып тормады һәм мактада ни барын күрсәтүен сорады.

— Юк ла инде, бер нәрсә дә,— дигән булды Том.

— Юк, бар!

— Юк инде, юк! Аннары бит сезгә кызык та түгел ул!

— Кызык! Кызык, дим! Күрсәтегез инде!

— Аннары берәрсенә әйтүегез бар.

— Әйтмим, билләһи-валлаһи-таллаһи дип әйтәм, әйтмим!

— Берәүгә дә, бер генә җан иясенә дә әйтмисезме? Мәңге әйтмисезме?

— Берәүгә дә әйттмим. Күрсәтегез инде.

— Соң бит сезнең күрәсегез дә килми...

— Ах, шулаймы! Алайса мин барыбер карыйм!

Һәм үзенең нәни куллары белән Томның кулына ябышты, көрәш башланды. Том чын-чынлап курыккан атлы булып кыланды, әмма әкренләп кулын бер читкә шудырды һәм ниһаять: «Мин сезне яратам!» дигән сүзләр күренде.

— Әшәке! — дип, кызый тиз генә аның кулына сугып алды, ә үзе кызарып чыкты,— әлеге сүзләр аның күңеленә хуш килгәне әллә каян күренеп тора иде.

Шул мәлне Том кемнеңдер салмак кына, ләкин бик каты итеп колагыннан эләктереп, аны өскә таба тарта башлавын тойды. Шушылай итеп, аны бөтен класс аша үзенең әүвәлге урынына илттеләр, класстагы бөтен бала-чага хихылдап торды, шуннан соң берничә минутлар буена укытучы, бер сүз дә әйттмичә, ярсыган кыяфәттә аның янында басып торды, аннары, шулай ук бер сүз дә әйттмичә, үзенең тәхетенә таба юнәлде. Томның колагы ут янып торса да, күңеле тантана итә иде.

Класс тынычлана төшкәч, Том бик тырышып укуга бирелмәкче булды, әмма ул чамадан тыш дулкынланган иде. Уку дәресендә ул ялгышып, сүзләрен бутап бетерде, җәгърәфия дәресендә күлләрне — тауларга, тауларны — елгаларга, елгаларны материкларга әйләндереп бетерде, ягъни бөтен галәм борынгы хаос халәтенә кайтты. Аннары диктант вакытында гап-гади сүзләрне ул шулкадәр хаталы итеп язды, хәтта аның дөрес язу өчен бирелгән кургаш медален дә кире алдылар. Шул медале белән менә инде берничә ай буена Том мактанып туя алмый иде.



VII бүлек

Том игътибарын дәрескә юнәлтергә никадәр ныграк тырышса, аның фикерләре шулкадәр ныграк чуалды. Ниһаять, ул тирән итеп бер сулап куйды да, авызын ачып исни-исни, юкка җәфаланмаска булды. Озын тәнәфес бервакытта да җитмәс кебек тоелды аңа. Көн бик бөркү иде, җил искәне бөтенләй сизелмәде. Ямансу көннәрнең дә иң ямансурагы иде бу көн. Дәресләрен ятлап утырган егерме биш баланың умарта күче кебек бертөрле гүләгән тавышы Томны йокымсыратты. Анда, еракта, кояшның ялкынлы нурларында Кардиф тауларының нәфис-яшькелт сыртлары җемелди; ерактан, эсселек томаны аша алар куе кызылга манылган кебек күренә. Күктә, бик биектә, иренеп кенә ялгыз кошлар оча; йокымсырап яткан ике-өч сыерны исәпләмәгәндә, урамда бернинди дә җан иясе күренми. Томның күңеле иреккә омтыла иде. Шушы эчпошыргыч вакытны үткәреп җибәрер өчен нинди дә булса кызык табасы килде аның! Малай кесәсен актаргалады, һәм кинәт аның йөзе сөенечтән яктырып китте. Иләп кенә кесәсеннән пистон тартмасын тартып чыгарды да шуннан талпанны алып парта өстенә җибәрде. Шушы бәхетне биргән өчен ул үзе дә сизмәстән Ходайга рәхмәт укыды. Талпан да Ходайга рәхмәт укыгандыр, чөнки ул да сөенечтән нишләргә белмәде, ләкин аның сөенүе вакытсызрак булды, чөнки моннан ычкынырга җыенгач та Том аны, булавкасы белән борып җибәреп, башка юнәлештә хәрәкәтләнергә мәҗбүр итте.

Том белән янәшә, шулай ук күңелсезлектән нишләргә белмичә, аның бер якын дусты утыра иде; килеп чыккан күңел ачу мөмкинлегенә ул да чиксез куанды. Аның бу дусты Джо Һарпер исемле иде. Малайлар атна буена дус кына булып йөриләр дә, якшәмбе көннәрендә үзара сугышып китәләр иде. Джо курткасының якасына кадап куйган булавкасын алды да Томга кушылып талпан белән уйнарга тотынды. Уен торган саен кызыграк була барды. Уйный торгач Том Джоны күпсенә башлады, дусты аңа талпан белән уйнарга комачаулыйдыр кебек тоелды. Ул Джо Һарпернең грифель тактасы белән партаны икегә бүлде дә өстән аска кадәр сызык сызып төшерде.

— Менә,— диде ул,— талпан синең якта чакта син аны теләгән кадәр йөртә аласың, мин тимим, әгәр дә ул минем якка чыгып китсә, ул чагында инде талпанны мин генә йөртәм.

— Ярар. Башла әйдә!

Талпан тиз арада Том ягыннан Джо ягына таба экваторны кичеп чыкты. Шуннан соң аны бераз Джо интектерде. Аннары талпан, Джодан качып, тагын чикне үтеп чыкты. Ул әледән-әле бер яктан икенче якка күчеп торды. Малайларның берсе, бу кызыктыргыч шөгыль белән мавыгып, талпанны куып йөрткән арада аларның икенчесе дә шундый ук кызыксыну белән уенны күзәтеп торды. Икесе дә башларын такта өстенә таба игәннәр, ниндидер башка нәрсә аларның гамендә дә юк иде. Ахырга таба Джоның бәхете баса төште, күрәсең. Малайларның үзләреннән ким алгысымаган талпан әле тегендә, әле монда ташланды, әмма һәрвакыт, җиңү инде Том ягында дип, аның бөҗәккә кагылам дип куллары кычытып торганда гына Джоның булавкасы осталык белән талпанның юлын бүлеп куя иде дә, бөҗәк тагын Джо биләмәсенә кереп кала иде. Ниһаять, Томның сабырлыгы төкәнде. Кызыгуы чиктән ашты. Ул, кулын сузып, талпанны үз ягына таба тарткали башлады. Джоның шундук ачуы чыкты.

— Кагылма, Том! — диде ул.

— Әз генә кыймылдатып карамакчы идем мин аны.

— Бу — гаделсезлек, әфәндем, талпанны тынычлыкта калдырыгыз!

— Мин бит нәни генә...

— Тынычлыкта калдыр дим талпанны!

— Ә мин менә калдырмыйм аны тынычлыкта!

— Хакың юк, ул минем якта!

— Ә талпан үзе кемнеке соң, Джо Һарпер?

— Кемнеке булса да миңа барыбер... ул минем якта, һәм син аңа кагыласы булма!

— Ничек инде кагыласы булма? Талпан минеке, һәм мин аның белән ни телим, шуны эшлим!

Кинәт Томның иңбашына каты гына итеп китереп суктылар. Джога да шундый ук өлеш тиде. Ике минутлар буена укытучы бик тырышып аларның курткасыннан тузан какты; малайларның кыйналуына бөтен укучы сөенде. Укытучы, аяк очларында гына малайлар янына килеп, аларның уеннарын карый башлаганда дуслар үзләренең шөгыльләренә үтә дә нык бирелгән иделәр шул. Класста да кинәт кенә тирән тынлык урнашты. Малайларның уенына төрләндерү чарасы керткәнче укытучы аларны озак кына итеп күзәтеп торган иде.

Ниһаять, уникене сугып озын тәнәфес башлангач, Том Бекки Тэтчер янына барды да аның колагына пышылдап кына:

— Өйгә кайткан атлы булып эшләпәгезне башыгызга киегез,— диде.— Почмакка барып җиткәч башка кызлардан ничек тә булса аерылып артка калыгыз да борылып кире килегез. Ә мин икенче юлдан китәм дә, үзебезнекеләрдән качып, яңадан монда киләм.

Шулай итеп, Том — бер төркем иптәшләре белән, Бекки икенче төркем белән китте. Озакламыйча алар тыкрыкның аргы башында очраштылар да бушап калган мәктәпкә кире керделәр. Грифель тактасын алларына куеп алар янәшә утырдылар. Беккиның кулына Том, грифель тоттырды да, рәсемне ничек ясарга икәнен күрсәтеп, аның кулын такта буйлап йөртә башлады, һәм, шулай итеп, тагын

бер бик матур өй барлыкка килде. Сәнгать белән мавыгу сүреләә төшкәч, алар сөйләшеп утырдылар. Том рәхәт минутлар кичерә иде. Ул Беккидан:

— Күселәрне яратасызмы сез? — дип сорады.

— Юк, мин күселәрне күрәлмыйм.

— Шулай инде ул, тере күсене мин дә яратмыйм. Мин бит үлгән күсе турында әйтәм. Бауга бәйләп тотасың да баш өстендә болгыйсың аны.

— Юк, күселәрне мин гомумән яратмыйм. Резинка чәйнәргә яратам мин.

— Шулайдыр шул, аны мин дә яратам. Менә хәзер чәйнәсәң иде ул. Тик минем резинкам гына юк.

— Минем бар бераз. Чәйнәп торырга бирәм мин, тик кире бирерсең.

Том риза булды, алар резинканы чиратлап чәйнәргә тотындылар һәм, рәхәткә чыдый алмыйча, аякларын селкеп утырдылар.

— Сезнең циркта булганыгыз бармы? — дип сорады Том.

— Әйе, булганым бар. Әйбәт укысам, әтием тагын алып барам, диде.

— Минем әллә ничә тапкыр булганым бар. Өчме, дүртме тапкыр. Цирк белән чагыштырганда чиркәү чүп кенә инде ул. Циркта һаман ни дә булса күрсәтәләр. Үскәч мин клоун булам.

— Шулаймыни? Менә шәп булыр! Алар шундый матурлар, чуп-чуар итеп киенәләр.

— Шулай шул, өстәвенә күрәп акча да алалар. Бен Роджерс әйтә, көн саен берәр доллар алалар, ди. Карале, Бекки, сезне кайчан да булса ярәшкәннәре бармы?

— Ни дигән сүз соң ул?

— Соң, кияүгә бирергә дип ярәшәләр инде. Ярәшелгән кыз буласыгыз киләме соң?

— Мөгаен... Тик мин аның рәтен белмим шул. Ничек эшләнә соң ул?

— Ничек булсын? Берничек тә түгел. Берәр малайга, синнән башка бүтән кешегә бервакытта да кияүгә чыкмыйм, дип кенә әйтәсез. Аңладыгызмы? Һәм шуннан соң үбешәсез. Шул гына. Моны теләсә кем эшли ала!

— Үбешәбез? Ә ни өчен үбешергә?

— Ни өчен дип инде... тәртибе шулай... Бөтен кеше дә шулай эшли.

— Бөтен кеше дә мени?

— Әйе, бөтен гашыйклар да. Тактага минем ни язганны хәтерлисезме?

— Әйе.

— Нәрсә дип яздым?

— Әйтмим.

— Бәлки аны сезгә мин әйтермен?

— Әйе, тик башка берәр вакытта.

— Юк, хәзер әйтәм.

— Юк, хәзер түгел,— иртәгә.

— Юк, юк! Хәзер, Бекки! Зинһар дим. Мин әкрен генә, сезнең колагыгызга гына... пышылдап кына... әйтәм...

Бекки икеләнеп калды. Том аның эндәшмәвен ризалык билгесе дип кабул итте, кызның иңеннән кочып алды да иреннәрен кызның колагына ук тидереп, йомшак кына итеп:

— Мин сине яратам,— диде.— Ә хәзер шуны ук син миңа пышылдап кына әйт,— дип өстәде.

Кыз озак кына ризалашмый торды һәм, ниһаять:

— Минем пышылдаганны күрмәс өчен сез икенче якка борылыгыз,— диде.— Тик берәүгә дә әйтмәгез. Әйтмисезме, Том?

— Юк, берәүгә дә сөйләмим. Йә инде, Бекки!

Том читкә борылды. Кыз аңа таба шундый да якын итеп иелде, хәтта ки аның сулышыннан Томның чәчләре җилфердәде, һәм: «Мин... сезне... яратам...» дип пышылдады.

Һәм, урыныннан сикереп торып, парталар тирәли йөгерә башлады, Том исә аның артыннан чапты, аннары кызый, йөзен алъяпкыч белән каплап, бер почмакка кереп посты. Том, муеныннан кочып алып, Беккины үгетли башлады:

— Менә шул инде, Бекки, хәзер үбешергә генә калды. Юкка куркасың син, бернис дә юк бит аның. Йә инде, Бекки! — дип, ул аның кулларыннан тарткалады.

Бекки әкренләп йомшый барды, кулларын төшерде дә йөгерүдән кызарып чыккан янагын куйды. Том аның алсу иреннәннән үбеп алды.

— Менә шул, Бекки, моннан соң инде син миннән башка берәүне дә яратмаска һәм кияүгә дә башка берәүгә чыкмаска тиеш. Мәңгегә инде бу, ярыймы?

— Әйе, мин синнән башка беркемне дә яратмаячакмын, Том, фәкать сине генә яратачакмын һәм кияүгә бүтән беркемгә дә чыкмаячакмын. Син дә, кара аны, миннән башка берәүгә дә өйләнмә, миңа гына өйлән!

— Әлбәттә. Үзеннән-үзе аңлашыла инде. Мәктәпкә дә без һәрвакыт бергә йөрербез, өйгә кайтканда да, безне күрүче булмаса, уйнаган чакларда да син мине сайлап алырсың, ә мин — сине. Ярәшелгән егет белән кыз шулай эшлиләр.

— Менә шә-әп! Мин белми идем дә бит әле. Бу турыда ишеткәнем дә булмады.

— Их, шулхәтле күңелле! Менә без Эмми Лоуренс белән...

Бекки Тэтчер күзләрен зур итеп ачты, һәм Том үзенең хата җибәргәнен аңлап алды да уңайсызланып тынып калды.

— Их, Том! Мин беренче түгел икәнмен бит... Синең ярәшкән кызың булган икән бит...

Кыз елап җибәрде.

— Елама инде, Бекки! Мин хәзер аны яратмыйм инде.

— Юк, яратасың, яратасың. Яратканыңны син үзең дә беләсең.

Том аны муеныннан кочып алмакчы булды, ләкин Бекки Томны этеп җибәрде дә стенага таба борылып елавында булды. Том аны үгетләргә тотынды, ягымлы сүзләр әйтте, яңадан кочып алмакчы булды, ләкин кызый аны тагын куып җибәрде. Шуннан соң Томда горурлык хисләре уянды. Ул кинәт борылып класстан чыгып китте. Том, әледән-әле ишеккә таба әйләнеп карап, икеләнеп һәм хафаланып озак кына басып торды, Бекки исенә килер дә аның артыннан чыгар дип өметләнде. Ләкин кыз һаман да чыкмады. Томга бик ямансу булып китте: чыннан да гаепле бугай бит ул. Дуслыкка таба беренче адымны атлау аңа бик кыен булды, әлбәттә, шулай да горурлыгын җиңеп ул кире класска керде. Бекки һаман да стенага борылган килеш почмакта елап тора иде. Томның вөҗданы газапланды. Ул Бекки янына килде дә сүзне нәрсәдән башларга белмичә, бераз басып торды.

— Бекки,— дип башлады ул сүзен кыюсыз гына,— мин сине генә яратам, башка берәүне дә белергә теләмим.

Җавап булмады. Үксегән тавыш кына ишетелеп торды.

— Бекки,— дип ялынды малай,— Бекки, бер генә сүз булса да әйт инде.

Кыз тагын үкседе.

Шуннан соң инде Том кесәсеннән иң зур байлыгын — камин рәшәткәсеннән төшкән кечкенә шарын чыгарды һәм кызый күрерлек итеп аңа таба сузды.

— Бекки, менә бу кирәкмиме сиңа, кирәк булса ал,— диде.

Кызый аның кулына сугып җибәрде, шар идәнгә барып төште дә тәгәрәп китте. Шуннан соң Том ныклы адымнар белән атлап мәктәптән чыкты да, бүген инде мәктәпкә яңадан әйләнеп килмәскә ант итеп, аягы атлаган якка таба китеп барды.

Беккиның күңеленә кинәт нindидер бер шомлы уй килде. Ул ишеккә ташланды, ләкин әйләнә-тирәдә Том күренмәде; ул йорт тирәли әйләнеп чыкты. Том уен мәйданчыгында да юк иде. Шуннан соң Бекки:

— Том, кайда син, Том? — дип кычкырырга тотынды.

Ул бераз вакыт тыңланып торды, ләкин аңа җавап бирүче булмады. Тирә-як тып-тын иде. Бекки эскәмиягә барып утырды да яңадан елап җибәрде: кызый үзен гаепле хис итте. Озак та үтми яңадан укучылар җыела башлады; кайгыңны эчеңә яшерергә, челпәрәмә килгән йөрәгеңне тыеп, авыр, озын моңсу көн буена әлеге хәсрәтеңә түзеп торырга кирәк иде; тирә-яктагы кешеләрнең барысы да ят һәм аның кайгысын уртаклашырдай бер кеше дә юк иде.





VIII бүлек

Том башта бер тыкрыктан икенче тыкрыкка борылды, гадәттә, укучылар йөри торган юлдан читкәрәк китәргә тырышты. Аннары аякларын көчкә өстерәп үргә таба менә башлады. Инешне ул юри икеме-өчме тапкыр бер яктан икенче якка ерып чыкты, шулай итсәң, артыңнан куып килүчеләрне юлдан яздырасың, имеш, дип сөйлиләр малайлар. Ярты сәгать дигәндә инде ул Дуглас дигән тол хатынның Кардиф тавы түбәсендәге утары яныннан үтеп китте. Аста, үзәндә утырган мәктәп моннан кечкенә генә булып күренә иде. Том юлсыз җирдән турыга гына урманның эченә кереп китте дә җәелеп үскән имән төбенә, мүкле җиргә барып утырды.

Җилнең әсәре дә юк, коточкыч эсседән хәтта кошлар да тынган, табигать тын-тын булып катып калган, бу тынлыкны берникди аваз да бозмый, сирәк-мирәк кенә кайдадыр еракта тукран тукылдаган тавыш ишетелгәләп куя, әмма ул тавыштан тирә-яктагы тынлык һәм кешесезлек тагын да көчәйгәндәй була. Малайның күңеле тулы сагыш иде, һәм аның кәефе тирә-яктагы табигать халәтенә тәңгәл килә иде. Терсәге белән тезенә таянып, ияген учына салып Том озак кына итеп уйланып утырды. Тормыш аңа иң әйбәт дигәндә дә беткмәс-төкәнмәс хәсрәттер сыман гына тоелды, ул хәтта күптән түгел генә вафат булган Джими Ходҗесның язмышына кызыгып куйды. Тыныч кына кабердә ятып, рәхәтләнеп туйганчы бер хыялланырга була, дип уйлады ул; җиле дә шунда ботаклар арасында шыбырдасын, кабер өстендәге үләннәрне,

чәчәкләрне иркәләсен, сине исә берни борчымый, син берни турында да кайгырмыйсың. Их, менә якшәмбе мәктәбендәге билгеләрең яхшы булсын иде ул, шулай булса үлсәң дә үкенмәс идең, сөйкемсез тормыш белән алыш-бирешеңне өзәргә дә исең китмәс иде... Йә, бу кызыйны гына ал инде син... Нишләде инде Том аңа? Берни дә эшләмәде. Яхшылык кына теләде ул аңа. Ә кызый аны көчекне куып җибәргәндәй куып җибәрде. Кайчан да булса бер үкенер әле ул, ләкин анда инде соң булыр. Их, мәңгегә түгел, вакытлыча гына үлеп торсаң иде ул менә.

Әмма яшь йөрәк ул бик пеше була, киеренке-кысан хәлдә озаклап кала алмый. Том искәрмәстән генә күңеле белән җирдәге тормыш хәлләренә кире кайтты. Менә хәзер үк кая да булса китеп качсаң иде ул. Серле генә рәвештә юкка чыксаң иде. Бик еракларга, диңгезләр артындагы күз күрмәгән, колак ишетмәгән илләргә китсәң, бервакытта да шуннан кире әйләнеп кайтмасаң? Нишләр иде микән ул чакта Бекки?! Том үзенең клоун булырга җыенуын исенә төшерде, әмма хәзер бу турыда уйлау гына да аны чиркандырды, чөнки күңеле белән романтиканың томанлы һәм мәһабәт биеклекләренә күтәрелгән бер мизгелдә шамакайлану, сәвәләйләнү, тәнгә сыланып торган чуар трико киюләр — кешелек дәрәҗәнә тию, үзеңне түбәнсетү булып тоелды. Юк, ул солдатка китәр һәм өенә күп еллардан соң гына, җәрәхәтләргә, данга күмелеп кенә кире әйләнеп кайтыр. Яисә болай булыр: ул индеецлар янына китәр дә алар белән бергә буйволлар ауларга чыгар, сугыш сукмакларын, биек тауларны, Ерак Көнбатышның юлсыз далаларын чигәр һәм кайчан да булса индеецларның бөек юлбашчысы булып өенә әйләнеп кайтыр, йокымсыраган җәйге бер иртәдә каурыйларын тырпайтып, төрле-төрле буяуларга буялган куркыныч кыяфәткә кереп, тамырларыңдагы каннарыңны суытып җибәрердәй кыргый тавыш белән кычкыра-кычкыра туп-туры якшәмбе мәктәбенә килеп керер. Менә иптәшләренең күзе тонар шунда! Барысы да кызыгып карар аңа! Ләкин юк, дөньяда әле аннан да гүзәлрәк юллар бар, юлбасар булыр ул! Әйе, әйе! Шунда ул күзеңнең явын алырлык балкыш булып янган киләчәген күрде. Аның исеме, кешеләрнең котын алып, дөнья шаулатыр. «Да-

выл хәбәрчесе» дигән тәбәнәк озын корабы шомлы кара флаг астында давыллы диңгезләр буйлап дан эстәп йөзәр һәм ул, данының иң югары ноктасына менеп җиткәч, көтмәгәндә-уйламаганда борынгы туган шәһәренә кайтып төшәр: Томның җилдә чыныккан тәнен кояш ашаган, өстенә ул кара бәрхет камзул белән шундый ук чалбар кигән, муенында — алсу шарф, билбавында — пистолет белән канга буяла-буяла тутыгып беткән олы пычак, башында каурыйлары җилфердәп торган йомшак эшләпә булыр, кулында җилфердәгән кара байрагына баш сөяге белән аркылы-торкылы салынган тагын ике сөяк рәсеме төшерелгән булыр. Тирә-якта: «Бу бит — данлыклы юлбасар Том Сойер!» — дип пышылдашканнарын ул ләззәт вә куаныч белән тыңлап торыр.

Әйе, шулай булыр! Менә ул, шулай итеп, үзенә тормыш юлы сайлады. Бу — аның катгый карары. Ул өеннән чыгып качар да яңа тормыш башлар. Иртәгә иртәдән үк. Димәк, моңа хәзердән үк әзерләнергә, бөтен кирәк-яракны җыярга кирәк. Шул тирәдә генә аунап яткан черек агач янына барып, Том пәкесе белән шуның астын казырга тотынды. Казый торгач пәкениндидер бер каты әйбергә килеп төртелде, Том казыган чокырына кулын тыгып җибәрде дә әфсен укып алды:

— Монда булмаган нәрсә бар булсын, булганы урынында калсын! — диде.

Балчыкны кулы белән көрәп бер читкә чыгарды, аста юка гына нарат йомычка күренде. Том йомычканы тартып алды. Асты-өстенә пөхтә итеп йомычкалар куеп ясалган яшерен оянын төбендә бер кечкенә шар ята иде. Малай бу хәлгә чиксез гаҗәпләнде. Ул аптырап баш чүмечен кашып куйды.

— Менә сиңа мә! — диде ул.

Том ачу белән шарчыкны алып ыргытты да уйга калды. Эш шунда ки, башка малайлар кебек ул да бер әфсенгә бик нык ышана иде. Әфсененңе укып шарчыгыңны җиргә күмсәң, кайда гына югалган булса да, ике атна үтүгә башка шарчыкларың да шушысы янына җыелырга тиеш. Баксаң, барысы да юк сүз булып чыкты. Кемнендер шулай итеп уңышка ирешкәнен Томның күп мәртәбәләр ишеткәне бар иде,

ә менә кемнеңдер уңышка ирешә алмавын аның бер дә ишеткәне юк. Югыйсә ничә мәртәбәләр сынап караганы бар, әмма үзенең шарчыгын күмеп куйган урынын бервакытта да таба алганы юк. Уйлап-уйлап торгач ул монда берәр төрле җен-пәринең катнашы булмый калмагандыр дигән карарга килде. Том моны тикшереп карамакчы булды; тирә-юньне караштыра торгач, комда бер уемтык күрде. Җиргә ятып авызын шул уемтыкка куйды да:

— Нәрсәне беләсем килсә, шуны әйт! Коңгыз, коңгыз, коңгызчык, нәрсәне беләсем килсә, шуны әйт,— дип такмакларга тотынды.

Ком кыймыл-камыл килә башлады, ком арасыннан кечкенә генә бер кара коңгыз чыкты да куркынып шундук кире кереп китте.

— Әһә, әйтмисеңме! Чыннан да, монда ничек тә җен-пәрисез булмагандыр, дип уйлаган идем аны.

Җеннәр белән алышу берәүнең дә хәленнән килмәгәнен Том яхшы белә иде, һәм бу эшкә ул кул гына селтәде. Аннары Том, һич югында ыргыткан шарчыкны табарга кирәк, дип уйлады һәм, сабырлыгын җыеп, шуны эзләргә тотынды. Ләкин таба алмады. Ул, әлеге урынга килеп, теге шарчыкны ыргыткан җиргә басты, аннары кесәсендә калган шарчыгын да алып шул ук юнәлештә томырды.

— Агай-эне, бар, туганыңны эзләп тап! — дип сөйләнде ул.

Ул шарчыкның кая төшкәнен искәреп калды һәм барып аны шул урыннан эзләргә тотынды, ләкин таба алмады. Күрәсең, икенче шарчык беренчесе янына йә барып җитмәгән, яисә узып киткән иде. Ул тагын бик озак эзләде һәм, ниһаять, уңышка ирешә: ике шарчык та бер-берсеннән якын гына тәгәрәшеп ята иде.

Шул мәлдә урман авызында уенчык быргы кычкырткан тавыш ишетелде. Том тиз генә курткасын һәм чалбарын салып ыргытты, подтяжкасын биленә буды да аунап яткан черек бүрәнә янындагы чыбык-чабык өемен актарып ташлады. Чыбык-чабык астыннан кулдан ясалган җәя белән ук, агач кылыч белән калай быргы килеп чыкты. Том минут эчендә коралланып алды да күлмәкчән генә дошманына каршы ташланды.

Бер карт карама төбенә барып җиткәч ул җавап сигналы бирде,

аннары, сагаеп тирә-ягына карана-карана, фараз иткән отрядына әкрен генә команда бирде:

— Туктагыз, егетләр, мин сигнал биргәнче засадада калыгыз!

Урман эченнән шундый ук киемнән, шулай ук башыннан-аягына кадәр коралланган Джо Һарпер килеп чыкты. Том аңа:

— Тукта! Минем рөхсәтемнән башка Шервуд урманында йөрергә кем батырчылык итә? — дип кычкырды.

— Һай Һисборн берәүнең дә рөхсәтенә мохтаҗ түгел. Син үзең кем, мондый... мондый...

— Мондый нотык тотарлык кем соң син? — дип әйтеп җибәрде аңа Том: алар китаптан укып ятлаганнарын сөйли иде.

— Ә син үзең кем соң, мондый нотык тотарлык кем соң син?

— Минме? Мин Робин Гуд булам, һәм минем Робин Гуд икәнемә җаныңны суырып кулыңа тоттыргач инанырсың.

— Син, чыннан да, шул атаклы юлбасар буласыңмыни? Алайса мин бик рәхәтләнеп синең белән сугышырга әзер, шунда без бу ямьле урман юлларына кем хуҗа икәнен хәл итәрбез. Башла!

Алар, башка барлык коралларын читкә ташлап, агач кылычларына тотындылар, аякны нык терәп оборона позициясенә бастылар. Һәм, сәнгатьнең бөтен кагыйдәләренә туры китереп, бергәбер кылыч сугышы башладылар. Кинәт Том болай диде:

— Ә хәзер хикмәтнең нәрсәдә икәнен аңлагансыңдыр инде, тизрәк кыймылда!

Һәм алар шундый да тырышып «кыймылдый» башладылар ки, хәтта мышкылдашып, тирләп чыктылар.

Ниһаять, Том:

— Егыл! Егыл инде! — дип кычкырды.— Нишләп егылмыйсың?

— Егыласым килми! Нишләп үзең егылмыйсың? Синә катырак эләкте бит!

— Эләксә соң, шуннан ни булган. Ничек егылыйм ди мин. Китапта бит алай димәгән. Анда болай дигән: «Шунда ул бәхетсез Һай Һисборнны аркасына чәнчеп үтерде». Син артың белән әйләнеп басарга тиеш, шуннан мин синең аркаңа чәнчергә тиеш.

Китап сүзенә каршы килеп булмый иде, шуңа күрә Джо Һар-

пер арты белән әйләнде дә тегесе китереп сугуга гөрселдәп җиргә ауды.

— Ә хәзер мин сине үтерәм,— диде Джо егылган җиреннән тора-тора. Югыйсә болай дөрес булмый.

— Юк, болай ярамый, китапта алай түгел.

— Юк инде, беләсең килсә, дуңгызлык бу, башка берни дә түгел.

— Ярар, Джо, син монах Тэк яисә тегермәнче малае булырсың да мине күсәк белән тукмап ташларсың, яисә мин Ноттингем шәрифе булырмын да син Робин Гуд булып, мине үтерерсең.

Мәсьәләне болай хәл итүдән икесе дә бик канәгать булып калдылар, һәм шушы батырлыкларның барысын да алар башкарып чыктылар. Шуннан соң Том яңадан — Робин Гудка, ә хыянәтче монахка әйләнде. Аннары Джо, берүзе юлбасарлар шайкасын гәүдәләндереп һәм ачы күз яшьләрен агызып елый-елый хәлсезләнеп барган Робин Гуд дигән Томны бер читкә сөйрәп алып китте дә, аның кулына җәя белән угын тоттыргач, Том болай диде: «Шушы ук кая барып төшсә, бичара Робин Гудны шунда үсеп утырган агач төбенә күмәрсез,» — диде. Укны атып җибәргәннән соң чалкан китеп кычытканлыкка барып төшкәч үтә дә зур тизлек белән аягына торып басмаса, ул чыннан да үлгән булыр иде.

Малайлар өсләренә киенеп алдылар да, коралларын яшереп, кайтырга чыктылар. Алар, бүгенге көндә дөньяда юлбасарларның булмавына көенеп, бу югалтуны хәзерге заман цивилизациясе нәрсә белән алыштыра ала икән, дип уйлана-уйлана алга атладылар. Аларның фикеренчә, Кушма Штатларның гомерлек президенты булуга караганда бер елга Шервуд урманында юлбасар булу яхшырак иде.



IX бүлек

Һәрвакыттагыча, ул кичне дә Том белән Сидны унынчы яртыда йокларга озаттылар. Төнгә алар гыйбадәт кылдылар, һәм Сид шунда ук йокыга да китте. Том, сабырсызлануыннан дер-дер калтыранып, күзен дә йоммыйча сигнал көтеп ятты. Менә-менә яктыра да башлар инде дип ятканда ул сәгатьнең унны сукканын ишетте. Ачуың килмәслек тә түгел шул! Яткан җирендә бер яктан икенче якка да әйләнә алмый бит ул. Сидны йокысыннан уятырмын дип курка. Караңгыга күз терәп ул тик кенә ята бирде. Тирә-юньдә эчпошыргыч тынлык хөкем сөрә иде. Аз-азлап кына шул тынлыктан сизелер-сизелмәс булып төрле тавышлар ишетелә башлады. Сәгать тә келт-келт итә иде. Искергән матчалар серле генә итеп чатнагандай булды. Баскыч та шыгырдап куйды. Күрәсең, изге рухлар шулай йөриләр. Полли түткәйнең бүлмәсеннән көйгә салып кына гырлаган тавыш ишетелеп тора. Ул арада эчпошыргыч итеп чикерткә сайравы ишетелә башлады, ә чикерткәнең кайда икәнен син үлсәң дә белә алмыйсың. Аннары карават турында гына стенада үләксә козгынының шомлы итеп кыштырдавы Томның йөрәгенә курку салды: бу бит — озакламый өйдә кем дә булса үләргә тиеш дигән сүз. Аннары төнге җил каяндыр еракта эт улаган тавышлар алып килде, аңа каршы ишетелер-ишетелмәс кенә итеп икенче берсе ерактанрак җавап бирде. Том газаплы минутлар кичерә иде. Вакыт туктап калып, мәңгелек башлануына аның иманы камил иде. Һәм ул ирексездән йокымсырый башлады. Сәгать унберне сукты — ул моны ишетмәде. Шуннан соң инде ул төш күрә башлады, аның шул

төшенә яман итеп мәче мияулаган тавыш килеп кушылды. Күрше өйдә шакылдап тәрәзә ачылуы Томны йокысыннан уятты. «Прәс, каһәре!» дигән тавыш һәм сарай стенасына бәрелеп чылтырап шешә ватылганы ишетелде. Том тиз генә торып минут эчендә киенеп алды, тәрәзәдән чыгып, түбә буйлап үрмәләп китте, җавап итеп бер-ике тапкыр мияулап куйды, аннары, сарай түбәсенә барып җиткәч, шуннан җиргә сикереп төште. Һаклберри Финн, үлгән песиен кулына тоткан килеш, аны аста көтеп тора иде. Малайлар юлга кузгалдылар һәм тиздән караңгылык эченә кереп тә югалдылар. Ярты сәгатьләр узуга инде алар зиарат коймасы буеннан куе үлән ерып баралар иде.

Бу бик борынгы зиарат иде. Мондый каберлекләр Көнбатыш Штатларда бик еш очрый. Шәһәрдән бер ярым чамасы мильдә, калкулык өстенә урнашкан бу зиаратны әйләндереп алган такта койма искереп беткән. Койма урыны-урыны белән эчкәрәк, урыны-урыны белән тышкарак авышкан, бер җирдә дә тигез генә утырмый иде. Каберлек өстен чүп баскан. Иске каберләр инде иңә төшкән. Бер генә кабер ташы да үз урынында тиешенчә тормый; кортлар ашап, череп беткән такталар, терәк эзләп тә таба алмагандай, кабер өстенә авып төшкәннәр. Барлык такталарга да кайчандыр: «Фәләнфәләнгә мәңгелек истәлек итеп» дигән сүзләр язылган булган, әмма андагы хәрефләрне хәзер көпә-көндез дә танып укырлык түгел.

Агач ботаклары арасында җиңелчә генә җил шыбырдады, мазасызлаганнары өчен мәетләрнең җаннары сыкрыйдыр кебек тоелды куркынган Томга. Дуслар бик аз һәм пышылдап кына сөйләштеләр: урын һәм вакыт, тынлык һәм тантаналылык аларның күңеленә авыр тәэсир итте. Тиздән алар әлеге яңа күмелгән каберне эзләп таптылар һәм шуннан берничә адымдагы карама агачы төбенә постылар.

Шактый озак көткән сыман булдылар алар. Үле тынлыкны каядыр еракта кычкырган ябалак кына боза иде. Томның башына берсеннән-берсе күңелсезрәк уйлар килә торды, шул күңелсез уйларны малайның кем белән дә булса сөйләшеп таратасы килде.

— Син ничек уйлыйсың, Һакки,— дип, пышылдап кына башлады ул сүзен,— безнең монда килүебез мәетләргә ошый микән?

Һаклберри да пышылдап кына җавап бирде:

— Кем белә инде аларны! Куркыныч монда... әйеме?

— Әйе шул...

Озакка сузылган тынлык урнашты: малайларның икесе дә шул турыда уйланды. Аннары Том пышылдап кына:

— Карале, Һакки, бу картлач безнең сөйләшкәнне ишетә микән? — дип сорады.

— Ишетә билгеле, һичьюгы аның җаны ишетә.

Бераз тын торганнан соң:

— Кызганыч,— диде Том,— «Уильямс әфәнде» дип әйтәсем калган икән. Ләкин мин бит аны рәнҗетергә теләмәдем. Аны бит барысы да картлач дип кенә йөртә иде.

— Мәетләр турында сөйләшкәндә саграк булырга кирәк шул, Том.

Бу сөйләшү Томның бөтенләй гайрәтен чигерде. Кинәт ул иптәшен иңбашыннан тотып алды:

— Тсс!

— Ни бар, Том?

Алар тыннарын кысып бер-берсенә елыша төштеләр.

— Тсс... менә тагын! Ишетмисеңмени?

— Мин...

— Хәзер ишетәсеңме? Ходаем, киләләр бит, Том! Киләләр! Шулар бит! Нишлибез?

— Белмим. Безне күрерләр дисеңме?

— Их, Том, алар бит караңгыда да мәче кебек күрәләр. Ник кенә килдек!

— Курыкма... Безгә тимәсләр дим мин. Без бит аларга бернинди начарлык та эшләмибез. Шым гына утырсак алар безне бәлки бөтенләй күрмәсләр дә. Ярар, тырышып карыйк алайса... И, Ходаем, бөтен тәнем дер-дер калтырый!

— Тыңла әле!

Малайлар, тын да алмыйча, бер-берсенә тагын да ныграк елыштылар. Каберлекнең аргы башыннан тонык кына булып тавышлар ишетелде.

— Карале әнә тегендә! — дип пышылдады Том.— Ни ул анда?

— Тәмуг уты бит бу! Том, мин куркам!

Караңгыда ниндидер тонык кына шәүләләр пәйда булды. Алларында, җиргә исәпсез-сансыз яктылык очкыннары чәчеп, борынгы калай фонарь чайкала.

— Болары аермачык убырлар инде! — дип пышылдады Һаклберри калтырана-калтырана.— Җитмәсә өчәү бит әле үзләре! Беттек инде болай булгач. Берәр төрле дога белмисеңме ичмасам?

— Маташтырып карыйм, булмаса... Курыкма, безгә тимәсләр алар.

— Тсс!

— Ни бар, Һак?

— Кешеләр бит болар! Һәрхәлдә, берсе — кеше. Тавышы Мефф Поттерныкына охшаган.

— Булмасны!

— Аны гына таныйм инде мин. Син шым гына утыр. Ул безне искәрмәс тә бәлки. Һәрвакыттагыча лыкынганчы эчкәндер әле!

— Ярар. Мин шыпырт кына утырам... Туктап калдылар әле нишләптер. Нидер эзлиләр... Таба алмыйлар. Тагын монда таба киләләр... Күр әле ничек йөгерәләр! Хәзер әнә ничек якын килделәр! Туп-туры монда таба юнәләләр. Карале, Һак, мин икенчесенең дә тавышын таныдым бит — Индеец Джо анысы!

— Чыннан да, каһәр төшкән метис! Бу инде убыр ише генә дә булмас! Беләсе иде, нәрсә кирәк икән аларга монда?..

Пышылдаган тавыш тынды, чөнки әлеге өч кеше кабер янына килеп җитте дә малайлар посып утырган урыннан берничә генә адымда туктады.

— Шушында,— дип, өченче кеше фонарен югары күтәрүгә аның йөзенә ут яктысы төште. Бу кеше — яшь доктор Робинсон булып чыкты.

Поттер белән Индеец Джо баулар, көрәкләр салынган арба өстерәп килгән иде. Әйберләрен җиргә куеп, алар каберне казый башладылар. Доктор, фонарьны кабернең баш очына куеп, карама төбенә барып утырды. Ул малайлардан кул сузымында гына иде.

— Тизрәк, тизрәк! — диде ул, тавышын күтәрмичә генә.— Менә-менә ай калкып чыгарга тора.

Мэфф Поттер белән Индеец Джо җавап итеп нидер мыгырдандылар да казуларында булдылар. Көрәк тиеп чуерташ чытырдаган тавыштан башка шактый вакытлар буена бернинди тавыш та ишетелми торды. Ниһаять, көрәк тонык кына тавыш чыгарып табут капкачына барып тиде, һәм бер-ике минуттан инде Поттер белән Индеец Джо бергәләп табутны кабердән өстерәп чыгардылар. Көрәк белән капкачын каерып ачтылар, табут эчендәге мәетне тупас иттерәп җиргә алып ташладылар. Болытлар арасыннан ай килеп чыкты да мәетнең чырайсыз йөзен яктыртты. Арбаны алып килеп, мәетне шуңа салдылар һәм, одеял белән каплап, бау белән аркылы-торкылы бәйләп куйдылар. Поттер кесәсеннән олы пәке чыгарып бауның очын кисеп ташлады.

— Менә, Тереләй тунаучы әфәнде, бу шакшы эшне бетердек. Тагын биш тәңкә өстәгез, югыйсә бу үләксәне шушында калдырып китәбез.

— Дөрес! Шулай сөйләшергә кирәк алар белән,— диде Индеец Джо.

— Карагыз әле, ни дигән сүз инде бу? — дип, каршы төште аларга доктор.— Сез бит акчаны алдан сорадыгыз, һәм мин сезгә тулысынча түләп куйдым.

— Анысы шулай, тик сезнең әле тагын бурычыгыз бар,— дип башлады сүзен Индеец Джо, докторга таба атлап. Доктор инде хәзер аягүрә торып баскан иде.— Биш ел элек сез мине атагызның аш пешерү бүлмәсеннән, юньле ният белән йөрмисең син монда, дип, ашарга сорап кергән җирдән куып чыгардыгыз; йөз елдан соң булса да мин сездән үч алачакмын дип ант иткәч, атагыз мине, сукбайлыкта гаепләп, төрмәгә утыртып куйды. Әллә онытты дип уйлыйсызмы? Минем тамырларымда юкка гына индеец каны акмый. Хәзер килеп эләктегез менә. Аңладыгызмы инде?

Ул докторга йодрыгын күтәрде. Доктор, кинәт кизәнеп, аңа сугып җибәрде, һәм Индеец җиргә ауды. Шулчак Поттерның кулындагы пычагы төшеп китте дә ул:

— Әй, сез! Тимәгез минем дуска! — дип кычкырып докторга таба атылды, һәм ике арада аяусыз көрәш башланды. Индеец Джо аягына сикереп торды, икенче мизгелдә инде Поттер төшергән пәкене эләктереп алды һәм, уңайлы моментны көтеп, бөтен гәүдәсе белән бөгелә-сыгыла сугыш чукмарлары тирәсендә бөтерелергә керешге. Кинәт доктор, Поттер кулыннан ычкынып китеп, ачык кабердән бер такта эләктереп алды да Поттерны сугып екты; шул ук мәлне, җаен чыгарып, метис кулындагы пәкесен сабына кадәр яшь докторның күкрәгенә батырды. Доктор чайкалып куйды һәм, канга батып, җирдә яткан Поттер өстенә барып төште. Шул вакытта ай болытлар астына кереп китте, һәм бу хәлләр барысы да караңгылык эчендә калды. Котлары алынган малайлар, караңгыда кая басканнарын да белмичә, чабарга тотындылар.

Ай яңадан болытлар астыннан килеп чыккан чакта Индеец Джо, тирән уйга батып, җирдә тәгәрәшеп яткан ике гәүдә өстенә карап тора иде.

Доктор нидер мыгырданып ике тапкыр тирән итеп сулап куйды да бөтенләйгә тынып калды.

— Ярый, шайтан алгыры,— диде метис әкрен генә,— моның белән дә исәп-хисап өзелде.

— Аннары ул, мәетнең әйбер-сәйберләрен җыештырып, үзенә алды. Шуннан соң теге хыянәтче пычакны Поттерның бармакла-

рын җәеп яткан уң кулына салды, үзе ачык табут өстенә барып утырды. Өч минут, дүрт, биш минут үтте, Поттер кыймылдаган-дай итте дә ыңгыраша башлады. Ул кулына салынган пычакны кысып тотты; Поттер аны күзләре янына якын ук китереп җентекләбрәк карады һәм, кинәт сискәнеп китеп, янадан төшереп җибәрде. Шуннан соң ул торып утырасы итте, мәетне үзеннән читкәрәк этеп куйды, аңа күз төшереп алды, аннары ни булганын аңламыйча апты-рап тирә-ягына карангалап алды, һәм аның күзләре Джоның кара-шы белән очрашты.

— Йа Алла, ничек болай килеп чыкты бу? — диде ул.

— Шәп түгел инде,— диде Джо, урыныннан кузгалмыйча.— Ни дип шулай эшләгәнсеңдер?

— Минме? Нишләп мин булыйм?!

— Сөйләнеп торма, ансат кына котыла алмассың барыбер.

Поттерның чырае качты, ул дер-дер калтырана башлады.

— Айнып өлгерермен дип уйлаган идем мин. Бүген миңа эчәргә генә түгел иде югыйсә. Хәзер дә башым шаулап тора, монда кил-гәндәгедән дә начаррак. Мин томан эчендә сыман — берни дә хәтер-ләмим. Әйт әле, Джо, дөресен генә әйт әле, дустым, шулай ук аны мин дөмектердеммени? Үтерергә уйлаганым да юк иде бит, әйт әле, Джо, ничек килеп чыкты соң бу? Нинди мәтәвек! Ходаем, ул шун-дый яшь иде әле... Өметле күренә иде...

— Сез икегез бәйләнешеп киттегез дә, ул синең башыңа так-та белән кундырды, син әйләнеп барып төштең. Аннары сикереп тордың, үзең чайкала-чайкала аягыңда көчкә басып торасың, ул сиңа тагын сугам дигәндә генә кинәт пычагыңны аның эченә кертеп чыгардың. Шуннан соң икегез дә җиргә авып үлгән кешеләр сыман хәрәкәтсез калдыгыз.

— Их, мин бит нишләгәнемне дә белмим. Шул хак булса, ни йөзең белән яшәргә кирәк? Аракы аркасында инде барысы да — исерек тә булганмын, өстәвенә кызып та кителгәндер... Соң мин бит әле аны, пычакны тота да белмим, Джо! Сугышырга туры килгәне бар-ба-рын, анысын яшермим, әмма пычак белән түгел, йодрык белән генә. Моны сиңа теләсә кем раслар... Джо, кешегә сөйли күрмә инде, яме!

Сөйләмәскә вәгъдә бир, Джо, шәп егет бит син, Джо. Мин сине һәрвакыт якын итә идем һәм һәрвакыт сине яклый идем, хәтерендәме? Гел дә исеңдә юкмыни, Джо? Берәүгә дә сөйләмәссең бит, Джо?

Бичара адәм кулларын югары күтәреп, инәлеп бәгырьсез катыйль алдына тезләнде.

— Ярар, Мэфф Поттер, син миңа карата һәрвакыт намуслы булдың, миңа кешечә карадың, мин сине берәүгә дә сатмам. Аны гына эшли алам инде мин. Тыныч бул, сүземдә торырмын. Монда инде сүз куертып маташуның кирәге дә юк.

— Фәрештә син, Джо, валлаһи дип әйтәм! Гомерем буе рәхмәт укырмын...

Һәм Поттер елап җибәрде.

— Йә, җитәр! Елап утырыр чак түгел. Бар, син әнә теге юлдан кит, мин монысыннан китәм. Кара аны, артыңнан дәлил булырдай әйбер калдырасы түгел.

Поттер кызу-кызу атлап китеп барды, аннары, адымын тагын да тизләтә төшеп, бар көченә йөгерә башлады. Метис аның артыннан озак кына карап торды, аннары үзалдына сөйләнеп куйды:

— Башына сугудан шулай миңгерәгән булса, өстәвенә ләх исерек килеш пычакны хәтеренә төшерми инде ул.. Исенә төшсә дә, ул аны алырга зиратка кире килергә курка — куян йөрәк бит ул.

Ике-өч минут үтүгә, үле докторга, одеялга төрелгән мәеткә, өсте ачык табут һәм казып ташланган кабергә күктән ялгыз ай гына карап тора, тирә-юньдә исә янадан үле тынлык хөкем сөрә иде...



X бүлек

Малайлар, куркудан тыннары бетеп, бар көчләренә шәһәргә чаптылар. Куа килмиләр микән, дигәндәй, вакыт-вакыт шомланып артларына борылып карадылар. Каршыларына очраган агач төбе аларга дошман сыман булып күренде. Куркудан малайларның тәмам хәлләре бетте. Малайлар шәһәр читендәге агач өйләр буеннан узып барганда йокыларыннан уянган этләр һау-һаулап өрә башлады. Шул эт өргән тавыш малайларга канат чыгаргандай булды.

— Тире заводына хәтле генә булса да барып җитәсе иде,— диде Том, көчкә сулышын алып.— Шуннан арысы булмый...

Һаклберри ни дип тә җавап бирә алмады: нык йөгергәнгә аның да тыны беткән иде. Малайлар, заводтан күзләрен дә алмыйча, бар булган көчләрен җыеп, шунда таба чаптылар. Ниһаять, алар барып җиттеләр һәм, ачык ишектән икесе берьюлы барып кереп, гөрселдәп идәнгә аудылар. Шушы иске бина эченә килеп керә алуларына алар бик сөенделәр, ләкин бик арыганнар иде инде. Бераз тын алгач Том:

— Һаклберри, син ничек уйлыйсың,— ни белән бетәр икән бу эш?

— Доктор Робинсон үлә калса, дар агачы белән бетәчәк.

— Син шулай булыр дип уйлыйсыңмы?

— Уйлап та торасы юк, шулай буласын беләм инде мин аның.

Том уйга калды, аннары тагын сорап куйды:

— Ә кем әләкләр? Безме?

— Ни сөйлисең син! Андый хәл була калса, Индеец Джоны асып куймасалар, ул безнең башыбызга җитәчәк бит. Бүген булмаса, соңыннан. Бусы инде көн кебек ачык.

— Мин үзем дә шулай дип уйлыйм, Һак.

— Әләкмисе булса әнә Мэфф Поттер әләкләсен; шундый ахмак икән инде, өстәвенә көн-таң атса сәрхуш, ә сәрхушкә нәрсә аңа — диңгез тубыктан!..

Том эндәшмәде; ул тагын уйга калды. Ниһаять, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп:

— Һак, ә бит Мэфф Поттер берни дә белми,— диде.— Ничек итеп әләкләсен ул?

— Нишләп белмәсен?

— Шулай менә: Индеец Джо пычакны нәкъ менә доктор кабер тактасы белән Поттерны сугып екканда кадады. Ничек күрсен ул? Каян белсен ул үтерү турында?

— Карале, чыннан да шулай булып чыга бит әле бу, Том!

— Аннары син шунысын да уйла — бәлки шул сугудан Поттер үзе дә мәрхүм булгандыр.

— Юк, Том, анысы — ай-һай! Эчкән иде бит ул. Мин анысын шундук искәреп алдым. Аннары бит ул гомумән дә гел аек булмый. Әнә минем әткәйне генә ал... Салган чакта хет имән күсәк белән дөмбәслә син аны... пычагым да булмый үзенә. Валлаһи менә! Үзенең дә ничә тапкыр сөйләгәне бар. Димәк, Мэфф Поттер да шулай инде. Әгәр дә Поттер аек булса, андый ук «сыйдан» үлеп тә киткән булыр иде... кем белә бит...

Янадан тынлык урнашты, Том кабат үзенең уйларына чумды.

— Һакки, ә син ялгыш ычкындырмассыңмы соң? — дип сорады ул, ниһаять.

— Теләсәң-теләмәсәң дә безгә телне тыярга кирәк булачак. Ул иблис Индеецны үзең беләсең... Без әләкләп, аны асып куймасалар ул безне песи балалары сымак суга батырып үтерәчәк. Беләсеңме нәрсә, Том! Әйдә без, телебезне тыябыз дип, бер-беребезгә ант итик. Иң дөресе шул булыр.

— Мин риза, Һак. Иң яхшысы шул булыр. Әйдә, җитәкләшик тә ант итик...

— Юк, мондый эштә алай гына ярамый... Юк-бар эштә ярый ул, әйтик, кызлар белән бер-бер эшкә бәйләнсәң, әләгә-нитә калсалар

ахыр чиктә барыбер телләрен тыя алмыйлар, әмма ләкин мондый эштә язмача ант итәргә кирәк. Һәм ул ант сүзләре кан белән язылырга тиеш.

Мондый фикер Томның күңеленә бик тә хуш килде. Болай итү серле дә, куркыныч та, шомлы да иде: төнге тынлык, әлеге вакыйга, тирә-юньдәге шомлылык — болар барысы да бер-берсен тулыландыра, серлелекне көчәйтә төшә иде. Том иләннән ай яктысында ап-ак булып ялтырап яткан чиста нарат йомычкасын алды, кесәсеннән кызыл буяу кисәге чыгарып, яктылык йомычкага төшәрлек итеп җайлап утырды да бик авырлык белән генә тырнап түбәндәге сүзләрне язып куйды:



Басым белән язган чакта ул телен тешләп, нечкә итеп язган чакта телен чыгарып язды.

Томның матур сүзләр табып, шулхәтле әйбәт итеп яза белүенә Һаклберри Финн чын күңеленнән сокланды. Ул, курткасының якасы астына кадап куелган булавкасын алып, бармагына кадамакчы гына булган иде, бу эшеннән аны Том туктатты:

— Туктале, булавкаң бакыр бит синең, аның агулы булуы мөмкин.

— Нинди агу ул?

— Шундый инде, бакыр әйберләрдән чыга ул. Бер генә тамчысын йотып карасаң да — ни икәнен белерсең.

Том бер энәсенең җебен сүтте дә, малайларның һәрберсе, энә белән баш бармагына кадап, берәр тамчы канын кысып чыгарды.

Шушы эшне берничә тапкыр кабатлагач Том чәнчә бармагы белән үз исеменең баш хәрефен язды. Аннары Һаклберрига Һ һәм Ф хәрефләренең ничек язылуын күрсәтте дә, шуның белән эш тәмамланды. Алар, төрле йолалар башкарып һәм төрле әфсеннәр укып, йомычканы стена буена күмеп куйдылар. Инде хәзер телләр бәйле, богаулар нык иде, һәм аның ачкычы еракларга ыргытылды дип исәпләргә була иде.

Шул мизгелдә җимерек бинаның аргы башындагы тишектән эчке якка таба бер шәүлә үтеп керде, ләкин малайлар аны искәрмәде.

— Том,— дип пышылдады Һаклберри,— серебезне тота алырбыз микән инде без?

— Әлбәттә тота алырбыз. Хәзер инде ни генә булмасын, без дәшмибез. Югыйсә бит шундук безне җир йотачак. Аңладыңмы?

— Әйе, мин үзем дә шулай уйлыйм.

Том аңа ни турындадыр бик озак итеп пышылдап маташты. Кинәт шомлы итеп сузып эт улап җибәрде, бик якында гына, унлап адымда гынадыр. Малайлар котлары алынып бер-берсенә елыштылар.

— Кемгә улый икән ул? — дип, көчкә генә сулышын алып пышылдады Һак.

— Белмим... Ярыктан карап ал әле. Тизрәк бул!

— Юк, син кара инде, Том!

— Карый алмыйм шул, Һак!

— Кара инде, Том... Әнә, тагын улый!

— И, Ходайга шөкер! — дип пышылдады Том,— мин аны тавышыннан таныдым. Харбисоннар эте бит бу.

— Алай булса ярый, югыйсә мин куркуымнан үләм дип торам. Бердәк эттер дип уйлаган идем.

Эт яңадан улый башлады. Малайларның коты ботына җитте.

— Ай, бу бит ул түгел! — дип пышылдады Һаклберри.— Карале, Том.

Том куркуыннан калтырана-калтырана ярыктан карады һәм ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады:

— Ой, Һак, бу бит бердәк эт!

— Карале, Том, карале тизрәк кемгә өрә икән ул?

— Безгәдер инде. Без бит инде якында гына.

— Их Том, бетте баш! Минем кая барып эләгәсем билгеле инде. Мин шундый әшәке, эт инде бер...

— Чәнчелеп кенә китсен! Шулай була ул менә дәресеңнән качып, кушмаганны эшләп йөрсәң... Тырышсам мин дә Сид кебек әйбәт була алыр идем югыйсә; юк шул, тырышмадым... Бу юлы исән калсам, якшәмбе мәктәбендә куна-төнә ятар идем!

Том әкрен генә сулкылдый башлады.

— Синме ул начар малай? — дип, Һаклберри да мышкылдый башлады.— Син, Том Сойер, минем белән чагыштырганда фәрештә бит, фәрештә. Ходаем, синдәге тәрбиялелекнең яртысы гына булсын иде миндә!

Том күз яшен йотып җибәрде дә:

— Карале, Һак, кара! — дип пышылдады.— Ул безгә таба арты белән утыра!

Һак караган иде, күңеле шатлык белән тулды:

— Әйе шул, арты белән утыра... Менә шәп! Ул башта да шулай утыргандыр инде.

— Шулайдыр шул, ә мин, юләр, искәрмәгәнмен. Менә бит ничек! Ләкин кемгә улый соң ул?

Эт улаган тавыш тынып калды. Том колагын торгызып тыңлана башлады.

— Тсс! Ни бу? — дип пышылдады ул.

— Дуңгыз мыркылдаган сыман... Юк, Том, кемдер гырлый бит...

— Чыннан да! Кайда гырлый соң ул, Һак?



— Теге башта бугай. Һәрхәлдә, шунда булырга охшаган. Кайчакта дуңгызлар белән бергә әткәй шунда куна торган иде минем, ләкин бу әткәй түгел. Ул түбәне күтәреп китәрдәй итеп гырлый торган иде. Аннары ул инде бу якларга кайтмас дип уйлыйм мин.

Малайларның тагын да кызык күрәселәре килде.

— Һак, карап килиекме? Курыкмыйсыңмы?

— Никтер карыйсым килми. Том, әгәр ул Индеец Джо булса? Том шүрләп калды. Әмма ки кызыксыну көчлерәк булып чыкты: малайлар барып карарга булдылар, әгәр дә гырлаган тавыш иштелми башласа, шундук кире торып чабарга сүз куештылар. Сиздермичә генә, аяк очларына гына басып, алар йоклап яткан кеше янына таба атладылар, Том — алдан, аның артыннан — Һак. Барып җитәргә берничә адым калгач Том аяк астындагы бер чыбыкка китереп басты; чыбык шартлап сынган тавышка йоклап ятучы ыңгырашып куйды, бер ягыннан икенче ягына әйләнеп ятты, һәм аның йөзе ай яктысы

төшкән җиргә туры килде. Бу кеше Мэфф Поттер булып чыкты. Малайларның тәннәренә суык йөгергәндәй булды, алар теге кеше кыймылдап куйгач курка калганнар иде, хәзер инде куркулары качты. Малайлар иләп кенә ярым җимерек ихатадан чыгып, берничә адым үттеләр дә, инде аерылышабыз дигәндә генә, кинәт төнге тынлыкта шомлы итеп тагын эт улый башлады. Борылып карагач Поттер яткан турдан берничә генә адымда ниндидер бер ят этнең басып торганын күрделәр, ул Поттер ягына таба карап улый иде.

Малайлар икесе берьюлы:

— Поттерга таба карап улый! — дип, кычкырып җибәрделәр.

— Беләсеңме, Том, Джонни Миллерлар турына килеп төн уртасында бер берәдәк эт улаган, дип сөйлиләр,— моннан ике атналар элек булган инде ул, шул ук кичне аларның баскыч култыксасына кунып бер төнге күгәрчен сайраган. Моңа карап аларның бер кешесе дә үлмәде бит әле.

— Әйе, беләм мин боларны. Үлмәсен дә ди, ә бит Грэси Миллер шул атнада шимбә көнне камин өстенә егылып бик каты пешкән, ди.

— Пешсә дә, үлмәгән бит әле. Терелеп тә килә ди инде.

— Менә күрерсең әле ни булганын. Аның хәле шәптән түгел, үләр диләр аны. Мэфф Поттер да үләр. Негрлар сүзе бу, алар әйткән сүз раска чыкмый калмый.

Шуннан соң малайлар бик нык уйга калып аерылыштылар.

Том кайтып йокы бүлмәсенең тәрәзәсеннән кергәндә инде төн үтеп бара иде. Өс-башын ул бик иләп кенә чишенде һәм йокы аралаш бүгенге эшләкләре турында берәүнең дә сизмәве белән үзен котлады. Әкрен генә гырлап яткан Сидның чынында инде берәр сәгать чамасы уяу ятканы аның башына да килмәде.

Том уянганда Сид киенеп чыгып киткән иде инде. Кояшка һәм бүлмәдәге яктылыкка караганда вакыт инде шактый соң булырга тиеш иде. Том бик гаҗәпләнде: нишләп аны һәрвакыттагыча уятмаганнар да, нишләп торгызмаганнар? Бу уй аның күңелендә яман шикләр тудырды. Бик йоклыйсы килсә дә һәм бөтен тәнендә ары-

ганлык сизсә дә ул, минут эчендә киенеп, аска төште. Иртәнге аш инде тәмамланган булуга да карамастан, гаилә әле өстәл яныннан кузгалмаган иде. Томны берәү дә әрләмәде, шул ук вакытта берәү дә аңа таба борылып та карамады, өстәл янында шомлы тынлык һәм ниндидер киеренкелек хөкем сөрә иде, хәтта ки Томның тәннәре чымырдап китте. Ул үзенең гадәттәге урынына килеп утырды һәм шат күңелле булып күренергә тырышты. Тик тырышуы юкка гына булып чыкты — аңа берәү дә кушылмады, берәү дә җавап бирмәде! Берәү дә елмаеп карамады, шунлыктан аның үзенең дә теле аңкавына ябышкандай, җаны табан астына төшкәндәй булды.

Иртәнге аштан соң Полли түткәй аны үз янына чакырды, Томның күңеле күтәрелеп китте: бер ярырлар да эш шуның белән бетәр дип уйлады ул, ләкин хәл ул көткәннән начаррак булып чыкты. Полли түткәй җылый-җылый зарланырга тотынды. Ничек инде Том аның карт йөрәген шушы хәтле дә җәберли ала, дип сорады ул. Аннары ул, моннан соң инде теләсәң нишлә дип, Томның үз ихтыярына куйды: теләсәң үзеңне харап итәсең, теләсәң карт түтаңны кабергә кертәсең, теләсәң аның чал башына хурлык китерәсең — хәзер инде сине барыбер төзәтеп тә булмас, һәм түтаң яңадан тырышып та азапланмас. Мең кат суктырудан да читенрәк иде бу. Томның тәненнән бигрәк йөрәге сыкрый иде. Том җылап җибәрде, гафу үтенде, төзәлермен дип яңадан-яңадан сүзләр бирде... Ниһаять, Томның үз иркенә куйдылар, ләкин малай үзенең тулысынча гафу ителмәвен һәм аңа карата ышанычның да элеккечә булмавын тоя иде.

Үзен шулхәтле дә бәхетсез хис итеп Том түтасы яныннан чыгып китте, аның хәтта Сидтан үч аласы да килми иде, һәм Сидныңкача-поса арт капкадан чыгып сызуының бөтенләй дә кирәге юк иде. Күңеле төшкән Том кайгыга батып мәктәбенә китеп барды. Анда аңа, Джо Һарпер белән бергә кичә дәрестән качканы өчен, сыек чыбык ачысын татырга туры килде. Чыбык белән суктырган чакта ул тамчы да дәрәҗәсен төшермәде, тагын да авыррак кайгысы булган кеше шикелле, мондый гына вак-төяккә исе китмәгәндәй кыланды. Урынына килеп утыргач, ул, терсәгенә таянып, ияген учына

салды, соң дәрәҗәдә җәберләнгән кеше кыяфәтендә карашын стенага төбәде. Терсәге астында ул ниндидер бер каты әйбер барлыгын тойды. Том бик озак аны күрмәскә тырышып утырды, аннары, авыр сулап, ашыкмыйча гына әлеге әйберне кулына алды. Әйбер кәгазьгә төрелгән иде. Том аны сүтеп җибәрде һәм озын, авыр итеп, күкрәк түреннән үк көрсенеп куйды,— аның соңгы өмете челпәрәмә килде. Бу — камин рәшәткәсеннән төшкән теге бакыр шарчык иде.

Болай да телгәләнгән йөрәккә монысы инде соңгы кизәнү булды.





XI бүлек

Төш вакыты җитәрәк кинәт бөтен шәһәргә коточкыч хәбәр таралды. Телеграфның да хаҗәте булмады, хәер, ул чакта аның турында хыялланучы да юк иде әле; бу хәбәр телеграф тизлеге белән диярлек кешедән кешегә, төркемнән төркемгә, өйдән өйгә күчте. Дәресләрнең яртысы үтүгә укытучы балаларны өйләренә кайтарып җибәрде: кайтарып җибәрмәсә, бөтен шәһәр бик тә сәерсенгән булыр иде.

Үтерелгән кеше янында канлы пычак табылган. Сөйләүләргә караганда, кемдер бу пычакның Мэфф Поттер пычагы икәнен таныган. Төнлә, сәгать икеләр тирәсендә, бик соңарып өенә кайтып баручы берәү Поттерның инештә юынып маташканын күргән, имеш. Әлеге кешене күрүгә, имеш, Поттер шундук каядыр юкка чыккан, бу бик тә шикле булып тоелган, чөнки Поттер гомумән юынырга гадәтләнмәгән. Үтерүчене эзләп инде бөтен шәһәрне айкаганнар, имеш, (обывательләр гадәттә дәлилләрне бик тиз табучан һәм хөкемне дә бик тиз чыгаручан булалар), ләкин бер җирдән дә таба алмаганнар. Төрле тарафларга җайдаклар чыгып чапканнар һәм аларның җинаятьчене төнгә кадәр таба алуларына шәриф бик нык ышана икән.

Бөтен шәһәр каберстанга таба агылды. Том, үзенең телгәләнгән йөрәге турында да онытып, кешеләр төркеменә барып кушылды — шундый теләге булганга түгел, ул моннан меңнәрчә миль ераклыкта булырга теләр иде, югыйсә. Томны аңлашылмый торган котылгысыз бер көч шунда таба тарта иде.

Бу шомлы урынга килеп җиткәч, кешеләрне аралап ул алга таба үтте һәм коточкыч тамашага тап булды. Шулчак кемдер аның кулын чеметеп алды. Борылып карауга күзләре Һаклберри белән очрашты. Шундук икесе ике якка караган атлы булды, үзләре исә, карашып алуларын күрүче булмады микән, дип, куркуга калдылар. Әмма һәркем, бу коточкыч тамашадан күзен алалмыйча, үзара гәп куерту белән мәшгуль иде. Төрле яктан:

— Бичара! Бәхетсез адәм!

— Кабер талаучыларга сабак булсын!

— Тотуын тотсалар, Мэфф Поттерны асалар инде,— дигән тавышлар ишетелде.

Пастор исә:

— Ходай тәгалә хөкеме бу; Аллаһы Тәгалә кулы! — диде.

Томның бөтен тәне калтыранып куйды, чөнки шул мәлдә аның күзе Индеец Джоның катып калган йөзенә төште. Тора-бара халык төркеме ярсып-ярсып дулкынлана башлады һәм бер якка таба сөрлегеп куйды.

— Әнә ул! Ул үзе килә монда! — дигән тавышлар ишетелде.

— Кем? Кем ул? — дип үкерде егермеләп тавыш.

— Мэфф Поттер!

— Карагыз әле, туктап калды... Качмакчы була! Ычкындыра күрмәгез!

Агач башына менеп утырган малайлар Мэфф Поттерның качарга ниятләп тә карамаганын әйттеләр.

— Хәттин ашкан оятсызлык бит бу! — диде тамашачыларның берсе.— Үзе кылган явызлыкка тыныч кына карап сокланып торырга дип килгән... Монда халык булыр дип уйламаган, күрәсең.

Халык төркеме артка таба чигенде, һәм кабер янына, тантаналы атлап, Поттерны кулыннан җитәкләгән шәриф килде. Бәхетсез адәмнең йөзе сулыгып калган, күзләрендә газаплы курку. Мәетне күрүгә ул паралич суккан кеше сыман калтырана башлады, йөзен кулы белән каплады да җылап җибәрде.

— Минем эш түгел бу, дусларым,— диде ул, үкереп җылыйҗылый,— валлаһи дип әйтәм минем эш түгел...

— Кем әйтә соң әле синең эш дип? — дигән тавыш ишетелде һәм Поттер битеннән кулын алды да тирә-ягына карады. Ул нинди дә булса игелек көтүдән өметен өзгән иде. Индеец Джоны күрүгә ул кычкырып җибәрде:

— Йә инде, Индеец Джо! Син бит вәгъдә биргән идең...

— Бу сезнең пычакмы? — дип, шәриф пычакны аның алдына куйды.

Әгәр дә тотып алып, ипләп кенә җиргә утыртмасалар, Поттер баскан җирендә егылып киткән булыр иде. Аннары ул:

— Күңелемә килгән иде, әгәр монда әйләнеп килеп нине тапмасам...— диде. Ул калтыранып куйды, өметсезлек белән кулын селтәп:

— Әйт инде, Джо, әйт дөресен,— хәзер инде эндәшми торудан ни мәгънә...— диде.



Һаклберри белән Томның котлары очты, алар күзләрен алмыйча миһербансыз ялганчының әлеге үтереш турында салкын кан белән бәйнә-бәйнә хикәя кылуын тыңлап тордылар, алар менә-менә аяз көндә күк күкрәр дә бу ялганчыны яшен сугып үтерер дип көттеләр. Ләкин сөйләп бетергәннән соң да аның исән-сау басып торуын күргәч, аларның күңелендә, антларын бозып, нахакка гаепләнә торган бичара Поттерның тормышын коткарып калу теләге туды, ләкин ул теләк шундук сүрелде һәм тиздән бөтенләй юкка чыкты, чөнки алар Джо-бәдбәхетнең җанын шайтанга саткан булуын аңладылар, ә җен-пәриләр белән шаярып булмый, алар эшенә тыгыла калсаң, шундук юкка чыгасың.

Кемдер берәү Поттердан:

— Нишләп соң син качмадың? Ник килдең соң монда? — дип сорады.

— Мин башкача... булдыра алмадым,— дип, ыңгырашып куйды Поттер.— Качмакчы да булган идем, аякларым үзләре монда китерде...

Һәм ул тагын үкереп җылый башлады.

Берничә минуттан соң суд тикшерүендә Индеец Джо, шундый ук салкын кан белән ант эчеп, әлеге мәгълүматларын кабатлады. Малайлар, аны һаман да яшен сукмавын күреп, җанын шайтанга саткан булуына тәмам инандылар. Индеец Джо алар өчен хәзер дөньяда иң куркыныч һәм иң кызыклы кешегә әйләнде, алар икесе дә, күзләрен алалмыйча, аңа сокланып карап тордылар. Җае чыкканда аны төннәрен дә күзәтергә кирәк дип уйладылар, аның хуҗасы булган шайтанны сыңар күзләре белән генә булса да күрәселәре килде.

Индеец Джо мәетне күтәреп алып повозкага салырга булышты. Төркем дулкынланып куйды: нәкъ шушы мәлдә, ярадан кан саркып чыкты, дип пышылдаштылар. Малайлар, инде чын үтерүченең кем булуы ачыклана, дип кенә уйлаганда, аларның өметләре өзелде, чөнки кешеләрнең күбесе:

— Мэфф Поттер мәеттән өч адымда гына торганга күрә шулай булды,— диештеләр.

Коточкыч сер һәм вөҗдан газабы атна буена Томга төннәрен йокларга ирек бирмәде. Һәм бервакыт иртә белән иртәнге аш вакытында Сид аңа болай диде:

— Том, син төнлә шулхәтле боргаланасың, йокы аралаш әллә ниләр сөйләнәсең, шуның аркасында мин йоклый алмый ятам...

Том агарынып күзләрен аска төшерде.

— Бу бик начар фал,— диде Полли түткәй үтә җитди итеп.— Ниләр уйлыйсың син, Том?

— Берни дә уйламыйм, түткәй!

Ул, кулы калтырап, кофесын эскәтергә түкте.

— Үзең шундый юк нәрсәләр сөйлисең,— дип дәвам итте Сид,— бүген төнлә, мәсәлән: «Кан бу! Кан! Менә нәрсә ул!» — дип кычкырдың. Кабат-кабат шуны әйтәсең. Аннары: «Интектермәгез мине —

барысын дә сөйләп бирәм»,— дип кычкырасың. Нәрсә сөйләмәкче соң син? Нәрсә?

Томның күз алдындагы бөтен нәрсә әйләнә башлады. Ни булып бетәсен әйтүе авыр иде, әмма, бәхеткә каршы, Полли түткәйнең йөзендәге борчылу билгеләре юкка чыкты, һәм ул, үзе дә белмичә, Томга ярдәмгә килде:

— Аһ! Бу һаман шул коточкыч үтереш аркасында. Минем үземнең дә көн саен диярлек төшемә керә ул. Кайчакта төшемдә үтерүче мин үзем икән дим.

Мэри дә үзенең шундый ук хәл кичергәнен аңлатты. Сид шушындый аңлатудан канәгатьләнгәндәй булды. Том болардан тизрәк котылу ягын карады, шуннан соң атна буена теш сызлый дип зарланды һәм ияген төнгә яулык белән бәйләп куя торган итте. Ул Сидның төннәрен юри йокламыйча ятканын белми иде; Сид еш кына Томның яңагын бәйләгән яулыгын бушайтып, терсәгенә таяна да аның ни сөйләгәнен карап тора иде. Ә Том моны сизми; аннары Сид яулыкны тагын элеккечә бәйләп куя. Әкренләп Том тынычланды, теш сызлавы да туйдырды, һәм ул аны бәйләмәс булды. Томның өзек-төтек мыңгырдауларыннан ниндидер нәтиҗә чыгарган булса да, Сид аларны эчендә калдырды. Сабакташлары үлгән песиләр өстеннән тикшерү алып баруны бервакытта да туктатмаслар һәм аның күңелен борчыган нәрсәне бервакытта да оныттырмаслар кебек тоелды Томга. Моңарчы бөтен уеннарда төп рольләрне башкарырга яраткан Томның бу уенда баш тикшерүче ролен алмавын Сид абайлады, әлбәттә. Аннары Томның шаһит булу роленнән баш тартуын күңеленә салып куйды, монда да ниндидер сәерлек бар иде. Сид шуны да искәрми калмады: Том, гомумән, бу уеннарны сөйми башлады һәм җае чыгу белән алардан баш тарту ягын карады. Сид бу табышмаклар хакында баш ватты, ләкин уйларын берәү белән дә уртаклашмады. Хәер, ахыр чиктә мондый уеннар модадан чыкты һәм Томның вөҗданын газапламый башлады.

Бу борчулы көннәрдә Том көн саен диярлек, яисә көн аралаш-мы, җаен табып, төрмәнең рәшәткәле бәләкәй тәрәзәсе янына килеп, кулга төшерә алган азык-төлеген шуның аша «кеше үтерүче»гә

китереп бирә торган булды. Төрмә булып шәһәр читендәге сазлык буена урнашкан бер кыяфәтсез генә кирпеч бина хезмәт итә иде. Каравылчысы юк иде аның, хәер, анда тоткыннар да булмый торган иде. «Кеше үтерүче»гә илткән шул кечкенә генә күчтәнәчләр Томның күңелен шактый тынычландыра төште.

Дегеткә манып, тавык йонына аунатып, таякка атландырып, шәһәр читенә алып чыгып җәзаларга бик теле иде халык Индеец Джоны. Әмма аңардан куркулары шулкадәр көчле иде ки, әлеге эшне башлап йөрердәй кыю кеше һич табылмады. Сорау алуларның икесендә дә метис үзенең сүзен сугыша башлаган җирдән башлады, мәет урларга маташулары турында авызын да ачып карамады, шуңа күрә билгеле бер вакытка кадәр аны судка тартмый торырга карар иттеләр.



XII бүлек

Әлеге борчуларыннан тыш, Томның яңа мәшәкатьләре килеп чыкты: Бекки Тэтчер мәктәпкә йөрми башлады. Берничә көн буена Том горурлыгы белән көрәште, Беккины сагынуын онытырга тырышты, әмма, ниһаять, аның сабырлыгы төкәнде. Кичләрен ул, үзен бик бәхетсез тоеп, Беккиның өе тирәсендә буталып йөри башлады. Кыз авырып киткән иде. Әгәр дә ул үлә калса? Менә шушы фикер Томның рухын төшерде дә инде. Ул инде хәзер сугышлар белән дә, пиратлар белән дә кызыксынмый иде. Аның өчен дөньяда яшәүнең бөтенләй яме бетте, тормыш тоташ күңел боеклыгы, гел кайгы-хәсрәт кенә булып калды. Ул кыршау белән таягын да ыргытты: алар аңа бернинди рәхәтлек китерми башлады. Полли түткәй пошаманга калды, малайга төрле дарулар эчертеп карады. Полли түткәй патентлы чаралар белән һәм сәламәтлекне ныгыту өчен дип чыгарыла торган һәртөрле яңа дарулар белән мавыгучылар рәтенә керә иде. Дәвалау буенча ул армый-талмый һәртөрле тәҗрибәләр үткәрә иде. Бу өлкәдә нинди дә булса яңа чара килеп чыга калса, аны шундук сынап карарга тырыша. Ләкин сынауны үз өстендә үткәрми, чөнки ул үзе бервакытта да авырмый. Монда инде тәҗрибә ясау өчен кул астындагы берәр кешене файдаланырга кирәк була. Түткәй бөтен медицина журналларын һәм френологларның шарлатан брошюраларын алдыра, шома тел белән язылган шул надан язмалардан башка яши дә алмый. Бүлмәне ничек җилләтергә, йокларга ничек ятарга, ничек торырга, нәрсә ашарга, ни эчәргә, һавада күпме йөрергә, кәефеңне нинди хәлдә тотарга, нинди кием киярргә — җыен

шундый сафсатаны ул изгеләр сүзе кебек чынга ала, ә үзе медицина журналларының кичәге сүзләрен бүген үзләре үк юкка чыгарганны искәрми дә. Полли түткәй бик саф күңелле һәм беркатлы кеше, шуңа күрә ул тегеләрнең кармагына бик тиз эләгә.

Су белән дәвалау ул вакытларда әле модага кереп кенә бара иде, һәм Томның кәефсезләнүе Полли түткәй өчен чын-чынлап табыш булды. Ул аны иртә таңнан уятып утын сараена алып чыгып китә дә башыннан ук боздай салкын су белән коендыра, аннары тәнен кытыршы сөлге белән ышкып, юеш җәймәгә төреп урынына сала һәм җиде кат тир акканчы ятқыра. Томның үз сүзе белән әйтсәк, «җаны сары тапка әйләнеп, тиресе аша чыгып беткәнче» тота.

Шушы чараларның барысына да карамастан, малай һаман саргая, ябыга барды, күңеле бер дә күтәрелмәде. Тутасы элекке дәвалары өстенә тагы кайнар ванналар, аяк ванналары, душлар һәм өскә су сибү кебек чаралар китереп кушты. Әмма малай һаман боегып йөри бирде. Су белән дәвалауга өстәп тутасы аңа сыек солы боткасы ашата башлады һәм бөтен җиренә чуан пластыре ябыштырып бетерде. Болардан башка да малайның ашказанын һәркөнне әллә нинди дару-дәрман белән дыңгычлап тутыра торды.

Тора-бара Том бу газаплауларга бөтенләй дә игътибар итми башлады. Малайның бу ваемсызлыгы карчыкның йөрәгенә тагын шом салды. Аны ничек кенә булса да аякка бастырырга кирәк иде. Нәкъ шул вакытта Полли түткәй беренче тапкыр авыртуны баса торган дару турында ишетте, бу даруны ул шундук бик күп итеп яздырып алды. Кабып карады да сөенеп бетә алмады: чып-чын сыек ут иде бу дару. Ул су белән дәвалавын ташлады, башка барлык дарулардан баш тартты, бөтен өметен яңа даруга баглады. Шул даруны ул Томга бер бал кашыгы белән эчертте дә бик нык дулкынланып нәтиҗәсен көтә башлады. Түткәйнең борчулары шундук үтте, күңеле дә тынычланды, чөнки Томның «ваемсызлыгы» секунд эчендә юкка чыкты. Ул аны утлы күмер өстенә утыртса да малай ул хәтле дәртле, җанлы була алмас иде.

Том, инде чыннан да бу йокылы-уяулы халәтеннән айнырга вакыт, дигән карарга килде. Мондый тормыш аның сагышлы кәефенә

бәлки тулысынча тәңгәл дә килгәндер, ләкин андый тормыш кирәгеннән артык бертөрле иде, ә күңел азыгы бик тә аз иде. Бу хәлдән чыгар өчен малай төрле ысуллар эзли башлады, ниһаять, аның башына шундый бер фикер килде: соңгы эчкән даруын ул бик нык ошатып җибәргәндәй кыланды. Даруны ул шундый да еш сорый башлады, хәтта Полли түткәй аңа, кирәк чагында үзең ал инде, дип әйтергә мәҗбүр булды. Том урынында Сид булса, ул сөенгән генә булыр иде. Мәсьәлә Томга кагылгач, Полли түткәй дару шешәсен күзәтәсе итте. Дару, чыннан да, торган саен кими барды, ләкин Том дару белән үзен дәваламый, ә бәлки аны идән ярыгына түгә бара, дигән уй Полли түткәйнең башына да килеп карамады.

Бер мәлне, Том бер кашык даруны ярыкка түгәргә генә торганда, бүлмәгә тутасының сары мәчесе килеп керде. Малайның кулындагы кашыгына карап, ул, мин дә татып карыйм әле, дигәндәй, мыр-мыр килә башлады.

— Эчәсең килмәгәнгә сорап торма инде, Питер,— диде аңа Том.

Питер эчәсе килгәнлеген аңлатты.

— Кара аны, ялгыша күрмә, үкенерсең...

Питер ялгышмавына ышаныч белдерде.

— Сорыйсың икән инде, бирәм, мин бит саран кеше түгел, тик кара аны, ошамаса үзеңә үпкәлә.



Питер бу шартларга риза булды. Том аның авызын ачып бер кашык дару салды. Питер әллә тагы ике метрга өскә сикерде, аннары әтәч тавышлары чыгарып кычкырып җибәрде дә, өстәл-урындыкларга бәрелә-сугыла, гөл чүлмәкләрен әйләндереп төшерә-төшерә, коточкыч тавыш куптарып бүлмә буйлап бөтерелә башлады. Аннары арт аякларына басты да башын артка ташлап чиктән тыш дуамалланып бүлмә буйлап биергә тотынды. Аннары юлында очраган әйбер-сәйберне вата-җимерә чапкынлый башлады. Нәкъ шул вакытта Полли түткәй килеп керде дә Питерның берничә мәртәбә мәтәлчек

атканын күреп алды, мәче, соңгы тапкыр «ур-ра» дип кычкыргандай итте дә, исән калган гөл чүлмәкләрен ияртеп, ачык тәрәзәдән тышка ташланды. Полли тутасы аптыраудан тораташ булып катты, үзе күзлеге өстеннән бүлмәне күздән кичерде. Том исә идәндә ауный-ауный шаркылдый иде.

— Ни булган ул мәчегә?

— Белмим, түткәй,— диде Том, көчкә телен әйләндереп.

— Гомеремдә дә мондый хәлне күргәнем юк иде. Ни булган аңа?

— Чынлап белмим, Полли түткәй. Берәр сөенечләре булганда песиләр гел шулай мәтәлчек аталар, ди.

— Менә ничек, чынлапмы?

Полли түткәйнең тавышында нидер сизеп Том сагаеп калды.

— Әйе, түткәй. Ягъни... мин шулай дип уйлыйм.

— Син шулай дип уйлыйсыңмы?

— Әйе, түткәй...

Тутасы идәнгә таба иелде. Том исә аның нишләгәнен кызыксынып һәм пошынып күзәтеп торды. Әмма ул аның нишләргә теләгәнен соңыннан гына аңлады. Менә ул мин — җинаять эшләүче, дигәндәй, карават астыннан кашык сабы күренеп ята иде. Полли түткәй кашыкны алып Томга күрсәтте. Том сискәнеп китеп читкә карады. Гадәте буенча Полли түткәй аның колагын борып, уймагы белән башын төйгәндәй итте.

— Йә, әфәндем, нәрсәгә кирәк булды сезгә ул бичара хайванны җәфалау?

— Мин аны тутасы булмаганга җәлләдем.

— Тутасы булмаганга, имеш! Юләр син! Тутаның ни катнашы бар монда?!

— Ничек булмасын?! Аның да тутасы булса, ул да Питерның бөтен эчәкләрен дару эчертеп көйдереп бетергән булыр иде. Малай булмыйча, мәче булуына да карап тормас иде.

Полли түткәйнең кинәт вөҗданы газаплана башлады. Хәзер ул бөтенләй башкача уйлый иде: болай итеп дәвалау мәчегә карата шәфкатьсезлек булгач, балага карата да шулай буладыр бит инде. Аның күңеле йомшарып китте. Том аңа кызганыч булып то-

елды, түткәйнең күзләре яшьләнде һәм ул, кулын малайның башына куеп, иркә тавыш белән:

— Мин сиңа яхшылык теләгән идем югыйсә. Том,— диде.— Һәм ул сиңа файдага гына булды.

Том аның йөзенә күтәрелеп карады; малайның ирен читләрендә сизелер-сизелмәс кенә елмаю чагылды.

— Миңа яхшылык теләгәнегезне беләм, Полли түткәй. Мин дә Питерга яхшылык эшләмәкче идем шул. Аңа да файдалы буласы иде ул дару. Мәченең шулай итеп чапканын минем гомеремдә дә күргәнем юк иде.

— Ярар, җитәр, Том, яңадан минем ачуымны китерәсе булма. Гомереңдә бер генә мәртәбә булса да үзеңне тиешенчә тотарга тырыш. Яңадан сиңа бернинди дару да эчәргә кирәкми.

Том мәктәпкә дәрес башланганчы ук барып җитте. Мондый гайре табигый хәлнең соңгы вакытта көн саен кабатланганын искәрми калмадылар, әлбәттә. Һәм хәзер, иптәшләре белән уйныйсы урында, Том мәктәп капкасы төбендә килә сарып йөрде. Малай иптәшләренә авырыйм дип әйтте, һәм аның кыяфәте дә авырганга охшаган иде. Юлга карап торуын да ул бүтән җиргә караган атлы итеп күрсәтергә тырышты. Юлда Джеф Тэтчер күренүгә Томның йөзе яктырып китте, әмма шундук аның чыраена яңадан моңсулык йөгерде. Джеф капкадан керүгә Том аның янына йөгереп барды да Бекки турында сүз куертырга тырышып маташты, әмма теге ачыгавыз аның ишарәсен аңламады. Ерактан кызлар күлмәге җилфердәгәнен күргән саен Томның күңеле өмет белән тулды, ләкин күренгән кеше Бекки булып чыкмагач, аның яңадан сөмсере коелды. Нињаять, күлмәкләр бөтенләй күренми башлады, һәм Том тәмам өметен өзде. Боегып һәм уйчанланып ул буш класска барып керде дә, эндәшми-тынмый гына газап чигәргә дип, үз урынына барып утырды. Шулвакыт капкада тагын бер кызлар күлмәге җилфердәгәне күренде, һәм Томның йөрәге сөенечтән леппердәп тибәргә тотынды. Күз ачып йомганчы ул инде ишегалдында иде һәм индеецлар кебек котырына башлады: кычкыра, шаркылдап көлә, малайларны куып йөри, аягын йә муенын сындырырдай итеп

койма аша сикерә, мәтәлчек ата, баштүбән йөри,— бер сүз белән әйткәндә, һәртөрле батырлыклар эшли, бер үк вакытта, күрә микән, дигәндәй, Бекки ягына таба карап-карап ала иде. Әмма кыз аның ягына борылып та карамый, нишләгәнен күрми дә кебек иде. Шулай ук ул аны күрми микәнни? Аның монда икәнен белми дә микәнни? Том батырлыкларын аңа таба якынрак килеп кыла башлады. Ул Бекки тирәсендә дәртле авазлар чыгарып бөтерелде, кемнеңдер башыннан кепкасын тартып алып өй түбәсенә тондырды, атылып малайлар төркеме уртасына барып кереп, аларның төрлесен төрле якка төрткәләп җибәрде һәм Беккиның борын төбенә үк диярлек җиргә барып төшеп, аздан гына аны аягыннан екмый калды. Кыз читкә борылып борынын чөйде дә Том ишетерлек итеп:

— Фи, берәүләр әтәчләнә, кемдер шуннан кызык таба дип уйлыйдыр инде...— диде.

Томның бит очлары янып чыкты. Ул егылган җиреннән сикереп торды да, күңеле тәмам кителеп, әкрен генә бер читкә китеп барды.



XIII бүлек

Ниһаять, Том катгый бер карарга килде. Аның кәефе тәмам кырылган, ул теләсә ни эшләргә әзер иде. Дус-ишләре юк, барысы да аннан йөз чөергән, үзен берәү дә яратмый. Бәхетсез малайны нәрсәгә китереп җиткерүләрен күргәч, бәлки үкенерләр дә, кызганырлар да әле. Ул әйбәт булырга да тырышып карады, юк бит, ирек бирмәделәр. Арынасылары килә инде аннан, әйдә, рәхим итсеннәр. Әйе, барыбер ул гаепле булып калыр. Булсын әйдә! Бөтен кеше тарафыннан җәберләнгән малайның зарланырга ни хакы бар? Мәҗбүр иттеләр бит! Нишләмәк кирәк, җинаятьчел тормыш алып барырга туры килер инде. Башка чара юк.

Том Болын тыкрыгының аргы башына барып җиткәндә дәрескә чакырып кыңгырау чылтыраганы тонык кына булып килеп иреште. Таныш чылтырау тавышын яңадан бервакытта да ишетмәячәген уйлап, ул сулкылдап куйды. Бу бик авыр хәл иде, әмма нишләмәк кирәк,— аны мәҗбүр итәләр. Сыеныр урыны булмаган бу бичараны дөнья буйлап адашып йөрергә мәҗбүр итәләр, монда инде берни эшли алмыйсың. Ләкин ул аларның барысын да кичерә... Әйе, кичерә. Ул ешрак һәм ныграк сулкылдый башлады.

Нәкъ менә шул вакытта ул үзенең ахирәт дусты Джо Һарпер белән очрашты. Джо да җылап беткән, аның да күңелендә боек һәм шомлы планнар җитлеккән, күрәсең. «Бер фикер белән яшәүче ике күңел»нең очрашуы иде бу. Том, җиңе белән күз яшьләрен сөртә-сөртә, өйдән качып китәргә уйлавы турында сөйли башлады, чөнки,

диде ул, аны бирәү дә яратмый һәм бирәү дә кызганмый, шулай булгач, иң әйбәте — ил гизеп йөрү һәм бервакытта да өйгә әйләнеп кайтмау. Сүзен йомгаклап, Джо аны бервакытта да онытмасын иде, дигән өметен белдерде.

Әмма шушы урында Джоның да дустыннан нәкъ шушы хакта үтенергә җыенган булуы беленде, һәм нәкъ шул максат белән ул аны эзләп тә йөри икән. Әнисе аны, ниндидер сөт эчкән өчен дип, кыйнап ташлаган, Джоның исә андый нәрсәгә тию түгел, күргәне дә юк икән. Әнисенең малайдан туйган булуы һәм аңардан котылырга өметләнүе көн кебек ачык: бәс, шулай икән, малайга чыгып китүдән башка чара калмый да инде. Бәлки ана кешегә малаеннан башка рәхәтрәк булыр, һәм ул үзенең бичара улын чит кешеләр арасына ил гизәргә куып чыгаруына һичкайчан үкенмәс тә, әйе, малай шунда газап чигә торгач дөнья белән саубуллашыр.

Бер-берсенең кайгысын уртаклаша-уртаклаша малайлар ары киттеләр һәм юлда бертуганнар кебек бер-берсенә ярдәм итешергә, бөтен газапларның азагы булып үлем көне җиткәнче бер-берсеннән аерылмаска сүз беркеттеләр. Аннары алар ничек яшәргә җыенулары турындагы планнар белән уртаклаштылар. Джо, кипкән агач кайрысы ашап, тау куышында ялгыз яшәргә һәм ахыр чиктә салкыннан, хәсрәттән һәм нужадан үлеп китәргә җыена иде, ләкин Томның сөйләгәннәрен тыңлап карагач, җинаятьчеләр тормышында кайбер җитди өстенлекләр булуы белән килеште һәм пиратлыкка чыгарга ризалык бирде.

Сент-Питерсбергтан өч миль чамасы түбәнрәк, Миссисипи елгасының иңе бер милдән артып киткән җирдә агачлар үсеп утырган озын, тар бер утрау бар. Алар шул утрауның аргы башындагы комлы сайлыкта тукталырга уйладылар. Кеше яшәми торган бу утрау куе кара урман каплаган каршы як ярга якын гына урнашкан иде. Алар менә шушы Джексон утравын сайлыйсы булдылар. Әмма анда без кемне генә таларбыз икән соң дигән сорауны куярга аларның башларына килмәде. Шуннан алар Һаклберри Финны эзләп таптылар, һәм ул шундук аларга кушылды, чөнки аңа ни белән шөгыльләнсә дә барыбер; мондый мәсьәләдә ул бик күндәм иде. Балалар елганың шәһәрдән

югарырак урынында, аулакта, үзләре яраткан вакытта, ягъни төн уртасында очрашырга дип сүз куештылар да таралыштылар. Һәрберсе кармак сабы белән кармак, теш арасына кыстырырдай бирәр нәрсә алып килергә тиеш иде. Боларны ничек тә булса серлерәк һәм әкәмәтрәк итеп кулга төшерергә кирәк булачак иде. Кич җиткәнче үк инде алар малай-шалай арасында үзләре турында «кайбер кызыклы нәрсәләр ишетерсез әле», дигән сүз тараттылар. Бу томанлы кинаяне җиткергән һәр кешегә алар «телне тыярга» дигән кисәтү дә ясадылар.

Төн урталарында, пешкән ит һәм тагын кайбер азык-төлек заты алып, Том килеп җитте дә очрашу урыныннан югарырак җиргә, калку урынга, куаклык арасына кереп утырды. Төн аяз һәм тын иде. Алда, җилсез чактагы океан кебек, куәтле елга җәелеп ята. Том тавыш-мазар юкмы дип колак салды, әмма бернинди аваз да тынлыкны бозмады. Аннары ул сузып кына сызгырып куйды. Тау астыннан аңа шулай ук сызгырып җавап бирделәр. Том тагын ике тапкыр сызгырды, аның бу сигналына каршы да шулай ук сызгырып җавап бирделәр. Аннары кемдер иләп кенә:

— Кем килә? — дип сорады.

— Том Сойер, Испан диңгезләренең Мәкерле үч алучысы. Сез дә исемнәрегезне әйтегез.

— Һак Финн, Канлы кул һәм Джо Һарпер, Океаннар дәһшәте.— Том бу куппы кушаматларны яраткан китапларыннан укып белә иде.

— Яхшы. Парольне әйтегез!

Ике карлыккан тавыш төн караңгысында пышылдап кына бер үк:

— Кан! — дигән шомлы сүзне әйттеләр.

Шуннан соң Том югарыдан пешкән итен тәгәрәтеп төшерде; үзе шуып төшкәндә исә аның чалбары ертылды һәм аягы сыдырылды.

Тау астыннан яр буйлап җайлы гына, тигез генә сукмак сузылып киткән, әмма бу сукмакның бер җитешсезлеге бар: анда пиратлар бик тә хөрмәт итә торган каршылыклар юк. Океаннар дәһшәте

дигән кешебез бер зур гына кисәк түш ите алып килгән, шуны күтәреп килә-килә ул үзе дә шактый хәлдән тайган иде. Канлы кул Финн каяндыр котелок белән бер төргәк кибеп җитмәгән тәмәке яфрагы чәлдергән, өстәвенә трубка ясарга дип берничә бөртек кукуруз сабагы да эләктергән. Шуны да әйтергә кирәк, аның үзеннән башка пиратларның берсе дә тәмәке тартмый да, чәйнәми дә иде. Испан диңгезләренең Мәкерле үч алучысы, ут хәстәрләмичә юлга чыгарга ярамый, дип искәртеп куйды. Бу фикер акыллы иде: ул заманнарда шырпыны бөтенләй белмиләр дә иде диярлек. Елга буйлап үргә таба йөз адымнар киткәч алар, зур бер сал өстендә пыскып янган учак күреп, шуның янына шыпырт кына бардылар да бер кисәү башын кулга төшерделәр. Шуннан алар тәмам маҗара ясадылар: йә, бер-берсенә пышылдадылар, йә кинәт туктап калып, шаулама, дигәнне аңлатып, бармакларын иреннәренә куйдылар, яисә кулларын фараз иткән хәнҗәрнең сабына салдылар. Салчыларның, шәһәргә китеп, кибетләр буйлап яисә салгалап, кәеф-сафа кылып йөрүләрен малайлар бик яхшы белә иде, һәм алар үзләрен чын пиратларча тотмасалар моны берничек тә аңлап булмас иде.

Шуннан соң малайлар юлга кузгалдылар. Том аларга боерып торды. Һак — көймәнең койрыгындагы ишкәк белән, Джо борынындагы ишкәк белән иште. Том «корабның» уртасында басып торды. Кашларын моңсу җыерып, кулларын күкрәгенә куеп, ул төксе тавыш белән пышылдап кына боерык бирә торды:

— Җилгә таба тот! Җилгә таба тот!

— Ярый, әфәнде!

— Шулай тот!

— Ярый, әфәнде!

— Ярты румбага бор!

— Ярый, әфәнде!

Малайлар тыныч кына аккан елга уртасына таба ишкәнгә, бу боерыклар барысы да «матурлык өчен генә» бирелә иде. Һәм, әлбәттә, бернәрсә дә аңлатмый иде.

— Корабта нинди җилкәннәр күтәрелгән?

— Түбәнге, марсельләр һәм бом-кливерлары, әфәнде!

— Трюмсельләрне куярга! Әй, сез! Унлап егетне фор-стеньстаксельгә җибәрергә! Кыймылда!

— Була ул, әфәнде!

— Грот-брамсельне җибәр! Шкот һәм брасны! Тизрәк, егетләр!

— Була ул, әфәнде!

— Рульне җил ягына — сул борттан! Абордажга алырга әзерлән! Сул як рульне бор! Тагын да сулгарак! Ягез, егетләр! Дәррәү! Шулай тот!

— Шулай тотарбыз, әфәндем!

Сал елганың уртасын узып китте, малайлар аны агым уңаена бордылар да тырышып-тырышып ишкәк белән ишә башладылар. Бик тирән булмаган суның агым көче ике-өч мильдән ары түгел иде. Өч чирек сәгатьме, бер сәгатьме вакыт үтте; бу вакыт эчендә малайлар бөтенләй диярлек сөйләшмәделәр. Хәзер сал Сент-Питерсберг турыннан үтеп бара иде. Шәһәрчек тыныч йокыга талган. Җемелдәп янган бер-ике уттан гына аның кайсы турыда икәнен чамалап була иде. Шушы минутта нинди зур вакыйгалар булып ятканы йокыдагы кешеләрнең башына да килми иде. Испан диңгезенең Мәкерле үч алучысы, кулларын күкрәгенә кушырган килеш кайчандыр үзе сөенечләр татыган, газаплар чиккән урынга «соңгы тапкыр» карап хәрәкәтсез калган иде. Давыллы дулкыннар өстеннән аның хәвеф-хәтәрләргә каршы ничек итеп җилдергәнен һәм һәлакәтләрне моңсу елмаеп, курыкмыйча сәламләвен «ул» күрсен иде дип хыялланды. Хыялын эшкә җигеп, ул Джексон утравын шәһәрдән күренмәслек итеп, арырак күчереп куйды һәм йөрәге тулы сызлану-сөенеч белән «туган шәһәренә соңгы карашын ташлады». Калган пиратлар да шәһәргә «соңгы тапкыр карыйлар иде», алар шул тарафка шактый озак карап тордылар, саллары әздән генә утрауны үтеп китми калды; куркыныч янаганны алар вакытында сизеп алдылар һәм тиз генә хаталарын төзәтергә өлгерделәр. Төнге сәгать икеләрдә сал утраудан ике йөз метрлар өстәрәк бер сайлыкка барып утырды; малайлар кирәк-яракларын су ерып ярга чыгардылар. Шушы бәләкәй генә салда иске җилкән бар икән, малайлар шуны азык-

төлек өстенә каплар өчен түбә итеп куаклар өстенә җәйделәр, үзләре, чын пиратлар шикелле, аяз күк астында йокламакчы булдылар.

Караңгы урман ешкынлыгыннан егерме-утыз адымнарда, ауган агач янында, алар учак дөрләтеп җибәрделәр, кечкенә ашка дип табага салып дуңгызның түш итен кыздырып алдылар һәм кукуруз кабартмаларының яртысын ашап та бетерделәр. Их, нинди зур бәхет бит ул иректә, берәү дә аяк басмаган, тикшерелмәгән җирдә, кеше яшәгән урыннан еракта бәйрәм итү! Цивилизацияле тормышка алар яңадан беркайчан да әйләнеп кайтачак түгел. Кабынып-кабынып китә торган ут аларның йөзләрен яктыртты һәм шул уттан агачларга, аларның урман-йортына, лак йөгертелгәндәй елкылдап торган яфракларга һәм кыргый йөзем төлгәшләренә кызгылт ут шәүләсе төште.

Түш итенең һәм кукуруз кабартмасының соңгы кисәкләре ашалып беткәч, малайлар хозурланып үлән өстенә сузылып яттылар. Дөрес, алар тагын да салкынчарак урын таба алган булырлар иде, әмма алар үзләрен урмандагы учак буенда яту рәхәтеннән мәхрүм итә алмадылар.

— Әллә рәхәт түгелме? — дип куйды Джо.

— Искиткеч! — дип җавап бирде Том.

— Башка малайлар безне күрсәләр ни диярләр иде икән?

— Ни дисеннәр? Көнләшеп үләрләр иде! Әйеме, Һакки?

— Әйе шул,— диде Һаклберри.— Башкалар ничектер, әмма мин канәгать. Шушыннан да рәхәте булмас инде. Корсакны туйганчы туйдыру да көн саен эләкми бит әле миңа. Аннары монда сиңа берәү дә тими, тик торганда килеп бәйләнми...

— Шушындый тормыш бик ошый миңа,— диде Том.— Иртән иртүк торасы, мәктәпкә барасы, юынасы юк һәм башка шуның ише вак-төяк белән маташасы юк. Беләсеңме, Джо, пиратка әйләнгәч яр буенда синең бернинди эшең дә булмый, ә менә инде дәрвиш булсаң, һәрвакыт дога укырга кирәк, бердән; икенчедән, инде ялгыз башыңа бик үк күңелле дә түгел.

— Әйе шул, дөрес әйтәсең,— диде Джо.— Беләсеңме, мин элек

бу турыда нишләптер уйламаганмын. Ә хәзер, инде төмен татып карагач, минем бик тә пират буласым килә.

— Беләсеңме,— диде Том,— дәрвишләрне хәзер ихтирам да итмиләр, элекке вакытлардагы кебек түгел, ә инде пиратларны хәзер дә хөрмәт итәләр. Шуның өстенә әле дәрвишкә урынның да катысы гына, киемнең дә сәләмәсе тия, башына көл дә сибелә, яңгыр астында да чылана...

— Ә нигә аңа киемнең сәләмәсе тия, ә нигә аның башына көл сибелә? — дип сорады Һаклберри.

— Нигә икәнен белмим. Әмма шулай булырга тиеш. Дәрвиш булсаң, синең белән дә шулай булыр иде.

— Булмыйни! — диде Һак.

— Ә башкача ничек?

— Белмим. Тик алай булмас иде.

— Шулай булыр иде.

— Юк, мин ул хәлгә чыдамас идем. Тотар идем дә качар идем.

— Качар идең! Нинди дәрвиш буласың ди инде син ул чакта?

Канлы кул берни дип тә җавап бирмәде, чөнки ул үзенә кызыклырак шөгыль тапкан иде: кукуруз чәкәнен чокып трубка ясаган да шуңа кукуруз сабагыннан сап куйган. Трубкасына кипкән тәмәке яфрагы төеп тутырган. Хуш исле төтен божралары җибәреп, ул шуннан тәм табып мәш килә иде. Аның тәмәке тартуы бүтән пиратларны бик тә кызыктырды, һәм алар бу шөгыльне мөмкин кадәр тизрәк үзләштерергә булдылар. Һак тагы Томга эндәште:

— Ә алар нишлиләр, пиратлар?

— О! Пиратлар алар бик күңелле яшиләр, корабларны әсир итәләр дә ут төртеп яндыралар, андагы алтын-көмешне үзләренә алалар һәм утраудагы нинди дә булса бер сихерле урынга күмеп куялар. Анда аны өрәкләр һәм башка шуның ише җен-пәриләр саклый. Корабтагы бөтен кешене алар үтереп бетерәләр, аннары аларны тактадан шудырып диңгезгә төшереп җибәрәләр.

— Хатын-кызларны үзләренең утрауларына алып китәләр,— дип өстәде Джо,— хатын-кызларны үтермиләр алар.

— Әйе,— дип, аның фикерен куәтләде Том,— хатын-кызларны алар үтермиләр. Алар киң күңелле кешеләр. Һәм аннары бит хатын-кызлар һәрвакыт чибәр була.

— Өс-башлары аларның гаҗәп зиннәтле була, алтыннан да көмештән генә, брильянттан! — дип, тантаналы рәвештә өстәп куйды Джо.

— Кемнең? — дип сорады Һак.

— Пиратларның инде, кемнең булсын!

Һаклберри Финн, күңеле төшеп, үзенең өс-башын күздән кичерде.

— Минемчә, пиратлыкка батмыйм мин, киемем дә андый түгел,— диде ул үкенүле тавыш белән,— тик минем бүтән киемем юк шул.

Әмма малайлар, матур-матур костюмнарыбыз булырга озак калмады инде, дип, аны юатырга тотындылар: мажаралы тормыш белән яши башлагач — алтыны да, көмеше дә — барысы да була аның, диделәр. Башлап җибәрү өчен киемнең сәләмәсе дә ярый, ә инде бай диңгез юлбасарлары, мажараларын башлаганчы ук, кирәкле кием-салымнарын алдан әзерлиләр.

Сөйләшү әкренләп тына барды: нәни качкыннарның күзләре йомыла башлады, алар торган саен ныграк йокымсырадылар. Трубка Канлы кулның бармаклары арасыннан шуып төшеп китте, һәм ул, арып-талган намуслы кешедәй, тирән йокыга талды. Океаннар дәһшәте белән Испан диңгезләренең Мәкерле үч алучысы алай ук тиз йокыга китмәде. Йокы алдыннан укыла торган догаларын алар яткан җирләреннән, күңелдән генә укыдылар, чөнки аларны тезләнергә һәм кычкырып укырга мәҗбүр итәр кеше юк иде. Дөресен генә әйткәндә, алар гомумән дә догаларын укымаска булганнар иде, ләкин Хак Тәгалә аларның башына махсус яшен җибәртер дә баскан җирләрендә үтертер, дип курыктылар. Кинәт бөтен нәрсә бергә буталды, һәм алар инде йокыга талырга әзер иделәр. Ләкин нәкъ менә шушы мәлдә аларның күңелен вөҗдан газабы дигән нәрсә кимерә башлады. Алар, өйдән чыгып китеп бик үк әйбәт эшләмәгәнбездер, мөгаен, дип, шомланып пошына башладылар; аннары урланган ит исләренә төште, һәм шуннан соң инде чын мәгънәсендә газап чигү башланды. Элек тә

чоланнардан конфеттыр, алмадыр ише нәрсәләрне ничәмә-ничә тапкырлар чәлгән бар иде бит, дип, алар күңелләрен тынычландырырга тырыштылар, әмма вөждан дигән нәрсә, бу дәлилләрне көчсез дип табып, һич кенә дә килешергә теләмәде. Ахыр чиктә нинди дә булса вак-төяк тәм-том чәлү — юк эш, ә менә түш ите белән башка шуның ише кыйммәтле нәрсәләрне урлау исә — бусы инде чын караклык, һәм моңа каршы Тәүратта махсус канун да бар. Шуңа күрә диңгез юлбасары булып йөргән суръттә дә алар үзләрен угрылык ише җинаять белән пычратмаска карар иттеләр. Шул чагында инде вөждан дигән нәрсә килешү төзергә риза булды, һәм безнең эзлексез юлбасарларыбыз тынычлап йокыга талды.





XIV бүлек

Иртәгесен уянып киткәч Том озак кына үзенең кайда икәнен аңлый алмыйча ятты. Торып утырды да күзләрен уа-уа тирәягына карана башлады — шунда гына ул исенә килде. Чырайсыз гына булып салкынча таң атып килә. Урман үзенә бертөрле рәхәт тынлыкка чумган. Бер генә яфрак та селкенми, бөек табигатьнең уйчанлыгын бер генә аваз да бозмый. Яфраклар һәм үләннәр өстендә сәйлән булып чык бөртекләре җемелди. Учак өстендә ап-ак көл катламы ята, һәм өскә таба нечкә генә булып зәңгәрсу төтен сызыгы күтәрелә. Джо белән Һак әле йоклыйлар.

Еракта, урман эчендә, ниндидер кош чыркылдап куйды, икенчесе аңа җавап бирде, шундук тукран тукылдый башлады. Көн яктыра төшкән саен авазлар күбәя барды — һәр тарафта тормыш уянды. Малай, уйга калып, табигатьнең уянып эшкә тотынуын күзәтте. Чыкка манчылган яфрак өстеннән кечкенә генә бер яшел бөҗәк шуышып бара. Вакыт-вакыт ул яфрак өстендә гәүдәсенең өчтән ике өлешен күтәреп-күтәреп ала, әйтерсең лә нәрсәнедер иснй һәм аннары тагын юлын дәвам иттерә.

— Яфракның үлчәвен ала,— дип куйды эченнән генә Том.

Бөҗәк аңа таба якынлаша башлагач Том тынсыз булып көтеп калды, бөҗәк башка юнәлештә китәргә ниятләгәч исә малайның кәефе кырылды.

Ниһаять, бөҗәк, үзенең ыргак сыман кәкрәйгән гәүдәсен күтәреп, кайсы якка китәргә икән дигән сыман, ниндидер мизгелгә

туктап калды да, аннары Томның аягы өстенә менеп, аяк буйлап сәяхәт итәргә тотынган иде, малайның йөрәге шатлык белән тулды, чөнки бу — аның яңа костюмы була дигән сүз иде, әлбәттә инде, ул костюм елкылдап торган алтынланган пират мундиры булыр! Каяндыр бер көтү кырмыска килеп чыкты, һәм ул кырмыскалар шундук эшкә керештеләр: аларның берсе, үзеннән биш мәртәбә зуррак үрмәкүчне сыртына салып, агач кәүсәсе буйлап өскә таба үрмәләде.

Кызылга ак бөрчек төшкән камка үлән сабагы буйлап югарыга менеп бара. Том аңа таба иелде дә:

— Киявең килә — кач, кач! Киявең килә — кач! — дип пышылдады.

Камка аның сүзен ишетүгә шундук киявеннән качып очып та китте, һәм бу хәлгә Том бер генә дә гаҗәпләнмәде: камкаларның шундый ышанучан булуына ул электән күнеккән иде; беркатлы булуларыннан файдаланып ул аларны гел шулай алдый торган иде. Аннары дәртләнеп, шарын алга таба этә-этә, тирес корты килеп чыкты. Том аңа бармагы белән кагылды: шулай иткәч ул тәпиләрен гәүдәсенә кыса да үлгән атлы булып кылана. Бу вакытта инде кошларның барысы да тырыша-тырыша сайрый иде. Томның баш очындагы агачка бер миләш чыпчыгы килеп кунды да төрлечә иттерeп сайрар кошларны үртәргә тотынды. Зәңгәрсу ут төсле булып һавадан чәрелдек кукшә очып үтте, малайдан бер-ике адым ераклыктагы агач ботагына килеп кунды һәм, башын кыек салып, бик кызыксынып таныш булмаган килмешәкләрне күзәтә башлады. Соры тиен белән ниндидер башка бер эрерәк җәнлек, төлке токымыннан булса кирәк, бер-бер артлы кызу гына йөгерешеп уздылар. Вакыт-вакыт туктап, алар көтелмәгән кунакларга таба карап пошкырып куйдылар; әлеге урман җәнлекләренең бервакытта да кеше күргәннәре булмаганлыктан, аннан куркыргамы, юкмы икәнен дә белмиләр иде. Бу вакытта инде бар табигать уянып, кыймыл-камыл килергә тотынды. Кояшның озын сөңгеләре куе яфраклар аша тегендә дә, монда да үтеп керә башлады; бер-берсе белән куыша-куыша каяндыр берничә күбәләк очып килеп чыкты.

Том башка пиратларны да уятты, алар кычкырыша-кычкырыша елгага таба чаптылар, шундук өс киемнәрен салып ыргыттылар да төбе тулы ап-ак ком яткан чиста, сай суда йөгерешеп-сикерешеп уйный, куыша башладылар. Тегендә, мәһабәт су сахрасы артында, йоклап яткан шәһәр аларны һич кенә дә үзенә тартмады. Ә саллары боларның төнлә агып киткән иде; аны йә бормаланып аккан агым, яисә бераз күтәрелә төшкән су үзе белән иярткәндер инде, әмма бу хәлгә малайлар көенмәделәр генә түгел, хәтта сөенделәр дә: хәзер инде, әгәр шулай дип әйтергә яраса, мәдәни дөнья белән бәйли торган күперләр яндырылган кебек булды.

Лагерьга алар күңелләре күтәрелеп, гаҗәп тә сафланып, бүре урынына ачыгып кайтып килделәр, тиздән аларның поход учаклары яңадан да ялкынланып дөрли башлады. Һак шуннан ерак түгел челтерәп агып яткан салкын сулы бер чишмә тапты, малайларның кайсысы имән яфрагыннан, кайсысы чикләвек яфрагыннан үзләренә касә кебек нәрсә әмәлләде, һәм кыргый урман исе аңкып торган шушы су аларга менә дигән кофедан да тәмлерәк булып тоелды. Джо иртәнге ашка дип дуңгыз ите турый башлады. Ләкин Том белән Һак аңарга ашыкмаска куштылар: алар елга буена, бер бик җайлы гына урынга йөгереп киттеләр дә кармакларын салып та куйдылар. Джо көтеп сабырлыгын югалтырга да өлгерә алмый калды, менә дигән кара балык, ике алабуга һәм кечерәк кенә бер җәен балыгы күтәреп, болар учак янына әйләнеп тә кайттылар, алар алып кайткан балык бөтен бер гаиләнең тамагын туйдырырга җитәрлек иде. Дуңгызның түш ите белән бергә турап кыздырганнар иде, хәйран калдылар: балыкның әле бервакытта да болай тәмле булганы юк иде. Алар елга балыгын никадәр тизрәк табага салсаң, шулкадәр тәмлерәк булуын дә белмиләр иде шул; урманда йоклауның, саф һавада уйнап-чабышып йөрү, су коенуның, мәгълүм бер дәрәҗәдәге ачлыкның нинди гүзәл тәмләткеч булуы аларның башына да килми иде.

Иртәнге ашны ашагач алар, Һакның трубка тартып бетергәнен көтеп, күләгәдә ятып тордылар; аннары разведка ясап кайтырга дип урман эченә кереп киттеләр. Ешкынлыкларны кичеп, очларыннан алып җиргә кадәр кыргый йөзем төлгәшләренә төренгән

мәһабәт агач араларыннан үтә-үтә, күңелле итеп сөйләшә-сөйләшә алар коры-сары өстеннән атлап бардылар. Анда-санда куе үлән келәме һәм, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән кебек, чуп-чуар чәчәкләр каплаган ямьле аланлыклар очрап торды.

Юлда очраган күп нәрсә малайларны сөендерде, ләкин алар бернинди дә искитәрлек нәрсә тапмадылар. Утрау өч мильгә буйга сузылган, иңе исә нибары бер чирек миль булып чыкты, һәм иң якын дигән ярдан аны иңе ике йөз метр тирәсендәге култык аерып тора иде. Малайлар сәгать саен диярлек су коендылар, һәм алар лагерьга әйләнеп кайтканда инде көн кичегеп килә иде. Алар бик нык ачыккан иделәр һәм шуңа күрә балык тотып мәшәкатьләнмәделәр, аның каравы салкын дуңгыз итен тәмләп ашадылар да, күләгә урынга ятып, гәп корып җибәрделәр. Ләкин аларның сүзләре бәйләнмәде, озакламый исә бөтенләй өзелде. Тынычлык, урмандагы мәһабәт тынлык һәм ялгызлык хисе малайларның кәефендә чагыла башлады. Алар уйга талдылар. Аларның күңелләрен ниндидер шомлы сагыш биләп алды. Тиздән ул сагыш хисе шактый анык төскә керде: бу — өйне юксына башлау хисе иде. Хәтта Канлы кул Финн да буш мичкәләр, чит-ят кешеләрнең өйалды хакында хыялланды. Ләкин малайларның һәрберсе үзенең йомшаклыгыннан ояла иде, һәм берсенең дә уендагысын кычкырып әйтергә йөрәге җитмәде.

Малайларның колагына инде шактыйдан бирле ниндидер бер сәер тавыш килеп ирешә торды. Ләкин алар аны, кайвакыт сәгать келтләгәнен ишетмәгән кебек, искәрмиләр иде. Мәгәр серле аваз әкренләп һаман көчәя барды, һәм аны инде искәрмичә калу мөмкин түгел иде. Малайлар сискәнеп куйдылар, бер-берсенә карашып алдылар да тыңлана башладылар. Берни белән дә бозылмый торган, озакка сузылган тирән тынлык урнашты. Аннары алар тонык кына итеп «бум!» дип куйган шомлы аваз ишеттеләр.

— Нәрсә булыр бу? — диде Джо ишетелер-ишетелмәс кенә итеп.

— Белмим,— дип, пышылдап кына җавап бирде Том.

— Күк күкрәү түгел бу,— диде Һаклберри куркынып,— чөнки күк күкрәү ул...

— Туктагыз! — дип кычкырып җибәрде Том.— Тыңлагыз!

Алар берникадәр вакыт сабыр иттеләр, бу вакыт аларга мәңгелек сыман озын булып тоелды, һәм аннан соң тантаналы тынлыкны тагын «бум!» дигән аваз бозды.

— Әйдәгез карыйбыз!

Өчесе дә сикереп торып елга буена таба чаптылар. Аннан шәһәрчек күренеп кенә тора иде. Куакларны аергалап малайлар алга таба текәлделәр. Елганың урта бер җиреннән, шәһәрдән берәр мильгә түбәннәнрәк, агым уңаена кечкенә бер пароход йөзеп бара иде. Аның киң палубасы өстендә халык ыгы-зыгы килә. Пароходның янәшәсеннән генә түбән таба көймәләр дә йөзә. Әмма көймәләргә утырган кешеләрнең нишләгәнен малайлар ачык кына итеп күрә алмады.

Кинәт кенә пароходның борты буеннан ак төтен баганасы күтәрелде, ул төтен таралып җиңелчә болытка әйләнгәч, малайларның колагына шул ук «бум!» дигән моңсу тавыш килеп ишетелде.



— Хәзер мин эшнең нәрсәдә икәнен аңладым! — дип кычкырып җибәрде Том.— Кемдер батып үлгән!

— Дөрес,— диде Һак.— Былтыр җәй көне Билли Тернер батып үлгәч тә шулай булган иде; ул чакта да су өстендә туптан атканнар иде,— шулай иткәч батып үлгән кеше су өстенә калкып чыга икән. Әйе! Аннары бер бөтен ипи алып шуның эченә терекөмеш салалар да суга җибәрәләр: ул ипи кеше батып үлгән җиргә барып туктый икән.

— Әйе, бу турыда минем дә ишеткәнем бар,— диде Джо.— Аңламыйм, нишләп туктый торгандыр инде ул ипи?

— Монда, минемчә, хикмәт ипидә түгел, ипине суга агызганда ниндидер сүзләр әйтәләрдер, мөгаен — хикмәт менә шунда булырга тиеш,— диде Том.

— Бернинди сүз дә әйтмиләр! — дип, аңа каршы төште Һак.— Үземнең күргәнем бар: бернинди сүз дә әйтмиләр.

— Сәер!..— диде Том.— бәлки эчтән генә әйтәләрдер... әлбәттә инде эчтән генә әйтә торганнардыр — берәү дә ишетмәсен өчен. Әлбәттә шулайдыр. Моны шундук аңларга була инде.

Малайлар Томның фикере белән килештеләр, чөнки берни дә аңламый торган ипи кисәге бернинди әфсен укымаган килеш ничек итеп инде шундый мөһим эшне башкара алсын.

— Их! Хәзер теге якта булсаң иде менә! — диде Джо.

— Әйе шул,— дип, аның сүзенә Һак та кушылды.— Үтереп тә беләсе килә бит кем батканын!

Малайлар әле һаман күзләрен еракка текәп тыңлануларында булдылар. Кинәт кенә Томның башына бер уй килде.

— Малайлар, мин беләм кем батып үлгәнен! Без ул,— диде малай.

Бер минутка алар үзләрен батырлар итеп хис иттеләр. Бу чынчынлап тантана иде: аларны эзлиләр, алар хакында күз яше түгәләр, алар аркасында кешеләрнең кайгыдан йөрәкләре өзгәләнә, кешеләр бу бичара малайларга карата каты бәгырьле булулары өчен соңга калып булса да үкенәләр. Шунысы шәп — алар турында бөтен шәһәр сөйли; алардан, аларның шаккатарлык даннарыннан бөтен малайлар

көнләшә. Шуның өчен генә булса да пиратлыкта йөрергә ярый иде.

Күз бәйләнер вакыт җитүгә пароход, бер ярдан икенче ярга таба йөреп, үзенең гадәттәге эше белән мәшгуль булды. Диңгез юлбасарлары лагерьларына әйләнеп кайттылар. Алар куанычларыннан нишләргә белмәделәр; яңа калкып чыккан бөеклекләре белән, даннары белән горур иделәр. Бөтен шәһәргә шундый мәшәкать тудырулары белен мактаныштылар. Балык тотып кичке ашны әзерләп ашадылар да үзләре турында шәһәрдә нәрсә уйлауларын, нилләр сөйләүләрен фараз итәргә тотындылар. Үзләре турында халыкның ничек кайгыруын күз алдына китерү дә аларга рәхәтлек бирә иде. Әмма төн күләгәсе куера төшкәч аларның сүзләре әкренләп сүрелде: өчесе дә текәлеп учак утына карап утырдылар, уйлары, күрәсең, кайдадыр еракта иде. Әсәрләнүләре инде басылды; Том белән Джо үзләренең кайбер якыннарын искә төшерми булдыра алмадылар, бу көлкеле шаяртудан, ай-һай, аларга кызык иде микән? Малайларның күңелләренә тагын ниндидер шом керде, икесенең дә җаннары тынычсызланды, икесе дә үзләрен бәхетсез хис иттеләр һәм ике-өч мәртәбә ирексездән уһылдап та куйдылар. Ниһаять, Джо мәдәни дөньяга кире кайту мәсьәләсенә башкалар ничегрәк карый икән, дип, кыяр-кыймас кына кармак салырга батырчылык итте.— Хәзер үк түгел, әлбәттә, кайчан да булса бер, дип әйтүе...

Том аны усал итеп мыскыллап ташлады. Хәзергә әле бернинди гаебе дә булмаган һак, әлбәттә инде, Том ягына басты. Икеләнеп торганнан соң Джо үзенең шаяртып кына алырга теләгәнен әйтте. Шулай да йөрәксез диган, өен сагына дигән гаеп аның өстендә калды. Бу юлга фетнә бастырылды, әмма кайчанга кадәр булыр?

Көн тәмам караңгыланып җиткән мәлдә һак йокыга китте, аннары гырлый ук башлады. Аның артыннан Джо да йокыга талды. Том, терсәгенә таянган килеш, берникадәр вакыт иптәшләренең йөзенә текәлеп хәрәкәтсез ятты. Аннары ул ипләп кенә тезләнде дә җемелдәп торган учак яктысында капшанып үлән арасыннан нидер эзли башлады. Бөгәрләнеп беткән берничә чинар кайрысы табып, аларның һәр кисәген җентекләп күздән кичергәч, шулардан икесен сайлап алды; аннары учак буена килеп тезләнеп һәр ике кайры

кисәгенә бик тырышып үзенең «кызыл охра»сы белән тырнаштырып берничә сүз язды. Кайрының берсен элеккечә бөтәрләп кесәсенә тыкты, икенчесен Джоның эшләпәсенә салды. Моннан башка эшләпә эченә ул һәр укучы өчен дә ифрат дәрәҗәдә кадерле булган хәзинә — бер кисәк акбур, резин туп, өч кармак белән «чын бәллүр» дип атап йөртелә торган кечкенә генә бер шар салды. Аннары иплəп кенә, аяк очларына басып кына агачлар арасыннан китеп барды. Иптәшләре инде еракта калып, аның аяк тавышларын ишетмәслек булгач, ул бар көченә елга сайлыгына таба чабарга тотынды.



XV бүлек

Берничә минуттан Том сайлык буйлап Иллинойс ярына таба атлый иде. Су аның биленә менеп җиткәнче ул инде юлның яртысыннан күбесен үткән иде; аннары, көчле агым комачаулаганлыктан, тәпиләп барып булмый башлады. Каршы як ярга кадәр нибары йөзләп метр калганда Том уйлап та тормыйча йөзә башлады. Ул агымга каршы кыйгачлап йөзде, ләкин су аны ул уйлаганга караганда да тизрәк түбән таба агыза иде. Ниһаять, ул барыбер ярга якынайды һәм яр буйлап йөзеп китте, аннары җайлы урын табып яр өстенә чыкты. Курткасының кесәсен капшап карады, кайрысының төшеп калмаганлыгына ышангач, яр читеннән урман буйлап алга атлады. Аның киеменнән шыбырдап су акты. Ул урманнан ачык җиргә — шәһәрнең нәкъ каршысына килеп чыкканда әле сәгать ун да тулмаган булгандыр. Том текә яр буенда, агачлар күләгәсендә туктап торган пароходны күреп алды. Тирә-як тып-тын, күктә йолдызлар гына җемелдәшә. Дикъкать белән як-ягына карана-карана Том иләп кенә текә яр башыннан төшеп су эченә керде һәм, берникадәр араны йөзеп үтеп, пароходның койрыгына бәйләп куелган көймәгә менде дә эскәмия астына кереп ятты. Хәл җыеп алгач, ул көтә башлады.

Озакламый ярык кыңгырауны сугып куйдылар, һәм «Кузгал!» дигән команда тавышы яңгырады. Берәр минуттан пароход дулкыныннан көймәнең борыны сикереп куйды, һәм Томның сәяхәте башланып китте. Җае туры килү белән ул бәхетле иде, пароходның соңгы рейсы икәнен Том белә иде. Бик озак итеп уникеме, унбишме минут

үтте. Тәгәрмәчләр эшләүдән туктады. Том көймәдән суга төште дә караңгы яр буена таба йөзеп китте; арттарак калган берәр пассажирга барып төртелмәгәем дип, яр буена пароходтан бер илләп адым читкәрәк китеп чыкты.

Том аулаграк тыкрыклар буйлап йөгерергә тотынды һәм озакламый тутасының өй артындагы койма буена кайтып җитте. Койма аша ишегалдына сикереп төште дә кача-поса гына флигель янына килеп Полли түткәй бүлмәсенең ут янып торган тәрәзәсеннән карады. Бүлмәдә Полли түткәй, Сид, Мэри һәм Джо Һарпернең әнисе нәрсә турындадыр гәпләшеп утыра иде. Алар караватт буена җыелышып утырганнар. Том ишек янына килде дә сиздермичә генә бигеп күтәрә башлады һәм әкрен генә итеп ишекне этте,— ул тар гына булып ачылды; ачыла башлаган ишеккә Том тагын да әкренрәк итеп төртте, ишек шыгырдаган тавышка үзе сискәнеп куйды; ниһаять, ачык ишектән дүрт аякланып бүлмәгә керергә мөмкин булды, һәм Том башын тыкты да үрмәләп бүлмәгә узды.

— Нишләп соң әле бу шәмнең ялкыны җилферди башлады? — дип куйды Полли түткәй. Том ашыгыбрак үрмәләргә тотынды.— Ишек ачылып киткәндер, күрәсең. Әйтәм бит ачылгандыр дип. Ябып җибәр әле, Сид!

Том караватт астына бик вакытлы кереп чумды. Ул бераз тын алып, хәл җыеп торды, аннары Полли түткәйнең янына ук үрмәләп барды, кулы белән ул хәтта аның аягына да кагыла алган булыр иде.

— Әйтәм бит,— дип, сүзен дәвам иттерде Полли түткәй.— Бернинди әшәкелеге дә юк иде аның югыйсә, шуклыгы бар иде инде. Башсыз, хәтерсез... Ни әйтәсең инде аңа. Ул берәүгә дә әшәкелек эшләмәде. Яхшы күңелле иде. Аннан да миһербанлырак малай бар микән әле тагы...— Шулай диде дә Полли түткәй җылап та җибәрде.

— Минем Джом да шундый иде: уйный, шаяра үзе, әйтерсең лә эченә меңләгән шайтан кереп утырган. Үзе шундый шәфкатьле, ягымлы иде! И Ходаем, үзең ярлыка! Мин бит сөт өстен эчкән өчен арт сабагын укыткан идем аның, ачы тәм кергәч үземнән үк чыгарып түккәнем башымнан бөтенләй чыгып киткән. Яңадан берва-

кытта да күрмәм бит инде сабыемны.— Һәм Һарпер ханым да йөрәге ярылырдай итеп үксеп җылап җибәрде.

— Минемчә, Томга хәзер анда рәхәтрәктер инде,— диде Сид,— ә шулай да үзен яхшырак тоткан булса...

— Сид! (Полли түткәйнең ачуланып күзләрен елтыратканын чамалап алды Том.) — Эндәшмә дә, Томга кагылма да, ул юк инде хәзер. Хәзер инде ул Аллаһы Тәгалә кулында. Их, Һарпер ханым, ничекләр итеп чыдарга бу хәсрәткә! Белмим инде! Кайчакларда эчемне пошырса да, ул минем бердәнбер юанычым иде.

— Аллаһы Тәгалә үзе биргән, үзе алды. Алланың рәхмәте киңдер. Әмма бик авыр хәл инде, бик тә авыр. Әле менә үткән шимбә көнне генә Джо яныма килде дә борын төбемдә үк пистон шартлатты. Котларым алынды! Этеп җибәрүем булды, барып төшүе булды бичараның. Ул чагында каян беләсең аның шулай тиз... Их, шуны ул хәзер эшләсә, мин аңа хәер-фатихамны гына бирер идем дә үпкән-кочкан булыр идем...

— Әйе шул, мин бик яхшы аңлыйм сезнең хәлегезне, Һарпер ханым. Бик яхшы аңлыйм. Әле кичә генә төшке аш алдыннан Томым песине бер дару белән «сыйлаган» иде. Мәхшәр булды өйдә, бөтен нәрсәнең асты-өскә килде... Ә мин, Ходай үзе кичерсен инде, Томның маңгаен уймак белән төйдем. Бичаракаем минем, бәхетсезкәем! Аның каравы хәзер инде боларның берсен дә эшләмәс. Һәм аның мин ишеткән соңгы сүзләре — үпкә сүзләре иде...

Бу хатирә карчык өчен артык авыр булды, һәм ул ачы күз яшьләрен агызып тагын җылап җибәрде. Том үзе дә сулкылдый башлады,— хәер, башкаларны кызганудан бигрәк, ул үзен ныграк кызгана иде. Аны җылы сүзләр белән генә искә ала-ала Мэри дә җылап утырды. Ахыр чиктә Том горурланып куйды: үзен шундый әйбәт малай дип ул бервакытта да уйламый иде. Шулай да Полли түткәйнең хәсрәте аны бик нык дулкынландырды, ул шундук карават астыннан чыгып, муенына асылынып аны сөендерердәй булды. Әмма Том күңелендәге вәсвәсәгә бирелмәде һәм, сүзнең дәвамын тыңлап, тыныч кына ятарга тырышты.

Өзек-төтек сөйләүләренә караганда, малайларның югалуын алар

болай дип аңлаталар: башта малайларны су коенган чакта батканнар дип уйлаганнар, аннары кечкенә салның юкка чыкканын шәйләп алганнар, малайларның кайсысыдыр Джо белән Томның «тиздән безнең турыда ишетәчәкләр әле,» дип йөргәннәрен исенә төшергән. Шуннан соң акыллы башлар уйлана торгач, малайлар сал белән агып киткәннәр дә тиздән елганың түбән өлешендәге берәр шәһәрдә килеп чыгарлар, дигән фикергә килгәннәр; әмма көн урталарында салны шәһәрдән биш-алты чакрымда, Миссури яры буенда тапкач, бөтен халыкның өмете өзелгән, малайлар һичшиксез батып үлгәннәрдер, югыйсә алар төнгә хәтле ашамыйча тора алмаслар иде, өйгә кайтып килерләр иде, дип уйлаганнар. Гәүдәләре ни өчен табылмаган? — Чөнки алар елганың уртасында ук батканнар, дип фараз кылганнар, шулай булмаса, ярга чыгып җитә алган булырлар иде, чөнки өчесе дә яхшы йөзәләр иде, дип фараз кылган халык. Бу хәл чәршәмбе көнне кич булды. Якшәмбе көннең иртәсенә хәтле малайларның гәүдәләре табылмаса, димәк, бернинди өмет тә калмый, дигән сүз; якшәмбе көнне гыйбадәт вакытында аларга җеназа укырга җыеналар икән. Шуны ишетүгә Том сискәнеп куйды.

Һарпер ханым үксеп җылый-җылый барысы белән дә саубуллашты да ишеккә таба юнәлде. Әмма шул мәлдә ике хатын, кинәт берберсенең кочагына ташланып, аерылышыр алдыннан туйганчы тагын бер рәхәтләнеп җылашты. Полли түткәй Сид белән Мэрины һәрвакыттагыга караганда назлырак итеп үпте. Сидның яңаклары алсуланып китте. Мэри исә күз яшьләренә тыгылып чыгып йөгерде.

Аннары Полли түткәй йокларга ятар алдыннан тезләнде дә Томның рухына багышлап гыйбадәт кыла башлады. Аның әйткән сүзләрендә һәм калтыранып чыккан тавышында чиксез зур мәхәббәт сизелә иде, хәтта ки Том, караватт астында яткан килеш, кайнар яшьләрен агызды.

Полли түткәй урынына барып яткач та әле Томга бик озак тыныч кына, кыймылдамыйча ятарга туры килде; вакыт-вакыт түткәй ниндидер хәсрәтле авазлар чыгарып куйды, боргаланып һаман урынында әйләнгәләде. Ниһаять, ул тынычланды, ара-тирә генә йокы

аралаш ыңгырашкалап куйгалады. Малай караватт астыннан шуышып чыкты да, кулы белән шәмнең яктысын каплап, йоклап яткан тутасының йөзенә текәлде; аның йөрәге кызгану хисе белән тулды. Ул кесәсеннән чинар кайрысын тартып чыгарды да шәм яктысына куйды. Әмма кинәт аның башында ниндидер яңа фикер туды бугай, ул уйланып туктап калды. Томның йөзе яктырып китте, һәм ул, күрәсең, ниндидер бер карарга килеп, кайрыны алып кире кесәсенә салды. Аннары иелеп тутасының җыерчыклы иреннәрен үбеп алды, бер секунд та тоткарланып тормыйча бүлмәдән чыгып ишекнең келәсен элде.

Гадәттә, кечкенә пароход туктап торган пристаньга барып җиткәч,— бу сәгатьләрдә яр буенда берәү дә булмаганын Том белә иде — ул батыраеп судно эченә кереп китте. Пароходның каравылчысы каютага кереп тирән йокыга талган иде. Том койрыктан көймәне чишеп алды да, тавыш-тынсыз гына эченә кереп утырып, агымга каршы ишә башлады. Шәһәрне бераз үтүгә ул кыйгачлап тагын да тырышыбрак ишәргә тотынды. Малай нәкъ пристань турына барып туктады: бу эш — аның өчен күнегелгән нәрсә иде. Томның бер дә көймәне монда калдырып китәсе килмәде, чөнки көймә берникадәр дәрәҗәдә шул ук судно бит инде ул һәм, димәк, пиратның законлы табышы дигән сүз, ләкин аны бөтен җирдән эзләячәкләрен Том белә иде. Бу исә качкыннарның эзенә төшерергә мөмкин. Шуңа күрә малай көймәдән ярга сикереп кенә төште дә урман эченә кереп китте.

Урманда, йокысын җыңәргә тырышып, ул яхшылап ял итте, аннары лагерьга таба юл тотты. Төн инде үтеп бара иде, ул сайлык турына килеп җиткәндә бөтенләй яктырылып та бетте. Кояш югары күтәрелеп, мәһабәт елганы алтын нурлары белән бизәгәнче, Том тагын ял итеп алды, аннары суга кереп китте. Берникадәр вакыттан соң ул, баштан-аяк юеш килеш, лагерь читендә басып тора иде. Нәкъ шул чакта ул Джоның:

— Юк, һак, Том ышанычлы кеше, кире киләчәк ул,— дип әйтеп маташканын ишетте.— Чынлап әйтәм. Качмый ул. Мондый хәлнең пират өчен хурлык икәнен белә бит ул. Ә пират горурлыгы аның

өчен барыннан да өстенрәк. Нинди дә булса берәр мөгез чыгарып йөридер әле шунда. Беләсе иде!

— Аның әйберләре безнеке була бит инде хәзер?

— Шулайрак инде, ләкин бөтенләйгә үк түгел, Һак! Әгәр дә ул иртәнге ашка килеп җитмәсә, язган язуында Том аларны алырга кушкан.

— Ә ул килеп җитте! — дип кычкырып җибәрде Том һәм тантаналы кыяфәттә алар каршына килеп басты. Бу — сирәк очрый торган искиткеч гүзәл бер театраль күренеш иде.

Тиздән алар ысланган дуңгыз итеннән һәм балыктан мул итеп иртәнге аш оештырдылар, һәм ашарга утыруга Том башыннан үткәннәрен бизәкле-бизәкле сөйләргә тотынды. Хикәят ахыргача тыңланып беткәч малайлар тагын да ныграк тәкәбберләнә төштеләр һәм үзләрен бөек баһадирлар дип хис иттеләр. Көн уртасына кадәр йокысын туйдырырга дип Том күләгә җиргә барып ятты, ә калган пиратлар утрауны өйрәнү һәм балык тоту нияте белән урыннарыннан кузгалдылар.





XVI бүлек

Төшке аштан соң юлбасарлар шайкасы сайлыкка ташбака йомыркасы җыярга китте. Малайлар комга таяк белән төртеп-төртеп карыйлар да, йомшак җирен тапкач, тезләнеп куллары белән казырга тотыналар. Кайбер чокырдан бишәр-алтышар дистә йомырка килеп чыга. Йомыркалар ап-ак һәм түм-түгәрәк булып, әчтерхан чикләвегеннән бераз гына ваграк иде. Бу кичне пиратларның кичке ашы да бик бай булды — туйганчы йомырка тәбәсе ашадылар, икенче көнне иртән, җомга көнне дә алар шулай ук бик әйбәт сыйландылар.

Иртәнге аштан соң алар сайлыкта сикерешеп уйнадылар, кычкырыша-кычкырыша куышып, өсләреннән киемнәрен салып ташлап йөгерештеләр, аннары шәрә килеш сайлык буйлап су эченә таба кереп әллә кайларга кадәр барып җиттеләр. Кайчакларда көчле агым аларны аяктан егып ташлый, шуннан соң аларга тагын да күңеллерәк булып китә. Алар барысы берьюлы суга таба иелеп бер-берсенә су чәчрәтә башлыйлар, һәрберсе «дошманы» янына посып кына, үзенең битенә чәчрәтмәскә тырышып кына килә. Аннары шундук алар суда кул сугышы уйный башлыйлар, җиңүче башкаларны башы белән суга чумдырганчы шулай уйныйлар. Ниһаять, барысы бергә суга кереп чумалар. Өчесенең дә аяк-куллары кояшта ап-ак булып ялтырап-ялтырап китә, яңадан су өстенә калкып чыккач алар уһ-аһ килеп пошкырынып көлешәләр, төкеренә-төкеренә комсызланып һава сулыйлар.

Хәлдән тайгач алар яр буена йөгереп чыгып кайнар комга күмелеп яталар, аннары яңадан суга кереп чумалар, шуннан барысын да өр-яңадан кабатлыйлар. Кинәт аларның башына, безнең тәнебез нәкъ трико төсле икән бит, дигән уй килде; алар комга сызып түгәрәк арена ясадылар да өч клоуннан торган цирк оештырып җибәрделәр. Бу мактаулы рольне һәрберсенең үзе башкарасы килә иде.

Аннары алар, шарчыкларын алып, шулар белән туйганчы төрле уеннар уйнадылар. Джо белән Һак яңадан су коенырга кереп киттеләр. Том исә тәвәккәлләмәскә булды, чөнки ыштанын салып ташлаган чакта аягына бәйләп куйган шалтырак еланның шалтыравыгын төшереп калдырган булып чыкты. Әлеге тылсымлы төене булмаган көе моңарчы аны ничек көзән җыермагандыр, дип, ул аптырап калды. Шалтыравыгын тапмый торып Том суга керергә батырчылык итмәде, ул арада инде аның иптәшләре арып-талып ярга чыгып ял итәргә ятканнар иде. Әкренләп алар кайсы кая таралышып моңсу уйларга бирелделәр, һәрберсе туган йортын сагынып шәһәрчек ягына таба карады. Том, үзе дә аңышмыйча, аягының баш бармагы белән комга «Бекки» дигән сүзне сызгалады. Аннары ул, исенә килеп, язганын бозып ташлады, йомшаклыгы өчен үзен битәрләп алды, әмма чыдамады, шул исемне тагын язды, яңадан бозды, инде яңадан да коткыга бирелмәс өчен иптәшләрен үз янына чакырды.

Ләкин Джоның бөтенләй күңеле кителеп, рухы төшкән иде. Үзенең өен ул шундый да сагына иде, аның инде бу ачы сагышны күтәрерлек көче калмаган иде. Ул менә-менә җылап җибәрергә әзер иде. Һакның да күңеле төште. Хәтта Том үзе дә боек иде, ләкин ул бар көченә сагышын яшерергә тырышты. Вакыты җитмәс борын иптәшләренә белгертмәскә дигән бер сере бар иде аның; иллә дә мәгәр аларның күңеленнән гыйсъянчылык кайгысын йолып ташлый алмаса, серен ул хәзер үк ачарга да әзер иде. Һәм, күтәренке күңелле булырга тырышып, болай диде:

— Бу утрауда безгә кадәр дә пиратлар яшәгәндер дип уйлыйм мин. Әйдәгез, тагын бер кат әйләнеп чыгыйк. Монда берәр җирдә хәзинә күмелми калмагандыр. Әгәр алтын-көмеш тулы черек сандыкка юлыксак ни диярсез, ә?

Әмма бу сүзгә берсенең дә артык исе китмәде.

Малайларны кызыктырып булмасмы дип, Том тагын бер-ике тәкъдим кертеп карады, ләкин аның да файдасы тимәде. Джо моңсуланып, кара коелып таягы белән комны актаргалап утырган жиреннән болай диде:

— Их, егетләр, ташлыйк әле бу мәгънәсез эшне! Өйгә кайтасы килә бит. Шундый да ямансу монда!

— Юк инде, Джо, күнегерсең әле, аннары күңелле була башлый ул,— дип, үгетләргә тырышты аны Том.— Уйлап кына кара, балык каптырулары гына да ни тора бит монда!

— Балык тотасым килми минем, өйгә кайтасым килә!

— Их, Джо, мондагыдай итеп син тагы кайда су коена аласың?

— Нәрсәгә ул миңа коену? Төкерәм мин ул су коенуга хәзер, бирәү дә тыймагач... Минем өйгә кайтасым килә!

— Бар алайса, кайт! Маңка! Әниең янына кайтасың килә икән!

— Әйе шул, әнием янына кайтасым килә! Әниең булса, синең дә аның янына кайтасың килер иде! Мин синнән бер дә ким түгел! Маңка да түгел!

Джо мышкылдап куйды.

— Ярар алайса, бу жылакны без өенә, әнисе янына кайтарып жибәрик. Шулай бит, Һак? Мескен, ул бит әнкәсен сагынган. Ярар! Кайта бирсен! Ә сиңа ошый бит монда, әйеме, Һак? Без синең белән калырбыз бит, әйеме?

Һак: «Әй-й-е»,— дип куйды, ләкин аның да тавышында артык шатлану галәмәте сизелми иде.

— Моннан соң мин синең белән сөйләшмим. Менә шул! — диде Джо, урыныннан кузгалып.

Ул моңсуланып бер читкә китте дә киенә башлады.

— Харап икәнсең! — диде Том.— Бик кирәгең бар ие! Пират диген инде моны да! Һак белән без — синең кебек жылаклар түгел. Без монда калабыз, шулай бит, Һак? Тели икән, китә бирсен, аннан башка да торырбыз!

Тыштан салкын канлы булып күренергә тырышса да, Том шактый борчылган иде һәм чырайларын сытып киенеп маташучы Джога

дулкынланып карап торды. Джоның җыенганын йотлыгып карап торган Һакның кыяфәте аны тагы да ныграк борчый төште. Һакның эндәшмәвендә Том ниндидер шом тойды. Джо киенеп бетте дә хушлашып та тормыйча су эченнән генә Иллинойс ярына таба китеп барды. Томның йөрәге сызлана башлады. Ул борылып Һакка таба карап куйды. Тегесе, аның карашын күтәрә алмыйча, күзләрен аска төшерде.

— Минем дә кайтасы килә бит, Том,— диде ул ниһаять.— Монда ничектер ямансу булып китте, ә хәзер тагын да моңсурак булыр, әйдә, без дә кайтыйк.

— Кайтмыйм! Телисең икән, син дә кайт! Ә мин калам.

— Кайтыйм әле мин, Том...

— Бар, кем тота сине?!

Һак ком өстендә таралып яткан кием-салымын җыештыра башлады.

— Син дә кайтсаң иде безнең белән, Том! Чынлап менә, юньләбрәк уйлап кара әле. Без сине теге якта көтеп торырбыз.

— Сезгә мине бик озак көтәргә туры килер шул!

Һак боегып кына китеп барды. Том аягүрә баскан килеш аның артыннан карап калды, үзе исә, булган горурлыгын онытып, алар артыннан торып йөгерердәй булды. Ул, менә-менә малайлар туктарлар, дип өметләнә иде, ләкин алар тез тиңентен су эченнән баруларын дәвам иттерделәр. Томны коточкыч ялгызлык биләп алды. Ул, күңелендәге горурлык хисен тәмам басып, дуслары артыннан торып йөгерде.

— Туктагыз әле! Туктагыз! Минем сезгә әйтәсе сүзем бар! — дип кычкырды.

Тегеләр шундук туктап калдылар да аңа таба борылып карап тора башладылар. Артларыннан куып җитеп, Том аларга күңелендәге серен ачып салды. Алар аны ачу катыш тыңлап тордылар, ләкин аннары, аның кая таба сукалаганын аңлагач, чиксез куаныштылар. Ник аны баштук әйтмәдең, әйткән булсаң кайту турында сүз дә кузгатмаган булыр идек югыйсә диештеләр.

Акланырга теләп, Том нидер аңлатып маташкан булды, әмма

чынында исә әлеге сер дә аларны озак тота алмас дип уйлап, ул аны соңгы чара итеп саклаган иде.

Малайлар күңелләре күтәрелеп лагерьга әйләнеп кайттылар һәм рәхәтләнеп элекке уеннары белән мавыгып киттеләр, үзләре һаман Томның зирәклеге турында сөйләшәләр һәм аның тапкырлыгына сокланалар иде. Балык белән йомырка тәбәсе ашаганнан соң, Том тәмәке тартып карарга теләвен әйтте. Джо да шушы фикергә кушылды, һәм ул да тәмәке тартырга өйрәнергә каршы түгеллеген әйтте. Һак аларга трубкалар ясап, тәмәке тутырып бирде. Моңа кадәр боларның йөзем яфрагы төрелгән сигара гына тартканнары бар иде, тик ул сигара телне ачыттыра иде, һәм аны чын тарту дип исәпләп булмый иде.

Алар терсәкләренә таянып җиргә сузылып яттылар да иплəп кенә, курка-курка гына эчкә алып тарта башладылар. Тәмсез төтен тамак төбенә утыра иде, шулай да Том:

— Бик ансат икән бу! Шулай икәнен белсәм әллә кайчан өйрәнгән булыр идем инде,— диде.

— Мин дә,— дип, аның сүзен куәтләде Джо.— Берни түгел икән.

— Ничә тапкырлар бүтәннәрнең тартканын күргәндә: «Өйрәнәсе иде! Юк, минем хәлдән килмәс бу!» дип уйлый идем,— диде Том.

— Мин дә шулай дип уйлый торган идем. Әйе бит, Һак? Моны минем синең алда әллә ничә тапкыр әйткәнем булды, әйе бит, Һак?

— Әйе, әйе. Әллә ничә тапкыр,— диде Һак, аның сүзен раслап.

— Соң минем дә меӊ тапкыр әйткәнем бар. Берсендә бойня янында идек. Хәтереңдәме, Һак? Анда тагын Боб Таннер, Джонни Миллер белән Джеф Тэтчер бар иде. Минем әйткән исеңдәдер бит, Һак?

— Истә шул! — диде Һак.— Мин ул көнне ак шарчыгымны югалткан идем... Юк ла, ул көнне түгел, элекке көнне.

— Әйттем бит! — диде Том.— Һак та хәтерли әнә.

— Мондый трубканы мин көн буе да тарта алам,— диде Джо.— Минем тамчы да күңелем болганмый.

— Минем дә! — диде Том.— Мин дә көн буена тарта алган булыр идем, ә менә Джеф Тэтчер тарта алмас дип уйлыйм мин.

— Кая инде ул Джеф Тэтчерга! Ике генә тапкыр суырса да исереп егыла бит ул! Бер дә суыра алмый әле ул.

— Шулай инде, булдыра алмый, Джонни Миллер да булдыра алмый. Күрәсе иде, анысы ничегрәк тартыр иде икән!

— Нәрсәсен күрәсең аның! — диде Джо.— Бер суырудан ук кәкрәеп төшәчәк бит ул да.

— Дөрес, Джо. Менә хәзер безне малайлар күрсен иде, әйеме?

— Менә ичмасам кызык булыр иде!

— Ләкин чур, берәүгә дә бер сүз дә әйтәсе түгел! Берәр вакыт, барыбыз да бергә җыелгач, мин синең яныңа килермен дә: «Джо, трубкаң яныңдамы? Берәрне тартып җибәрәсе иде»,— дигән булырмын. Ә син берни дә булмагандай: «Янымдасын янымда да, тәмәкем генә шәптән түгел»,— дип җавап бирерсең. Ә мин: «Анысы ярый, тик катырак кына булсын»,— дигән булырмын. Шуннан син трубкаларыңны чыгарырсың да, икебез дә исебез китмичә генә тартып җибәрербез. Шаккатарлар иде менә шунда!

— Валлаһи, менә шәп булыр иде! Хәзер үк күрсеннәр иде алар безне!

— Әйе шул. Без аларга, пиратлыкта йөргән чакларда өйрәнгән идек тартырга, дип әйтсәк, көнләшеп үләрләр иде...

— Шулай шул, көнләшерләр иде шул.

Әңгәмә дәвам итте, шулай да тора-бара ул сүлпәнләнә төште, бәйләнешсез була башлады. Паузалар озынайганнан-озыная барды. Тәмәкечеләр нишләптер торган саен ешрак төкеренә башладылар. Төкерек бизләре котырынып эшләде; тел астына су җыела торды, төкереп кенә өлгер. Нихәтле генә арынырга тырышсаң да, су тамак төбенә тыгыла торды, күңел дә болгана башлады. Малайларның икесе дә агарынып калды, кыяфәтләре дә мескенгә әйләнде. Трубка хәлсезләнгән Джо Һарперның бармаклары арасыннан шуып төште. Томныкы да төшеп китте. Авыз эчендәге селәгәй бизләре һаман эшли торды, төкерек җыела торды. Ниһаять, Джо хәлсезләнгән тавыш белән:

— Мин пәкемне югалттым... Әллә эзләп киләсе инде...— диде.

Том да дерелдәгән иреннәре белән көчкә-көчкә генә, томлыга-томлыга гына:

— Мин дә эзләшимме соң?..— дип әйтә алды.— Син әнә теге яктан эзлә, ә мин монда, елга буена төшәм. Юк, юк, Һак, син барып йөрмә безнең белән, без үзебез дә табарбыз аны,— диде.

Һак урынына барып утырды да аларны сәгать буена көтте. Ямансулый башлагач ул иптәшләрен эзләп килергә булды. Аларны ул урман эченнән, бер-берсеннән шактый ерак җирдә тапты; тегеләрнең икесенең дә төсләре качкан, икесе дә каты йокыда иде. Әмма Һак, нинди хәвеф булса да, куркынычның инде узуын аңлады.

Ул көнне алар кичке аш вакытында бөтенләй сөйләшмәделәр. Ничектер юашланып калганнар иде. Ашаганнан соң Һак үзенә трубка тутыргач аларга да тутырып бирмәкче иде, ләкин малайлар кирәксенмәделәр, кәефләре юклыгын әйттеләр, төшке аш вакытында ниндидер бер ярамаган нәрсә ашаганга сылтадылар.

XVII бүлек

Джо, төн урталарында уянып китеп, башкаларны да уятты. Һава бик бөркү, күңелне изә торган ниндидер бер авырлык сизелә иде; мондый чакларда бернинди дә яхшылык көтеп булмый.

Һавада тыннарны кыса торган бөркүлек хөкем сөрүгә карамастан, малайлар һаман учакка таба елыштылар. Тын калып, алар ниндидер бер киеренке халәттә утырдылар. Учак яктыртып җиткерә алмаган бөтен нәрсә караңгылык эченә кереп югалган сыман тоела. Кинәт нидер дөрләп кабынгандай булды да, яфракларны яктыртып юкка чыкты. Аннары тагын да көчлерәк итеп яктыртты. Тагын яктыртты. Аннары агачларның очлары ишетелер-ишетелмәс кенә көрсенеп куйгандай итте һәм әйтерсең лә ыңгырашып алды; малайлар бит очларына ниндидер бер чит сулыш килеп бәрелгәнен шәйләгәндәй булдылар һәм, моның төнге рух икәнен чамалап, дерт итеп куйдылар. Аннары бөтен дөнья тынып калды. Кинәт яңадан ниндидер гайре табигый яктылык аларның куркынган, агарынган йөзләрен яктыртып алды, төнне көнгә әйләндерде, хәтта ки аяк асларында үскән үләнне аермачык күрерлек итте. Тонык кына булып күк күкрәп куйды, аның тавышы бөтен күк йөзе буйлап келтерәп үтте дә әллә кайларга китеп тынып калды. Салкын һава агымы бөтен яфракларны бердәй шыбырдатты, учак көлен күтәреп алды да, кар бөртекләредәй туздырып, кире җиргә китереп салды. Яңадан гайрәтле ут бөтен тирә-юньдәге урманны яктыртты һәм шул ук мәлне кайдадыр нәрсәнедер ярып сукты: әйтерсең лә малайларның

баш өстендә генә агачларның очлары телгәләнде. Караңгылык эчендә калган пиратлар котлары алынып бер-берсенә ныграк елыштылар. Яфраклар өстендә сирәк кенә төшкән эре яңгыр тамчылары биешә башлады.

— Тизрәк, палаткага! — дип боерды Том.

Алар, агач тамырларына абына-абына, кыргый йөзем сабакларына урала-урала, чәчелешеп чабыша башладылар. Котырынган көчле җил ду килеп урман буйлап үтте, шуның артыннан ук бөтен тирә-як шау-шу белән тулды. Күз чагылдыргыч яшен өзлексез диярлек бер-бер артлы елтырап торды, күк күкрәве бер минутка да тынмады. Ургый-ургый яңгыр яуды һәм, көчәя барган өермә, рәхимсезләнеп, аны тоташ шарлавык итеп җир өсте буйлап агызып китте.

Малайлар бер-берсенә нидер кычкыралар иде, ләкин улап торган җил һәм күк күкрәве аларның тавышын бөтенләй басып китте. Ниһаять, алар бер-бер артлы ничек кирәк алай палаткага барып җитеп аның эченә кереп тулдылар; чыланып беткән малайлар куркудан дер-дер калтырана иде; киемнәре манма су булса да, алар җыенысы бергә булуларына куандылар. Иске җилкән искиткеч бер гайрәт белән шапылдау сәбәпле, сөйләшергә теләсәләр дә, алар бер-берсенең тавышын ишетә алмаслар иде. Яшенле яңгыр көчәйгәннән-көчәя барды: ниһаять җил, кинәт исеп, җилкәнне бәйләп куйган җиреннән очыртып алып китте. Малайлар җитәкләшеп, минут саен абына-сөртенә, аяк-тезләрен бәреп күгәртә-күгәртә яр буенда җәелеп утырган бик зур бер имән төбенә таба йөгерделәр. Яңгырның иң нык көчәйгән чагы иде. Бертуктаусыз ялт-йолт килеп торган яшен яктысында бөтен нәрсә: бөгелеп-сыгылып утырган агачлар да, ап-ак күбеккә күмелеп котырынып аккан елга да, актарылып килгән дулкыннар да, ярның каршы ягындагы куе томан һәм кыйгач яңгыр пәрдәсе аша элем-чалым гына шәйләнгән мәһабәт кыялар да күләгәсез-нисез аермачык булып күренә иде. Баһадирдай зур агачлар, өермә басымына чыдый алмыйча, яшь агачларны чытырдатып сыта-изә минут саен гөрселдәп ава тордылар; өзлексез күк күкрәве колак тондыргыч көчле, әйтеп бетергесез куркыныч тоташ шартлауга әйләнде. Ахыр чиктә яшенле яңгыр утрау өстендә бөтен көченә

шундый итеп котырынды ки, утрауны ул кисәкләргә аерып ташлар да яндырып бетерер, агачларны очларына кадәр күмеп китәр һәм һәрбер җан иясен үтерер дәрәҗәгә җиткерер исәнгерәтер кебек — болар барысы да секунд эчендә эшләнер кебек тоелды.

Ниһаять, көрәш туктады, бер-берсенә каршы торучы гаскәрләр чигенә башлады, аларның каядыр еракта, янап һәм каһәрләп улаган тавышлары тынганнан-тына барды һәм җирдә әкренләп элекке тынычлык урнашкан сыман булды. Шактый ук нык куркынган малайлар лагерьга әйләнеп кайттылар; чинар агачын челпәрәмә китереп яшен суккан, нәкъ шул агач төбендә алар кунып ятканнар иде. Яшен суккан чакта аның төбендә булмауларына малайлар куанып бетә алмадылар.

Лагерьны да, учакны да су басып киткән, чөнки яшьлек гамьсезлеге белән малайлар учакны яңгырдан саклап калу өчен бер чара да күрмәгәннәр иде. Бу бик үкенечле хәл иде, чөнки өчесенең тиң өс-башы манма су булып, тешләре тешкә тимәде. Аларның моңа аермачык кәефләре китте, ләкин, эзләнә торгач, утның бер юан агач астына кереп, эчтән генә көйрәп ятканын искәреп алдылар. Малайлар эшкә керештеләр: егылып яткан агачлар астыннан юешләнмичәрәк калган чыбык-чабык, кайры ише нәрсә җыештырып, утны тергезергә тотындылар. Ниһаять, учак өр-яңадан кабынып китте. Малайлар аңа зур-зур ботаклар салдылар һәм ут, тимерче учагы шикелле, дөрләп яна башлады — балаларның яңадан күңелләре күтәрелеп китте. Пешкән дуңгыз итен ут өстенә тотып киптерделәр дә менә дигән итеп кичке аш ашадылар, аннары ут тирәсенә җыелышып утырып, таң атканчыга хәтле арттыра-арттыра төнге маҗаралар турында сөйләштеләр; йоклар урын барыбер юк иде, чөнки тирә-юньдә бер генә коры почмак та калмаган иде.

Кояшның беренче нурлары күренә башлауга күзләрен йокы баскан малайлар яр буендагы комлыкка барып сузылышып яттылар. Тиздән кояш шактый ук нык кыздыра башлады, малайлар торып сүлпән генә кәеф белән ашарга әзерләргә керештеләр. Ашаганнан соң алар тагын да авырая төштеләр, аяк-кулларын кузгата алмас хәлгә килделәр, һәм аларның яңадан да өйгә кайтасылары килә башлады. Том бу хәвефле галәмәтләрне шәйләп алды һәм пиратларның күңелләрен күтәрер өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләргә тырышты. Ләкин аларны алебастр шарлар да, цирк та, су коену да — дөньяда бернәрсә кызыктырмый иде инде. Ул үзенең серен аларның исенә төшерде, һәм малайларның йөзендә шатлык чаткылары кабынып киткәндәй булды. Бу сөенү хисе таралып юкка чыкканчы Том малайларны яңа бер уйдырма белән кызыктырырга ашыкты. Ул аларга вакытлыча пират икәнлекләрен онытып, индеецлар булып торырга тәкъдим итте. Бу фикер кызыктыргыч кебек тоелды: алар шундук өс-башларын чишенеп ташладылар, саз белән буяп тәннәренә сурәтләр төшерделәр, зебра сыман буй-буй тәнле булып калдылар. Шуннан соң алар, Англиядән сөрелеп китерелгән кешеләргә һөҗүм

итәргә дип, чабышып урманга кереп киттеләр, малайларның һәрберсе юлбашчы ролендә иде.

Әкренләп алар бер-берсенә каршы торучы кабиләләргә бүленделәр. Куркыныч итеп оран сала-сала засададан чыгып берсе өстенә берсе ташландылар, дошманнарын меңәрләп-меңәрләп кырып салдылар. Бу көнне күп кан коелды, һәм малайлар уеннан бик канәгать калдылар.

Үтә дә нык ачыгып һәм чын бәхеткә тарып алар кичке ашка лагерьга җыелдылар. Әмма шунда бер уңайсызлык килеп чыкты: берберсе белән дошманлашкан индеец кабиләләре шундук үзара солых төзергә тиешләр иде; чөнки, шулай булмаганда, алар бер-берсен кунак итә алмыйлар. Әмма ләкин тынычлык трубкасын тартмый торып ничек итеп солых төзисең ди? Солых төзүнең башка юлын алар белмиләр дә иде. Шунда индеецларның икесе хәтта гомер буена пират булып калмаганнарына үкенеп тә куйды. Ләкин башка чара юк иде һәм, теләсәң-теләмәсәң дә, күтәренке күңелле булып күренергә тырышып, чиратлашып трубканы суырырга туры килде. Ахыр чиктә алар индеец булуларына хәтта сөенделәр дә, чөнки бу аларны кайбер нәрсәгә өйрәтте: югалган пәке эзләүне дә хаҗәтсенмичә, алар инде бераз тәмәке тарта алдылар. Дөрес, балаларның хәзер дә күңелләре болганды, ләкин бу элекке кебек үк газаплы түгел иде. Малайлар шушы уңайлы шартлардан файдаланып калырга ашыктылар. Кичке аштан соң алар иләп кенә әлеге тәҗрибәне кабатладылар һәм бу очракта ул уңышлы тәмамланды. Шулай итеп кич күңелле үтте. Алар уңышлары белән шулхәтле бәхетле һәм горур иделәр, әйтерсең лә алты кабиләнең тән тиресен тунап арт чүмечен салдырып алганнар. Хәзергә малайларны калдырып торыйк: тартсыннар әйдә тәмәкеләрен, сөйләшсеннәр, туйганчы мактанышсыннар. Хәзергә без алардан башка да яшәп тора алабыз.

XVIII бүлек

Анның каравы, бу тын шимбә кичендә әлеге бәләкәй калада берәүгә дә алай күңелле түгел иде. Полли түткәй, Мэри, Сид һәм Һарпер ханымның бөтен гаиләсе авыр кайгы кичереп, күз яше коеп матәм киеме киде. Болай да артык шау-шулы булмаган бу калада хәзер аеруча тын иде. Кала кешеләре үзләренең гадәти эшләре белән аннан-моннан гына шөгыльләнделәр, сөйләшүен дә бик аз сөйләштеләр, еш кына көрсенгәләп куйдылар. Шимбә көн хәтта балаларга да ял булып түгел, авыр йөк булып тоелды. Уеннарын да алар юньләп уйный алмадылар, аларның уеннары әкренләп сүрелеп, үзеннән-үзе туктап калды.

Үзен кая куярга белмәгән Бекки Тэтчер көн ахырында бушап калган мәктәп ишегалдына барып керде. Әмма анда да кызны юатырдай бер нәрсә дә юк иде.

«Их, минем хәзер һич югында шул бакыр шарым булса икән! — дип уйлады ул.— Анның турында истәлек булырдай бернәрсәм дә калмады шул».

Бекки тамагына килеп тыгылган күз яшьләрен йотып җибәрде.

Кинәт кыз барган җиреннән туктап калды.

— Том нәкъ менә шушында басып торган иде...— диде ул.— Их, әгәр шул сөйләшү яңадан кабатлана торган булса, мин беркайчан да аңа алай дип әйтмәс идем! Ләкин ул юк, һәм мин яңадан бервакытта да, беркайчан да аны күрә алмам инде!

Бу фикер кызның тәмам кәефен кырды, һәм ул, кайнар яшьләрен агыза-агыза, моннан китеп барды. Аннары бер төркем малайлар белән кызлар — Том белән Джоның иптәшләре — килеп чыкты; алар койма буенда туктап, ишегалдына таба карап тора башладылар,

үзләре пышылдап кына Томны соңгы тапкыр кайда күрүләре хакында хөрмәт белән сөйләшәләр иде, һәм шул чакта ул менә фәлянне-фәлянне эшләде, шулай-шулай дип әйтте, дип, искә алдылар, күрәсең, хәвеф-хәтәр буласын сизенгәндер, дип юрадылар; һәм сөйләгән берсе һәлак булган малайларның ул чакта кайдарак басып торганын төптөгәл иттерел күрсәтә һәм: «Менә мин хәзер ничек басып торсам, шулай тордым, ә ул — менә син ничек басып торсаң, шулай басып торды, бөтенләй яп-якын иде, һәм ул шундый итеп елмайды, һәм мин кинәт шундый әсәрендем — кинәт кенә шундый да куркыныч булып китте, аңлыйсызмы? Ул чакта мин, әлбәттә, берни дә аңламадым, хәзер генә эшнең нәрсәдә булганын чамалыйм»,— дип өсти иде.

Һәлак булган малайларны исән чакта иң соңыннан кем күргән? Шул турыда бәхәс купты: күпләр малайларны иң соңыннан очраткан кеше булып күренергә тырышты, ә аларның сүзен башкалар юкка чыгарырга маташты; ниһаять, мәрхүмнәрне иң соңгы булып күрүчеләрнең кем икәнлеге ачыклангач, болар тәкәбберләнеп борын чөйделәр, башкалар исә, аларга кызыгып, авыз ачып карап торды. Ә бер бичарасы шактый ук горурланып:

— Ә Том Сойер бер мәртәбә мине нык кына итеп тукмап та ташлады! — дип белдерде.

Әмма аның үзен данга күмәргә маташуы уңышлы барып чыкмады, чөнки бөтен малайлар диярлек шулай дип әйтә алырлар иде. Һәлак булган каһарманнар турында гәпләшә-гәпләшә укучылар өйләренә таралышты.

Икенче көнне, якшәмбе мәктәбендә дәресләр беткәч, чиркәү чыңы гадәттәгедән үзгәрәк булып, салмаграк һәм моңсурак ишетелде. Бу еламсыраган матәм авазлары ул якшәмбедә табигатьтә хөкем сөргән уйчан тынлыкка тулысынча тәңгәл килә иде. Кала кешеләре чиркәү буена җыела башладылар, әлеге кайгылы

вакыйга турында сөйләшеп алу өчен алар чиркәү болдырында тукталып калдылар. Әмма чиркәүнең эченә кергәч инде пышылдашулар тынып калды. Хатын-кызлар үзләре утыра торган эскәмияләренә таба үтеп киткәндә тынлыкны бары тик күлмәкләренең чыштырдавы гына боза иде. Бу кечкенә чиркәүдә кайчан да булса берәр вакыт кешенең шушы кадәр күп булуын һичкем хәтеренә төшерә алмады. Ниһаять, Мэри һәм Сид белән бергә Полли түткәй, алар артыннан — авыр кайгыга чумган Һарперлар гаиләсе килеп кергәч бина эчендә нидер көткәндәге сыман киеренке тынлык урнашты... Гыйбадәт кылучылар барысы бер кешедәй — шул исәптән карт рухани үзе дә — утырган урыннарыннан хөрмәт белән торып бастылар һәм һәлак булган балаларның туган-тумачалары алгы рәтләрдәге урыннарга урнашканчы аягүрә калдылар. Аннары яңадан шомлы тынлык урнашты, ул тынлыкны вакыт-вакыт тыелып кына елаган тавыш бүлдерде. Ниһаять, рухани кулларын җәеп җибәрде дә гыйбадәт кыла башлады. Дулкынландыргыч гимн җырладылар, аның артыннан «Мин яңадан терелеп яши башлыйм» дигән сүзләр китте.

Аннан соң вәгазь башланды, һәм рухани үзенең нотыгында һәлак булган малайларны күкләргә чөеп мактарга тотынды; алар шундый акыллы да, уңган да, игелекле дә булган икән; чиркәүдәге кешеләрнең бер дә үкенмәгәне калмады; аларның һәрберсе үз-үзеннән: нишләп соң әле мин бу бичара балаларның бер дә яхшы сыйфатларын күрә белмәгәнмен, гел җитешсез якларын гына күргәнмен, дип сорады.

Рухани алар тормышыннан күңел йомшартырлык берничә вакыйга сөйләде: малайлар ягымлы да, йомшак күңелле дә, игелекле дә булган икән; тыңлап утыручылар бу гаҗәеп балаларның вөҗданлы һәм гүзәл кешеләр икәненә җиңел генә инана алдылар һәм, балаларның исән чакта кылган гамәлләрен шуклыкка исәпләп, шул чакта аларны әйбәтләп каеш белән ярырга кирәк, дип санаганнары өчен вөҗдан газабы кичерделәр, руханиның нотыгы торган саен җанны эретә барды, халыкның күңеле нечкәргәннән-нечкәрде һәм, ниһаять, һәлак булганнарның туган-тумачалары җылау-сыктавына барысы да бердәм кушылды; рухани үзе дә, тыела алмыйча, кафедра артында җыламсырап алды.

Арттагы рәтләрдән ниндидер тавыш ишетелгәндәй булды, ләкин аңа берәү дә игътибар итмәде, шул арада чиркәүгә керә торган ишек шыгырдап ачылды. Җылап торган рухани күзеннән кулъяулыгын алса... аптырап калды! Башта ул караган якка таба бер кеше борылып карады, аннары тагы берәү, аннары чиркәүдә булган бөтен кеше, урыннарыннан бердәм күтәрелеп, батып үлгәнгә саналган өч малайның эскәмияләр арасыннан атлап килгәнен күрде: иң алда — Том, аның артыннан — Джо, алар артыннан сәләмәләрен җилфердәтеп Һак атлый иде. Алар артта яшеренеп, үзләре турындагы җеназа сүзләрен тыңлап торганнар икән. Полли түткәй, Мэри һәм Һарперлар үзләренең терелеп кайткан сөекләләренә таба ташландылар һәм аларны үбәргә-кочарга тотындылар, коткарганы өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләр укыдылар, бичара Һак кына нишләргә белмичә аптырап, үзенә таба юнәлгән нәфрәтле карашлардан кая керер тишек таба алмыйча басып торды. Тирә-ягына карангалап инде чыгып шыларга гына әзерләнгән иде — ул арада Том аны кулыннан эләктереп алды да Полли түткәенә әйтте:

— Ни дигән сүз инде бу! Һак өчен дә кем дә булса сөенергә тиештер бит! — диде.

— Һәм сөенер дә, һичшиксез сөенер! Ул бичара ятимне күрүемә менә мин үзем башлап сөенәм,— дип, Полли түткәй Һакны сөяргә-кочарга тотынды, моның белән ул малайны тагын да ныграк каушата гына төште. Кинәт рухани бар көченә кычкырып җибәрде:

— Аллаһы Тәгаләне барлык рәхим-шәфкатьләре һәм игелекләре өчен күкләргә күтәреп мактыйк. Ихлас күңелдән данлыйк без аны! — диде.

Һәм бөтен мәхәллә халкы мактау сүзләре көйли башлады. Чиркәү гөмбәзен тутырып тантаналы рәхмәт гимны яңгырады, һәм диңгез пираты Том Сойер, аның маҗараларына таң калган яшь иптәшләренә карап, күңеленнән бу минутларны гомеренең иң гүзәл мизгелләре дип санады.

Оятсыз рәвештә алданып кәкре каенга терәтелгән булсалар да, мәхәллә кешеләре бу кадәр рухланып башкарылган рәхмәт гимнын яңадан ишетү хакына тагын бер кат алданырга да риза икәнлекләрен белдерделәр.

Полли түткәенең үзгәреп торучан кәефенә карап, Томга бу көнне бүтән вакыт белән чагыштырганда ел буена җитәрлек тукмагы да төште, үбү-кочулары да эләкте; үзенә карата булган рәхмәтнең муен тамырына утыртудамы яисә кочып-үбүдәме — кайсысында ныграк чагылганын ул яхшылап аера алмады.



XIX бүлек

Томның сере шуннан гыйбарәт иде: пират дуслары белән бергә өенә кире әйләнеп кайтып, үзләрен җирләү алдыннан укыла торган җеназада яшерен генә катнашырга уйлый иде ул. Шимбә көнне, күз бәйләнгән чакта, алар бүрәнәгә атланып Миссури ярына килеп чыктылар да каладан биш-алты миль җирдә урманда кунып калдылар; таң алдыннан алар тыкрыклар буйлап кына чиркәүгә кайтып кердeләр һәм артта, ватык-җимерек эскәмияләр арасына кереп, калган йокыларын шунда йоклап бетерергә дип ятканнар иде...

Дүшәмбе көнне иртәнге аш вакытында Полли түткәй дә, Мэри дә Том белән бик ягымлы сөйләштеләр, берсеннән-берсе уздыра-уздыра аның һәр теләгәнен үтәргә тырыштылар. Аш янында сүз тынып тормады. Җаен туры китереп, Полли түткәй шунда болай диде:

— Йә, ярар, Том, атна буена диярлек бөтен кешене җәфалау сезгә кызык та булгандыр, әмма синең шундый каты бәгырьле, мәрхәмәтсез булуың мине бик рәнҗетә. Бүрәнәгә атланып үзегезнең җеназагызга кайта алгансыз икән, димәк, син үзеңнән үлмәвең хакында, өйдән качып китүең хакында ничек тә булса миңа хәбәр бирә алган булыр идең.

— Әйе, Том, син шулай итә ала идең,— диде Мэри,— синең бу турыда башыңа килмәгән, югыйсә һичшиксез шулай эшләгән булыр идең, әйеме?

— Чынлапмы, Том? — дип сорады Полли түткәй, һәм аның йөзендә өмет чаткылары балкыды.— Әйт әле зинһар, башыңа килсә хәбәр биргән булыр идеңме?

— Мин... мин... әйтә алмыйм шул... Бу бит безнең бөтен уенны бозган булыр иде.

— Их, Том, мин тагы әз генә дә булса мине яратасыңдыр дип өметләнгән идем,— диде Полли түткәй кәефе китеп, Том хәтта уңайсызланып калды.— Минем турыда уйлый алсаң, бер дә юк эше булмас иде.

— Йә инде, түткәй, нәрсә инде? — дип, Томны якларга ашыкты Мэри.— Гомергә шул бит инде Томның — ашыга-кабалана, нәрсә кирәген үзе дә оныта!

— Шулай булуы бик кызганыч. Ә менә Сид исенә төшергән булыр иде. Бу якка чыгып миңа хәбәр итәр иде. Кара аны, Том, берәр вакыт исеңә төшәр дә, минем турыда уйламаганыңа үкенерсең, әмма инде соң булыр.

— Йә инде, түткәй, сезне ятканымны беләсез бит.

— Берәр ничек шуны сиздерсәң, әллә белгән дә булыр идем.

— Бу турыда уйламавым өчен мин хәзер үкенәм,— диде Том чыннан да үкенеп,— аның каравы, мин сезне төшемдә күрдем. Бер дә юк эше түгел ич, әйеме?

— Әйтик, моның әллә ние юк-югын, мәче дә кайчак төшләр күрә, шулай да, гел булмаган эше түгел, билгеле. Шуннан, ни күрдең инде син төшеңдә?

— Чәршәмбе көнне кич шундый төш күрдем: имеш, сез әнә тегендә карават янында утырасыз икән, дим... Ә Сид утын тартмасы янында утыра икән. Аның янәшәсендә — Мэри, имеш.

— Без, чыннан да, шулай утырган идек. Без һәрвакыт шулай утырабыз, һич югы төшеңдә булса да исеңә алуың өчен рәхмәт инде.

— Аннары, имеш, Джо Һарперның әнисе монда икән, дим.

— Ул бит чыннан да монда иде! Тагын ни керде төшеңә?

— Күп инде ул. Тик хәзер барысы да буталып кына бетте.

— Йә, исеңә төшерергә тырышып кара әле!

— Тагын... җил... әйе, әйе, җил...

— Исеңә төшер инде, Том! Нәрсә — җил?

Том бармагын маңгаена куйды да, уйланып торган атлы булып, болай диде:

— Әйе, әйе, исемә төште. Җил шәмне өреп сүндерде.

— Йа Ходай! Шуннан соң, Том, шуннан?

— Туктагыз әле, искә төшерергә ирек бирегез. Әйе, әйе, сез әйттегез, бу ишек... дидегез...

— Йә, Том!

— Туктагыз инде, уйларга ирек бирегез, бер генә минут! Әйе, сез, ишек ачылып киткәндәй булды, дидегез...

Мин бит чыннан да шулай дидем... Хәтереңдәме, Мэри? Йә, аннары?

— Аннары, аннары... Белмим инде, шулай да миңа сез Сидны...

— Нәрсә, нәрсә Сидны?.. Кая җибәрдем мин аны? Нишләргә куштым?

— Сез аңа... сез аңа... Әйе, ишекне ябарга куштыгыз.

— Менә, менә бит, минем мондый хәлне гомеремдә дә ишеткәнем юк. Менә шуннан соң ышанма инде төшкә. Хәзер үк Сирини Һарперга барып сөйләргә кирәк бу турыда. Карап карыйк, шуннан соң да имеш-мимешләргә ышанырга ярамый дип әйтергә җөрьәт итәр микән! Сөйлә инде, Том, тагын ниләр булды?

— Хәзер инде, түткәй, бары да исемә төште. Аннары сез... ни дидегез... минем хакта — ул явыз түгел, ул шук һәм дуамал гына... дидегез, аны артык гаепләп тә булмый инде, дидегез.

— Әйе, әйе, мин нәкъ менә шулай дидем дә! Йа Хода! Йә, тагын ниләр, Том?

— Аннары сез җылап җибәрдегез.

— Дөрес, дөрес, җылап җибәрдем! Һәм беренче тапкыр гына да түгел. Аннары?

— Аннары миссис Һарпер да җылый башлады һәм ул да: Джо да әйбәт бала иде, дип сөйләде, үзе үк чыгарып түккән сөт өсте өчен аны кыйнаганына үкенүен әйтте.

— Том, әүлияләр төшкән синең янына! Син хикмәтле, изге төш күргәнсең! Менә нәрсә булган ул! И Ходаем! Тагын ниләр, сөйлә инде!

— Аннары Сид әйтте... ни... диде...

— Мин берни дә әйтмәдем бугай...— диде Сид.

— Юк, әйттең, Сид,— диде Мэри.

— Туктагыз инде, Том сөйләсен! Йә, ни диде ул, Том?

— Ул болай диде: җирдәгегә караганда күкләрдә аңа яхшырак булыр. Шулай да, аңа тәртиплерәк булырга иде, диде...

— Ишетәсезме? Нәкъ шулай диде дә ул!

— Һәм сез аңа туктарга куштыгыз.

— Шулай булмый ни! Әлбәттә туктарга куштым. Ихлас, фәрештә булган безнең яныбызда. Һичшиксез булган!

— Миссис Һарпер исә Джоның пистон шартлатып куркытканын сөйләде, ә сез мәче турында, дару турында сөйләдегез.

— Шулай, шулай!

— Аннары безне елгадан эзләмәкче булулары турында, җирләүнең якшәмбе көнне буласы турында күп сүз булды. Аннары сез миссис Һарпер белән кочаклаштыгыз да җылаштыгыз, аннары ул китеп барды.

— Барысы да нәкъ шулай булды! Менә минем шушы урында утыруым ничек хак булса, болар барысы да шулай ук хак. Үз күзең белән күргән булсаң да, син бу турыда шушы кадәр яхшы итеп сөйли алмас идең. Тагын ниләр? Йә инде, Том?

— Аннары сез минем рухка дога кыла башладыгыз, мин сезне күреп, һәр сүзегезне ишетеп тордым. Аннары сез йокларга яттыгыз. Мин сезне шундый да кызгандым, кулыма бер агач кайрысы алып, шуңа: «Без батып үлмәдек, без качып китеп пиратларга гына әйләндек»,— дип яздым да өстәлдәге шәм янына куйдым; аннары, имеш, сез йокыга талдыгыз һәм сезнең йөзегез шундый да миһербанлы иде, хәтта ки мин, имеш, сезнең яныгызга иелдем дә иренегездән үбеп алдым.

— Чынлапмы, Том, дөресме? Шуның өчен мин синең барлык гаепләреңне кичерәм! — һәм ул Томны кочагына алып кысты, ә Том үзен иң кабахәт кеше итеп хис итте.

— Гәрчә бу төш кенә булса да, әйбәт инде, әлбәттә...— диде Сид, үз-үзенә әйткән сыман, әмма бар кешегә дә ишетелерлек итеп.

— Эндәшмә, Сид! Кеше төшендә дә өнендә эшләргә теләгәнен эшли. Менә сиңа алманың иң зурысы, Том! Кайчан да булса бер өйгә кайтырсың дип өметләнеп, сиңа дип саклаган идем. Әйдә, бар

тизрәк мәктәбеңә... Мине кызганып, сине кайтарган өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләремне күндерәм; аңа ышанып, аның васыятьләрен тоткан кешеләргә карата ул сабыр һәм шәфкатьле була, гәрчә мин лаек булмасам да, ул миңа карата да рәхим-шәфкать күрсәтте... Хәер, ул мәрхәмәтен лаеклы кешеләргә генә бүләк итә торган булса, хәзер җир йөзендә, дөньялыкта елмайган атлы булып йөрер тә, үлеменнән соң оҗмахта мәңгелек тынычлыкта калырга хаклары булган кешеләр аз булыр иде. Йәгез, Сид, син дә, Мэри, Том, сез дә инде барыгыз, тизрәк таралышыгыз — сезнең белән артык гәп сатып торырга вакытым юк минем!

Балалар мәктәпкә киттеләр, Полли түткәй исә миссис Һарпер янына ашыкты, ул, Том күргән төшләр турында сөйләп, аны могҗиза булуына ышандырырга исәп тотты. Сид өйдән чыгып киткәндә уйлаган уйларын кычкырып әйтмәскә булды. Ә ул:

«Ничектер бик сәер әле бу. Шундый озын төш күреп, бер дә хаталанмыйча истә калдырырга була микәнни?» — дип уйлады.

Том үзен чып-чын каһарманнарча хис итте! Ул шаярмады да, сикергәләмәде дә, үз дәрәҗәсен белеп кенә, чын пиратларча, һәркемнең күз карашы үзенә төбәлгәнен сизеп кенә атлады. Үтеп киткәндә ул үзенә төбәлгән карашларны күрмәмешкә һәм үзе турында сөйләнгән сүзләрне ишетмәмешкә салышты, күңеленнән исә боларның барысы белән дә хозурлана иде. Кечкенәләр аның артыннан калмыйча ияреп йөрделәр, аның янында булулары белән, куып җибәрмәве белән горурландылар, әйтерсең лә ул отряд башында торучы барабанчы яисә шәһәргә килеп керүче зверинец башындагы фил иде. Яшьтәшләре Томның өйдән чыгып китеп йөрүен белмәмешкә салыштылар, ә үзләре эчтән генә аннан үлә язып көнләштеләр. Аның кебек кояшта янып каралыр өчен, аның кебек данга ия булыр өчен алар бөтен нәрсәләрен бирергә әзер иделәр. Ләкин Том, хәтта тулы бер цирк бәрабәренә дә, бу сыйфатларыннан ваз кичәргә теләмәс иде.

Мәктәптәге бөтен балалар Том белән Джо Һарперга шундый да исләре китеп шаккатып карадылар ки, хәтта тегеләр, тиз арада масаеп китеп, борын чөя башладылар. Үтә дә нык кызыксынучыларга алар үзләренең маҗаралары турында сөйли башладылар, әйе, бары

тик сөйли башладылар гына: тиз генә сөйләп бетерә торган нәрсә түгел иде бу, чөнки аларның бетмәс-төкәнмәс хыяллары яңадан-яңа уйдырмалар өстәп торды. Ә инде Том белән Джо трубкаларын чыгарып төтәтә дә башлагач, аларның даны гомумән дә буй җитмәс югарылыкка менде.

Хәзер Том, Бекки Тэтчерга бөтенләй дә игътибар бирмичә, аннан башка да яшәргә мөмкин дигән карарга килде. Пират дигән даны да бик җиткән иде аңа. Шул даны исәбенә яшәячәк ул. Хәзер инде Беккиның бәлки дуслашасы да килер. Килсә соң! Шунда ул, башка кайберәүләр кебек, Томның да туң йөрәкле дә, ваемсыз да була алуын күрер... Ә, менә Бекки үзе дә килә икән. Том аны күрмәмешкә салышты. Ул бер читтә басып торган малайлар-кызлар янына китте дә шулар белән сөйләшә башлады. Ул битләре алсуланган Беккиның күзләрен елтыратып иптәш кызлары белән куышлы уйнап йөргәнен күрде; берәрсен әбәкли алуына Бекки чырылдап кычкырырга тотына иде. Том шуны да искәрде: берәрсен әбәкләргә омтылганда Бекки һәрвакыт аның янында булып чыга, берәрсен тота калса инде яшертен генә Томга таба карап ала иде. Бу хәл Томның шөһрәткә сусаган күңелен күтәреп җибәрде, һәм ул, Бекки белән килешәсе урында, тагын да ныграк киреләнергә карар кылды. Беккиның нәрсә теләгәнен аңлап, ул аңа берничек тә юл куймаска булды һәм аны күрмәмешкә салышты. Хәзер Бекки иптәш кызларын куып йөрүдән туктады һәм кыяр-кыймас кына шул тирәдә йөренә башлады. Ул ара-тирә көрсенеп куйгалады. Томга таба яшертен генә моңсу караш ташлап алгалады. Кинәт ул Томның күбрәк Эмми Лоуренс белән сөйләшкәнен искәрде. Беккиның күңелен газаплы сагыш хисләре биләп алды. Ул борчылды, үз-үзенә урын таба алмады, бер читкә таба китәргә дә омтылып карады. Ләкин тыңлаусыз аяклары, киресенчә, Том белән Эмми басып торган төркемгә таба атлады. Том янында басып торган бер кызга Бекки:

— Их, юньсез дә кеше инде син, Мэри Остин! Нишләп якшәмбе мәктәбенә килмәдең? — дип сүз катты.

— Нишләп алай дисең, булдым ич мин, күрмәдеңмени?

— Шулаймыни? Кайда утырган идең соң син?

— Мин гел мисс Питерс классында булам бит. Ә мин сине күрдем.

— Шулаймы? Кызык, мин нишләп күрмәдем икән соң сине? Мин сиңа пикник турында әйтмәкче идем.

— Шулаймы? Кем оештыра соң аны?

— Әнием. Минем өчен оештыра.

— Мин дә килсәм ярар микән?

— Әлбәттә. Минем өчен оештырыла бит ул. Үзем теләгән кешене чакырам инде мин. Сине дә чакырам.

— Ярар! Кайчан була ул?

— Озакламый. Бәлки каникул көннәрендә булыр.

— Бөтен кызларны, бөтен малайларны да чакырасыңмы соң?

— Әйе, барлык дусларымны чакырам... Минем белән дус буласы килгән кешеләрнең бөтенесен дә чакырам.

Ул яшертен генә Томга таба карап алды, әмма Том бу вакытта Эмми Лоуренска утрауда булган коточкыч өермә турында, яшеннең бинһаян зур чинар агачын «чәрдәкләп бетерүе» турында, үзенең шул мәлдә чинар агачыннан «өч кенә адымда» торуы хакында сөйләп маташа иде...

— Ә миңа ярыймы соң пикникка килергә? — дип сорады Грэси Миллер.

— Нигә ярамасын!

— Ә миңа? — диде Салли Роджерс.

— Сиңа да ярый!

— Миңа да ярыймы? — дип сорады Сюзи Һарпер.— Джога дамы?

— Ярый әлбәттә!

Том белән Эммидан башка барысы да бер үк сорауны бирде һәм, уңай җавап алгач, сөенеп кул чапты.

Шуннан соң Том исе китмичә генә Беккига арты белән борылды да Элми Лоуренс белән сөйләшә-сөйләшә китеп барды. Беккиның иреннәре дерелди башлады, күзләре яшьләнде, ләкин ул, ачынуын яшереп, шат күңелле булырга тырышты, сөйләнүен дәвам итте. Ләкин инде аның өчен пикникның да, һәртөрле башка нәрсәнең дә берниди кызыгы калмаган иде. Ул үзен уратып алган иптәш

кызларыннан арынырга ашыкты һәм, бер аулак урынга китеп, хатын-кыз халкы әйтмешли, туйганчы бер җылады. Һәм, дәрес башлануын белдереп кыңгырау чылтыраганчы күңелсезләнеп, гарьләнеп шунда утырды. Үз хәлен ул кешегә күрсәтмәскә тырышты. Аннары кызый торып аягына басты, башын чайкап озын толымнарын артка җибәрде, аның күзләрендә ачулы чаткылар елтырый иде. Һәм ул, инде хәзер нишләргә икәнен беләм дигән карарга килгән иде.

Том тәнәфестә Эмми Лоуренс тирәсендә чуалуын дәвам итте, үзенең өстен чыгуы белән хозурланды. Эмми белән бергә йөргәндә ул һаман Беккига күренергә, аның йөрәген бозарга тырышты. Ниһаять, ул Беккины күреп алды, һәм шундук аның кәефе кырылды: мәктәп артындагы эскәмиядә, Альфред Темпль белән, башын-башка куеп, Бекки, китап карап утыра иде. Алар икесе дә шундый мавыкканнар, хәтта ки үзләреннән башка дөньяда ни барын да искәрмиләр иде. Көнчелек хисе Томның кан тамырлары буйлап ут булып йөгерде. Аның үз-үзенә ачуы килде: Бекки бит аның янына башлап үзе килде, нигә килешмәскә иде шунда! Шул минутта ул үзен ахмак дип һәм күңеленә килгән башка төрле әрләү сүзләре белән тиргәде. Үкенүеннән ул җылап кына җибәрмәде. Алар ары узып киттеләр. Эмминың сөенечтән теле-телгә йокмады, Томның исә теле әйтерсең лә аңкавына ябышкан иде. Ул Эмминың ни сөйләгәнен дә ишетмәде, кыз җавап көтеп аңа карап торганда теленә ни килде шуны әйтте. Әлеге ачу китергеч күренеш аның йөрәген ничек кенә бозса да, ул һаман шул мәктәп бинасы артына таба омтыла иде. Ул үзен-үзе җиңә алмый иде. Беккиның бөтенләй игътибар итмәве Томның җенен чыгарды. Хәлбуки, кыз барын да искәрә, җиңүнең үзе ягында икәнен яхшы аңлый һәм хәзер Томның үзе кебек газаплануын күреп куана иде.

Эмминың күңелле итеп тәтелдәвенә Том түзеп тора алмый башлады. Ул бик әһәмиятле бер эше булуына һәм болай да инде соңга калуына ишарә итте, тик аның файдасы тимәде, кыз һаман сандугач урынына сайравын белде. «Их, җәһәннәм артына гына олаксаңчы! Шулай ук мин синнән котыла алмам микәнни?»— дип уйлады Том. Үзенең эше барын һәм аңа китәргә кирәклеген ул ачыктан-ачык әйтте,

кыз исә аңа эчкерсезлек белән дәрестән соң «шушы тирәдә» көтәчәген белдерде. Том шундук, кызга нәфрәтләнү дәрәҗәсенә җитеп, китеп тә барды. «Ичмасам, бүтән берәр малай булса икән,— дип уйлады Том тешләрен шыгырдатып.— Шәһәрдәге теләсә кайсы малай булсын иде, тик Сент-Луидан килгән шушы мактанчык кына булмасын иде. Энәдән-җептән киендем дигәч тә, аристократ булган, имеш! Әллә кемгә куеп үзен! Кирәгеңне биргән идем бит инде мин синең калага килгән көнне үк! Тагын эләгерсең әле, изәрмен измәңне...»

Том күз алдына китергән дошманын тукмарга ук кереште — йодрыкларын һавада селтәде, аяклары белән тибеп җибәрде. «Әле син шулаймы? Абыем дип әйт. Икенче вакыт белерсең менә!» Фараз ителгән сугыш Томның җиңүе белән тәмамланды.

Озын тәнәфескә чыккач Том өенә кайтып китте. Беркатлы Эмминың сөенүен күреп торуны аның намусы күтәрә алмады, көнчелек хисенә исә чыдарлык хәле калмаган иде. Бекки яңадан Альфред белән бергә рәсем карый башлады, әмма вакыт үтә торды, Том һаман күренмәде, газаплар кеше калмаган иде. Кызның рухы төште, уенның кызыгы беткән иде; Беккиның зиһене таралып, эче поша башлады, ул сагышлы уйларга бирелде, бер-ике тапкыр кыз сагаеп та калды, ниндидер аяк тавышларына колак салды, әмма бу юкка өметләнү иде — Том һаман да килмәде.

Ахыр чиктә Беккиның бөтенләй кәефе кырылды, эшнең шулай тирәнгә китүенә ул үкенә башлады. Бичара Альфред, кызга үзе белән күңелсез икәнен күрсә дә, һаман тынасы итмәде:

— Менә бу рәсемне генә карагыз әле! Ә менә монысы тагын да матуррак,— дип кызны мавыктырырга тырышты. Бара торгач Бекки сабырлыгын җуйды:

— Бәйләнмәгез әле, зинһар! Кирәге юк миңа сезнең рәсемнәрегезнең! — Шунда ул җылый ук башлады һәм сикереп торды да йөгереп китеп барды.

Альфред аның артыннан кузгалды һәм юата башларга җыенган гына иде, кыз аңа:

— Китегез дим, тынычлыкта калдырыгыз мине! Җенем сөйми минем сезне! — дип кычкырды.

Малай аптырап туктап калды, ул гаебенең нидә икәнен аңламый иде, Бекки бит үзе әйтте, озын тәнәфес буена китапның рәсемнәрен бергә карарбыз, диде, ә хәзер күз яшьләрен агызып китеп барды. Ни уйларга да белмичә, Альфред буш мәктәпкә таба юнәлде. Ул бик нык гарьләнә иде, аның кызга бик каты ачуы чыккан иде. Хикмәтнең нидә икәнен аңлау бер дә авыр түгел иде югыйсә: Том Сойерны үртәү өчен генә сөйләшкән икән бит кыз аның белән. Шулай икәнен ачыклагач, малай Томга тагын да ныграк нәфрәтләнде. Үзенә авырлык китермичә генә Томга берәр төрле этлек эшлисе килде. Шунда аның күзе Томның дәреслегенә төште. Бик тә уңайлы очрак иде бу! Ул дәреслекнең өйгә эш бирелгән битен ачты да өстенә кара түкте.

Нәкъ шул мәлдә Бекки тәрәзәдән эчкә карап тора иде һәм малайның нәрсә эшләп маташканын күреп алды, ләкин Альфредка бер сүз дә катмыйча тәрәзә буеннан үтеп китте. Ул өенә кайтырга чыкты. Аның Томны эзләп табып барын да сөйләп бирәсе килә иде. Том моның өчен аңа рәхмәт укыр, һәм шуннан соң алар дуслашып китәрләр кебек иде. Әмма ярты юлга җиткәч, Бекки бу уеннан кире кайтты. Томның пикник турында сөйләшкәндәге кыланышы исенә төште, һәм хурлануыннан кызның йөрәгенә яңадан ут капты. «Шул кирәк аңа!» дигән фикергә килде ул һәм Томны мәңге дошман күрергә карар кылды.

XX бүлек

Том, сөмсере коелып, өенә керде. Ләкин түткәенең беренче сүзләреннән үк бик тә вакытсыз кайткан булуын аңлады.

— Кирәгеңне бирәсе иде синең, Том!

— Нишләгән соң мин, түткәй?

— Сорап торган була бит әле! Ә мин, карт юләр, Сирини Һарперга йөгереп барган булам,— синең шул ахмак төшеңә ул да минем кебек ышаныр дип уйлаган булам! Тот капчыгыңны! Ә Джосы аңа синең ул кичне монда булып, безнең сөйләшкәннәрне тыңлап торганыңны бәйнә-бәйнә сөйләп биргән! Шушы кадәр дә оятсыз рәвештә алдаша ала торган малайдан ни генә чыгар икән! Нишләп син мине миссис Һарперга барганда туктатмадың — мин бит шыр ахмак булып калдым.

Әйе, хәзер инде барысы да башка төс алды. Моңа кадәр Томга иртәнге уйдырмасы үтә дә хәйләкәр мәзәк, чын-чынлап табыш кебек тоелган иде. Хәзер ул төссезләнеп, ямьсез һәм кыяфәтсез бер ялган булып калды. Том башын түбән иеп башта ни дип әйтергә дә белми басып торды, аннары:

— Алай эшләгәнемә мин бик үкенәм, түткәй... Мин ничектер уйлап җиткермәгәнмен...— диде.

— И җаным, син бервакытта да уйлап җиткермисең шул, үз рәхәтеңнән башка бер нәрсә турында да уйлый белмисең. Шул ерак утраудан төнлә йөзеп кайтып, төшләр уйлап чыгарып безнең кайгы-

быздан көлү синең башыңа килгән, ә менә безне кызганып, артык күз яшьләребезне агызудан коткару уеңа да килеп карамаган.

— Түткәй, мин моның бик яман этлек икәнен аңлыйм, әмма, мин сезгә ихлас күңелемнән әйтәм, һич тә алай булсын дип теләмәгән идем. Аннары... теге вакытта кичен... мин бөтенләй сездән көлер өчен кайтмаган идем...

— Ә соң нәрсәгә дип кайткан идең?

— Минем сезгә... без батып үлмәдек, борчылмагыз, дип әйтәсем килгән иде.

— Их, Том, Том, әгәр дә синең шундый изге ниятеңә ышана алсам, Аллаһы Тәгаләгә мин рәхмәт укыр идем, ләкин бит син алай булмаганны беләсең, һәм моны мин дә беләм.

— Чынлап әйтәм менә, түткәй, шулай булды. Баскан җиремдә чәчрәп китим менә!

— Их, Том, сафсата сатуның кирәге юк бит...

— Чынлап менә, түткәй! Хәсрәтләнмәсеннәр дип кайткан идем мин ул кичне.

— Бу сүзеңнең дөреслегенә ышану өчен мин ни генә бирмәс идем, моның өчен синең бөтен гөнаһларыңны ярлыкарга булыр иде, Том. Хәтта качып китүеңне дә, үзеңне шундый яман тотуыңны да! Тик менә ышанып булмый шул. Нишләп әйтмәдең соң син миңа?

— Беләсезме, түткәй, безне җирләү турында сүз башлагач, минем, әйләнеп кайтып, бик тә чиркәүгә керәп качасым килә башлады. Шуны ничек итеп сезгә әйтәсең инде? Һәм мин агач кайрысын алдым да кире кесәмә салып куйдым, беркемгә берни әйтмәскә булдым.

— Нинди кайры соң ул?

— Без пиратлыкка киттек, дип язылган кайры. Мин сезне үпкән чакта уянмавыгыз бик кызганыч, әлбәттә. Чынлап кызганыч менә.

Полли түткәйнең кырыс йөзендәге җыерчыклары язылып китте, күзләрендә ягымлы чаткылар елтырады.

— Чынлап үптеңме син мине, Том?

— Ничек инде чынлап булмасын!

— Чын әйтәсеңме, Том?

— Нишләп чын булмасын инде, түткәй!

— Нишләп үптең соң син мине, Том?

— Чөнки мин сезне бик яратам, сез йокы аралаш ыңгыраштыгыз, шуннан соң мин сезне бик жәлләдем.

Бусы дөрескә охшаган иде. Полли түткәй, тавышының калтырануын яшерә алмыйча, болай диде:

— Син мине тагын бер тапкыр үбеп ал да, Том, мәктәбеңә җыен, миңа комачаулама.

Том бүлмәдән чыгуга түткәсе чоланга ташланды, малайның качкынлыкка чыгып киткәндә кигән иске курткасын кулына алды һәм үз алдына сөйләнеп болай диде:

— Юк, кулым күтәрелми. Бичара бала, ул тагын алдагандыр инде мине, әмма бу — изге ялган, коткару бәрабәренә ялганлау, ул мине шундый сөендерде. Ходай Тәгаләгә ышанам инде... Юк, мин Ходайның ярлыкасына ышанам, ул бит аны күңеленең яхшылыгыннан уйлап чыгарган. Алдады дип уйлыйсым да килми хәтта. Юк, карамыйм әле.

Ул куртканы кире урынына куйды да бер генә минутка уйга калды. Ике тапкыр кулын курткага таба сузып, ике тапкыр кире алды. Өченче тапкырында, көчен җыеп, кулын куртка кесәсенә тыкты. «Бу бит изге ялган, аның өчен борчыласым юк әле»,— дип уйлады үзе. Берәр минуттан соң инде ул, күз яшьләрен коя-коя, агач кайрысына тырнап язылган сүзләрне укый иде:

— Хәзер инде мин аңа барысын да кичерәм, нигә шунда миллион гөнаһ эшләми!



XXI бүлек

Полли түткәй шундый да назлы иттерел үпте ки, Томның бөтен кайгылары таралды, күңелләре күтәрелеп, кәефе рәтләнгәндәй булды. Ул мәктәбенә чыгып китте һәм, өстәвенә, аның юлы да уңды: Болынлы тыкрыгының башында ук ул Беккины куып җитте. Томның үз-үзен тотышы һәрвакыт кәефенә бәйле була торган иде. Минут та икеләнеп тормыйча Том кызның янына йөгереп килде һәм:

— Мин бүген бик начар эшләдем, Бекки, шуның өчен бик үкенәм. Мин яңадан бервакытта да алай итмәм. Исән булсам, бервакытта да! Әйдә дуслашыйк, яме?

Бекки барган җиреннән туктап калды да аның күзенә җирәнеп карады:

— Мине тынычлыкта калдырсагыз, мин сезгә рәхмәт укыр идем, мистер Томас Сойер. Бүтән сезнең белән сөйләшмим мин.

Ул борынын чөйгән булды да юлына китеп барды. Том бу хәлгә шул кадәр каушап калды ки, хәтта: «Китсәң соң! Борын чөюен генә күр әле!» — дип тә әйтә алмады. Ул исенә килгәндә инде соң иде. Аның каравы, малайның үтә дә нык ачуы килгән иде. Их, әгәр шул кызый малай кеше булса, Том аны шәп итеп тукмап кына ташлар иде! Мәктәп ишегалдында ул яңадан да Бекки белән очрашты һәм аңа төрттмә сүзләр әйтеп китте. Кыз да җавапсыз калмады; шулай итеп алар тәмам дошманлаштылар. Ачуы кабарган Беккига инде дәрес бөтенләй башланмас та, буялган китабы өчен Томны җәзага да тарттмаслар кебек тоела иде. Моңа кадәр анарда Альфред Темпль-

ны фаш итү теләге булса, Томның ачы сүзләреннән соң ул теләк бөтенләй юкка чыкты. Бичара кыз үзенең алда ни күрәчәген белми иде шул әле.

Шушы мәктәпнең Доббинс дигән укытучысы, чәчләре агарганчы яшәсә дә, үзенең максатына ирешә алмаган: аның бик тә доктор буласы килгән, әмма ярлылык авыл мәктәбеннән ары китәргә ирек бирмәгән, һәр көнне ул, үзенең өстәл тартмасыннан ниндидер бер серле китап алып, укучылар дәрескә әзерләнгән арада шуны укып утыра иде. Китапны ул һәрвакыт бикләп тота. Мәктәптәге бөтен кызлар да, малайлар да шул китапка сыңар күз белән генә карап алырга бик кызыксалар да, һич чыкмый иде. Әлеге китап турында балаларның һәркайсы үзенчә фараз кыла иде, ләкин китапны тотып карарга бирәүгә дә туры килгәне булмады. Ишек төбендә үк торган кафедра яныннан үтеп барганда Бекки ачкычның йозак тишегендә калганын искәрде. Мондый очракны файдаланмый калу кызганыч иде, әлбәттә. Кыз тирә-ягына каранды — бирәү дә юк иде, һәм шул мизгелдә ул китапны эләктереп алды. Китапның беренче битендәге «фәлән профессор тарафыннан язылган «Анатомия» дигән сүзләр аңа берни дә аңлатмый иде, һәм кыз китапны актарырга тотынды. Аның беренче битенә матур итеп ясалган шәрә кеше рәсеме урнаштырылган. Шул мәлдә китап өстенә ниндидер күләгә төште — кызның җилкәсе аша китапка карап Том Сойер басып тора иде. Бекки ашыгып китапны япканда рәсемле битен уртасына кадәр ялгыш ертып җибәрде. Китапны өстәл тартмасына ташлап ачкычны борды да оятыннан һәм гарьлегеннән кычкырып җылап җибәрде.

— Том Сойер, сез гел әшәкелек кенә эшләп йөрисез! Кеше артыннан килеп карап торырга ничек оялмыйсыз?

— Сезнең анда нидер укып торганыгызны каян белим мин?

— Оят белергә кирәк. Том Сойер! Сез инде минем өстән әләкләшерсез, әлбәттә... Нишләргә инде миңа, нишләргә? Бөтен мәктәп алдында суктырырлар инде, ә минем андый хәлгә төшкәнем юк! — Ул дөп итеп аяк тибеп куйды.— Әләкләшегез сәнә, кабахәт! Аның каравы, мин дә бер нәрсә беләм: сез юньсез, әшәке малай! — Кыз тагын җылап җибәрде һәм бүлмәдән чыгып йөгерде.

Том, мондый һөҗүмнән аптырап, баскан җирендә катып калды. Аннары үз-үзенә сөйләнгәндәй итеп: — И тинтәк тә инде бу кызлар халкы! — диде.— Аны мәктәптә бервакытта да кыйнамаганнар, имеш. Кыйнасалар соң! Бөтен кызлар да, гомумән, шундый куркак, иркә була инде. Доббинс картка мин бу ахмак турында бер сүз дә әйтмәм анысы. Үчне башкача да алырга мөмкин, әләкләшүдән файда юк. Әмма кызый бит барыбер эләгәчәк. Китапны кем ертты, дип Доббинс барыбер сорый инде. Җавап бирүче юк. Һәрвакыттагыча ул һәркемнән берәм-берәм сорап чыгачак; Беккига килеп җитүгә аның гаепле икәнен карт шундук сизеп алачак: кызларның бөтен нәрсә дә йөзенә чыга бит. Кая түзсеннәр инде алар! Суктырырлар инде үзен... мөгаен... Эләкте инде Бекки, суктырырлар инде... үзен...

Бераз уйланып торганнан соң, Том фикерләрен болай дип йомгаклады:

— Булсын, шул кирәк аңа, мин бәлагә тарысам, ул сөенер генә иде. Менә хәзер үзе минем урында булып карасын әле.

Том ишегалдында уйнап йөрүче балалар төркеменә барып кушылды. Берничә минутлар үтүгә укытучы килеп җитте дә дәрес башланып китте. Том уку эшләре белән артык кызыксынмый иде. Ул минут саен кызлар утырган якка таба борылып карап-карап алды. Беккиның кыяфәте аның эчен пошыра иде. Бер дә жәллисе килми иде кызны, үзе исә кызганмыйча берничек тә булдыра алмады. Күңеленнән ул тантана итүгә охшаш нәрсә тоймады. Ә инде укытучы аның дәреслегендәге кара табын күреп алгач малайның бөтен игътибары үз кайгысына юнәлде. Бекки бер мәлгә үзенең күңелсез хәленнән айнып Томның маҗарасы белән кызыксынып китте. Дәреслеккә караны мин түкмәдем дип әйтсә дә, Томның бәладән арына алмаячагын белә иде ул, һәм шулай булып чыкты да: гаебен инкарь иткәне өчен малайга тагы да катырак җәза эләкте. Бекки сөенермен дип уйлаган һәм үзен шуңа ышандырырга да тырышкан иде, ләкин булдыра алмады. Эш кыйнауга барып җиткәч Беккиның, урыныннан торып, бөтен гаеп Альфред Темпльдә дип әйтәсе килде, ләкин ул үз-үзен көчләп тыныч кына утырырга мәҗбүр итте. «Том бит укы-

тучыга мине һичшиксез әләкләр, китапның рәсемен мин ертканны әйтер,— дип уйлады Бекки.— Үлсә дә яклап бер сүз әйтмим.»

Том, суктырганга әлләни исе дә китмичә, кире урынына барып утырды. Әллә уенга мавыгып үзем түктем микән караны, дип тә уйлады ул. Гаебен дә үз сүзеннән кайтмас өчен генә инкарь итте.

Тора-бара бер дәрес үтеп китте. Укытучы үзенең тәхетендә черем итеп утыра бирде. Дәрес ятлаучы укучылар гөжелдәвеннән һава үзе дә әллә нинди йокыны китерә торганга әйләнде. Менә мистер Доббинс киерелеп куйды, иснәп алды, өстәл тартмасын ачып, алыргамы-алмаскамы дигәндәй, икеләнеп кенә кулын китапка сузды. Укучылар иренеп кенә аңа таба карап утырдылар, арадан икесе генә аның һәр хәрәкәтен игътибар белән күзәтте. Мистер Доббинс берникадәр вакыт илтифатсыз гына китабын кулында әйләндергәләде, укырга әзерләнеп, креслосына җайлабрак утырды. Том шунда Беккига таба борылып карады. Кызның кыяфәте хәлдән тайган куяннықына охшаган иде. Том шундук аның белән ирләшкән булуын онытты. Тизрәк ярдәмгә! Секунд та көтмичә нидер эшләргә! Әмма нәкъ менә хәлнең бик ашыгыч булуы Томга ниндидер чара уйлап табарга комачаулый иде.

Ниһаять, аның башына менә дигән фикер килде: ул йөгереп барып китапны тартып ала да шундук ишектән чыгып ычкына! Ләкин Том бер генә мизгелгә икеләнеп калды, һәм уңайлы мәл кулдан ычкынды: укытучы инде калын китабын ачып та өлгергән иде. Их, шул мизгелне кире кайтарып булса!

«Инде соң, Беккига инде ярдәм итеп булмый!»

Тагын берәр минуттан укытучы укучыларын күздән кичерде. Алар барысы да шомраешып аска карап утыра иде. Укытучының карашында гаепсезләрне дә дер калтыратырдай ниндидер бер көч сизелә иде. Тынлык урнашты; ул шулкадәр озакка сузылган сыман тоелды ки, хәтта унга кадәр санап чыгарга мөмкин иде. Укытучының ачуы кабарганнан-кабара барды. Ниһаять ул:

— Кем ертты китапны? — дип сорады.

Җавап бирүче булмады. Бүлмәдә тирән тынлык урнашты. Чебен очканны да ишетергә мөмкин булыр иде, мөгаен. Тынлык дәвам

итте, гаепле кешене эзләп, укытучы берәм-берәм балаларның йөзенә текәлде.

— Бенҗамин Роджерс, сез ерттыгызмы бу китапны?

Юк, ул түгел. Тагын тынлык.

— Сезнең эшме бу, Джозеф Һарпер?

Ул да түгел. Томның куркуы торган саен көчәя барды. Бу сорау-җаваплар аның өчен озакка сузылган җәза иде.

Укытучы текәлеп малайлар рәтенә карады, бераз уйлап торды да кызларга мөрәҗәгать итте:

— Эмми Лоуренс?

Кыз башын гына чайкады.

— Грэси Миллер?

Шул ук хәл.

— Сьюзен Һарпер, сезнең эшме?

Юк, ул да түгел. Хәзер Ребекка Тэтчерга җитте чират. Килеп туган хәлдән берничек тә чыгу чарасын күрмичә, Том бөтен тәне белән калтырана башлады.

— Ребекка Тэтчер (кызның йөзе куркудан ап-ак булды), сез ерттыгызмы? Юк, сез минем күземә карагыз (кыз ялварып кулларын кушырды). Сез ерттыгызмы бу китапны?

Томның кинәт йөзе яктырып киткәндәй булды. Ул сикереп торды да кычкырып җибәрде:

— Мин ерттым аны! — диде.

Акылга сыймаслык ахмаклык эшләнүгә шаккатып, бөтен класс авызын ачып калды. Том, таркалган уйларын җыярга тырышып, берәр минут басып торды һәм җәзаны кабул итәр өчен алга таба атлады. Бичара Беккиның карашында чагылган илтифат, чиксез сөю, соклану бәрабәренә ул тагын шундый ун җәза алырга әзер иде. Үзенең киң күңеллелеге белән рухланган Том мистер Доббинсның моңарчы берәүне дә кыйнамаганча каты итеп кыйнавына бернинди тавыш та чыгармыйча чыдады һәм дәрестән соң ике сәгатькә мәктәптә калырга дигән өстәмә җәзаны да эһ тә димичә кабул итте. Тоткынлыктан чыкканда капка төбендә үзен кем көтәсен белә иде ул, шуңа күрә ике сәгатьлек әсирлекне дә артык авырга санамады.

Ул кичне йокларга ятканда Том ничек итеп Альфред Темпльдән үч алачагын бик җентекләп уйлады. Бекки үкенүеннән, оятыннан җылый-җылый, хыянәтен дә яшермичә, Томга барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Мәгәр үч алу теләге тиздән матуррак хыялларга урын бирде һәм, ниһаять, Том йокыга талды, ләкин ул хәтта йокы аралаш та Беккиның шаккатып:

— Син шундый да яхшы күңелле икәнсең, Том! — дигән сүзләрен ишеткәндәй булды.



XXII бүлек

Каникул көннәре җитеп килә иде. Болай да бик таләпчән укытучы хәзер тагын да катырак һәм тагын да таләпчәнрәк булырга тырышты: имтихан вакытында аның укучылары үзләрен күрсәтергә тиеш, дип исәпли иде ул. Сыек чыбык та, линейка да, бигрәк тә кечерәк классларда, бер дә эшсез ятмады. Иң өлкән укучылар белән унсигез-егерме яшьлек туташларны гына кыйнамыйлар иде. Мистер Доббинс исә бик тә авырттырып кыйный иде, чөнки, парик астындагы башы шәп-шәрә пеләш булуына карамастан, аңа әле картаерга ерак һәм аның мускуллары көчле иде. Әлеге бөек көн ныграк якынлашкан саен аңардагы җәза бирүгә һәвәслек өскә калкып чыга башлады: кечкенә генә гаеп өчен дә җәза бирүдән ул явызларча тәм таба иде кебек. Шуның аркасында иң кечкенә малайлар да көннәр буена куркынып, калтыранышып утыралар да, төннәрендә исә ничегрәк итеп укытучыдан үч алырга икән, дип план коралар иде. Укытучыга этлек эшләргә мөмкин булган һәр очракны алар файдаланмыйча калмыйлар иде. Әмма көчләр тигез булмау сәбәпле, укытучы һәрвакыт өстен чыга иде. Балалар җиңеп чыккан һәр очрак артыннан шәфкатьсез җәбер килә, һәм малайлар сугыш кырында зур югалтуларга дучар булалар. Ниһаять алар, үзара берләшеп, зур уңышлар вәгъдә итә торган план кордылар. Алар, вывескалар яза торган рәссамның өйрәнчек малаен үз арасына алып, аңа үзләренең планнарын сөйләп бирделәр һәм ярдәм итүен үтенделәр. Бу үтенечтән малайның куанычы эченә сыймады: чөнки әлеге укытучы

тамагын аларда туйдыра икән һәм инде нык кына малайның тең-кәсенә тияргә өлгергән. Укытучының хатыны берничә көннән каядыр авылга, үзенең танышларына кунакка китәргә җыена икән. Димәк, үч алу эшенә берни дә комачау итәргә тиеш түгел. Шундый тантаналы көннәр алдыннан укытучының мул гына итеп «кәгә» торган гадәте бар икән, һәм өйрәнчек малай, укытучы исереп кресло-сында йокыга китүгә «барысын да рәтләгәннән соң», аны уятып, мәктәпкә озатырга ризалашты.

Ниһаять, бу гаҗәеп вакыйга көне килеп җитте. Сәгать кичке сигезгә мәктәп бинасы як-якты итеп яктыртылган, агач ботакларыннан һәм чәчәкләрдән үреп ясалган бәйләмнәр һәм гирляндалар белән бизәлгән иде. Укытучы, тәхеттә утырган кебек, калку урынга куелган зур креслосында, аның артына исә кара такта эленгән. Укытучының шактый мул итеп «салган» булуы сизелә. Ике яклап өч рәт итеп тезелгән һәм каршыда алты рәт итеп куелган эскәмияләргә шәһәр сановниклары һәм укучыларның ата-аналары утырышкан. Укытучыдан сул якта, тамашачылар артында, киң эстрада кебек нәрсә калкып тора, анда имтихан тотарга тиешле укучылар утырышкан: чиста итеп юынып, пөхтә итеп киенгән малайлар үзләрен арканлаган кебек хис итәләр һәм үтә дә газапланып энә өстендә утырган кебек утыралар иде. Рәт-рәт булып килбәтсез үсмерләр тезелешкән; ап-ак батист һәм кисеядән тегелгән нәфис киемнәр кигән кыз балалар һәм туташлар утыра; шәрә беләкләренә әбиләренең борынгы беләзекләрен кигән, чәчләренә алды-зәңгәрле бантлар таккан кызлар шактый уңайсызлана иде. Калган урыннарга имтиханга катнашы булмаган укучылар утырган.

Имтиханнар башланып китте. Кечкенә генә бер малай алга таба атлады да куркынган сыман итеп: «Кадерле дуслар, сезнең берегез дә каршыгызга нәп-нәни бер кеше чыгып шигырь укыр дип көтмәгәндер»,— дип бытылдап алды. Ул ватык машинаны хәтерләткән сыман ниндидер тартышулы хәрәкәтләр ясады. Шулай да бала әйтәсе сүзен ахырына кадәр исән-сау әйтеп бирә алды һәм алкышлар астында мәйданнан чыгып китте. Бәләкәй бер кыз бала тартынып кына: «Мэриның бәтие бар»,— дип, көчкә-көчкә леперддәп алды,

мескен генә итеп реверанс ясады да өлешенә тигән алкышлардан тартынып һәм түбәсе күккә тиеп урынына барып утырды.

Эстрадага үз-үзенә үтә дә нык ышанган Том Сойер килеп чыкты. Ул кулларын болгый-болгый, ярсый-ярсый дәртләнеп: «Бирегез миңа ирек яисә үлем бирегез!» дигән мәгълүм тираданы сөйли башлаган иде, уртасына җиткәч кенә тотлыгып туктап калды. Ул каушады, аның тез буыннары калтырады, тамагына нидер килеп тыгылды, үзе телен йотып җибәргәндәй булды. Дөрес, тыңлаучылар аның хәлен аңладылар, ләкин аларның эндәшмәүләре тагын да читенрәк иде. Укытучы күңелсез итеп чыраен сытты, димәк, Томның эше бөтенләй хөрти иде. Ул яңадан да укуын дәвам итәргә тырышып карады, булдыра алмады һәм, хурлыкка калып, урынына барып утырды. Берән-сәрән генә кул чапкан тавышлар ишетелде, ләкин алар шундук тынды да.

Аннары «Ялкынланып янган палубада бер малай басып тора», шулай ук «Ассириялеләр килә...» дигән һәм шуныңише башка төрле, декламаторлар ярата торган җәүһәрләр тезелеп китте. Башка ярышларның чираты җитте: алары кычкырып уку һәм дөрес язу буенча иде. Аннары яшь туташлар үзләре язган әсәрләрен укырга тиеш булдылар. Бусы инде программаның кадагы иде. Туташлар берблер артлы эстрада читенә килеп бастылар, матур-матур тасмалар белән бәйләп куелган кулъязмаларын чишеп, тамак кыргалап, сәнгатьле итеп укый башладылар. Әсәрләрнең темасы — тәре походларыннан башлап, шул ук борынгыдан килә торган — әниләре, әбиләре, әниләренең әбиләре язган темалар. Алар арасында «Дуслык», «Үткәннәр турында хатирәләр», «Диннең тарихтагы роле», «Хыял патшалыгы», «Мәгърифәт безгә нәрсә бирә?», «Дәүләтләрнең сәяси төзелеш формалары», «Уйчанлык», «Ата-анага мәхәббәт», «Эчкерсез хыяллар» дигән темалар бар.

Бу язмаларның төп үзенчәлеге булып авторларның исен китәргән меланхолия тора иде, аннан соң — һәртөрле матур сүзләр җыелмасы, аннары — күңелгә ошаган берәр төрле матуррак әйтемне тешкә сыланырлык иткәнче һәм бөтен мәгънәсен тәмам югалтканчы куллану; бигрәк тә күңелсез булып күзгә бәрелгәне — һәр ин-

шаның ахырында көтек коерыгын болган торучы эчпошыргыч мораль. Темасы нинди генә булмасын, автор үзенең әсәренә игелекле бөек акыл хакына дип нинди дә булса файдалы һәм гыйбрәтле нәрсә кертеп калдырырга тырышкан. Гәрчә бу вәгазьнең фальшь булуы күзне ертып торса да, аны берничек тә юкка чыгара алмыйсың; дөнья беткәнчә торып безнең мәктәпләрдә ул бетмәячәк. Укучы кызлар үзләренең иншаларын мораль уку белән тәмамларга мәҗбүр булмаган мәктәп безнең илдә юктыр да ул. Укучы никадәр җилбәзәк һәм имансыз булса, аның вәгазе шулкадәр озынрак һәм диндаррак булыр. Ләкин бу турыда җитеп торсын. Ачы хакыйкать бирәүгә дә ошамый. Әйдәгез, имтиханнарга әйләнеп кайтыйк. Укылган беренче иншаның башына «Шушы буламы тормыш?» дип куелган иде. Шушы иншаның бер генә өзеген укып чыгарга бәлки укучымның сабырлыгы җитәр?

«Яшь аң тормышның тапталган сукмагында сөенечле дулкынлану белән бәйрәмне озак көтеп алдан ук ләззәтләнеп тора! Хыял уен-көлке күренешләрен ал буяулар белән ачык итеп буяп ташлый. Хыялында иркәләнгән модага баш июче үзен инде бәйрәмчә төркем эчендә, игътибар үзәгендә итеп күрә. Аның ак киемгә киенгән зифа сыны исерткеч бию өермәсендә бөтерелә; аның күзләре барысыныкыннан да яктырак яна; аның аяклары бу күңелле төркемдә барысыныкыннан да җиңелрәк очына.

Мондый ләззәтләндергеч хыялда вакыт тиз үтә һәм, аның бәхетле һәм татлы хыялындагы якты оҗмахка керү сәгате суга. Мондагы һәрнәрсә аның сокландыргыч күзләренә нинди сихри-гүзәл булып күренә! Һәр яңа күренеш аңа тагын да сокландыргычрак булып тоела. Әмма вакыт үтү белән бу ялтыравыклы кыяфәт астына ул юк-бар нәрсә генә яшеренгән икәнен ачыклый; кайчандыр күңелен әсир иткән ялагайлану хәзер инде аны ярсыта гына; танса заллары аның өчен инде сокландыру көчен югалта; чөнки ул затлы токым вәкилләрен канәгатьләндерә торган рәхәтлекләр инде аның күңел омтылышларын канәгатьләндерә алмаячагына инанды!»

Һәм башкалар, вә башкалар. Уку вакытында әледән-әле хуплаган тавышлар ишетелә торды, кешеләр «Нинди матур!», «Нинди оста

телле!», «Хак бит!» дип пышылдаштылар, бу эчпошыргыч вәгазь тәмамлануга тыңлаучылар рухланып кул чабарга тотындылар.

Аннары зифа сынлы меланхолик туташ чыгыш ясады, ул дару эчүдән һәм ашказаны эшләмәүдән килеп чыга торган сәер төссезлеге белән аерыла. Бу кыз «поэма» укыды. Ике строфасын китерү дә җитәдер, мөгаен.

МИССУРИ КЫЗЫНЫҢ АЛАБАМА
БЕЛӘН ХУШЛАШУЫ

Алабама, хуш! Мин сине яраттым,
Хәзер исә сине ташлап китәм!
Бар йөрәгем белән сызлап ачы яшьләр коям...
Һәм мәңгегә сине калдырам.

Алабама, сиңа сөю һәм сәлам юллыйм.
Синең үзәннәреңне мин юксынам.
Мәңгегә йөрәгем дә, tete[1] дә суынсын,
Әгәр дә сине мин сөйми башласам.

«Tete» дигән сүзне мондагы кешеләрнең бик азы гына белә иде, шулай да шигырь ошады.

Аннан соң тамашачылар алдына каратут йөзле, кара чәчле һәм чем-кара күзле туташ чыгып басты, озак кына итеп пауза тотты, йөзенә фаҗигале кыяфәт чыгарды да салмак һәм тантаналы итеп укый башлады:

ХЫЯЛ

«Төн давыллы һәм караңгы иде. Күк тәхете тирәсендә бер генә йолдыз да җемелдәмәде, әмма тонык итеп күк күкрәгән тавыш һаваны өзлексез тетрәтеп торды, шул ук вакытта, мәшһүр Франклин тарафыннан аның мәрхәмәтсезлеген буйсындыруны санга сукмагандай, дәһшәтле яшен күкләрнең болытлы пулатларында ачулы елтырады! Хәтта ярсулы җилләр дә, үзләренең серле сыеныр урыннарын бердәм ташлап чыгып, әйтерсең лә бу давыллы төн тагын

[1] *Tete* — баш (фр.).

да куркынычрак булып күренсен дигәндәй, җир өстендә дуамаллана башладылар.

Бу караңгылык һәм сагыш вакытында минем йөрәгем кешеләрчә теләктәшлек юксынды, әмма шуның урынына —

Дустым минем, хыялым минем — иң яхшы киңәшчем минем,
Кайгыда һәм шатлыкта — үземнең яныма килде.

Ул яшь романтикларның нурлы оҗмах турындагы хыялында барлыкка килгән чибәрлек алиһәсе кебек якынлашты, үзенең чиктән тыш нәфислегеннән башка берни белән дә бизәлмәгән иде. Аның аяк басуы шундый да йомшак, хәтта ул үзе турында бернинди аваз белән хәбәр бирмәгән һәм, әгәр дә аның якынаюыннан миңа күчкән сихри тетрәнү булмаса, ул, башка тыйнак чибәрләр кебек күренмичә, сиздермичә генә үтеп китәр иде. Аның кыяфәтендә, декабрьнең ап-ак киеменә җәелгән бозлы күз яшедәй, сәер сагыш җәелгән!»

Шушы мәхшәр ун кулъязма бит тәшкил итә һәм гаҗәп кырыс вәгазь белән тәмамлана иде, вәгазь исә, пресвитериан чиркәвенә карамаган бөтен кеше һичшиксез һәлак булачак, дип кисәтә иде. Менә шушы «әсәргә» беренче бүләкне бирделәр. Бу инша кичәдә укылганнар арасында иң яхшысы дип табылды. Бүләк тапшырганда шәһәр башлыгы кайнар нотык тотты; сүзенә караганда, аның бервакытта да мондый оста тел белән язылган нәрсә ишеткәне булмаган, һәм, аның фикеренчә, мондый инша белән хәтта Дэниель Уэбстер[1] үзе дә горурланган булыр иде.

Сүз уңаеннан шуны да искәртик, «гүзәл» дигән сүз өзлексез кабатланып торган иншалар саны, ә кешелек тәҗрибәсе дигән сүзне «тормыш сабаклары» дип атаган иншалар саны һәрвакыттагыдан бер дә ким түгел иде.

Ниһаять, салмыштан тәмам изрәгән укытучы, креслосын этеп куеп, тамашачыга аркасы белән борылды да җәгърәфиядән булачак имтихан өчен тактага Америка картасын сыза башлады.

---

[1] *Дэниель Уэбстер* (1782—1852) — АКШның дәүләт һәм сәяси эшлеклесе, мәшһүр оратор.

Ләкин аның кулы калтырана иде, эшен ул юньләп башкара алмады, һәм залда көлгән тавышлар ишетелде. Укытучы үзеннән көлгәннәрен аңлап алды да, эшен тәмамларга теләмәкче булды. Ул сызымын тактадан сөртеп алды, яңадан сызды, ләкин аны бары тик бозды гына, хихылдаган тавышлар тагын да көчәя төште. Укытучы башы белән эшенә чумды һәм, күрәсең, көлүләргә игътибар итмәскә булды, барысының да үзенә карап торганын ул сизә иде; аңа эше рәтләнә барган сыман тоелды, хәлбуки, көлү һаман басылмады, хәтта көчәя генә барды. Бу хәл юкка гына түгел иде. Укытучының башы турына чормага менә торган тишек туры килә иде, кинәт шушы тишектә бауга бәйләнгән мәче күренде; мияуламасын өчен аның башын чүпрәккә ураганнар иде; тыпырчына-тыпырчына аска таба төшә бирәп, мәче тырнаклары белән әле бауны, әле һаваны элэктергәндәй итте. Көлгән тавышлар көчәйгәннән-көчәйде — песи инде эш белән мавыккан укытучының башы яныннан нибары биш-алты дюймда[1] гына иде, - менә ул төшеп җитте дә тырнакларын укытучының паригына батырды һәм, күз ачып йомганчы парикны тырнакларына эләктереп, яңадан чормага күтәрелде. Укытучының пеләш башы лампа яктысында күз камаштыргыч булып ялтырап калды — рәссамның өйрәнчеге башны алтынсу төскә буяган иде.

Шуның белән кичә тәмам булды. Укучылар үзләренең укытучыларыннан үч алдылар. Аннары каникул көннәре башланып китте.

[1] *Дюйм* — үлчәү берәмлеге; 2, 54 см.



XXIII бүлек

Том яңа җәмгыятькә — «Аек башлы яшьләр» җәмгыятенә әгъза булып керде, чөнки бу җәмгыять әгъзаларына бик матур мундир бирәләр иде. Ул әлеге җәмгыятьтә торган чорда тәмәкене тартмаска да, чәйнәмәскә дә, сүгенмәскә дә сүз бирде, һәм шундук өряңа ачыш ясады: берәр нәрсәне эшләмәскә дип ант итүең була, шундук аны эшлисең килә башлый. Тиздән Томның үтерен тартасы һәм сүгенәсе килә башлады. Шулхәтле килә башлады ки, халык алдында алсу шарфы белән мактана алу ихтималы гына аны «Аек башлы яшьләр» җәмгыятен ташлап чыгудан тыеп торды.

Дүртенче июль көне якынлашып килә иде; әмма тора-бара Том бу бәйрәмне көтми башлады, богауларын ике көн тагып йөрергә дә өлгермәстән, ул өметен өзде, аның бөтен ышанычы үлем түшәгендә яткан Фрэзер дигән карт мировой судьяда иде; шундый дәрәҗәле урын биләгәч, аны зурлап җирләргә тиешләр иде. Өч көнләп Том судья Фрэзерның сәламәтлеге турында белешеп һәм бик тырышып аның турындагы бөтен имеш-мимеш сүзләрне җыеп торды. Кайвакыт судья шулхәтле өметләндерә иде, хәтта Томның бөтен «медальләрен» таккан хәлдә көзге алдына басып үзенең кыяфәтенә сокланып торган чаклары булды. Әмма судьяга ышаныч аз иде, аның хәле йә бик җиңеләеп китә, йә бөтенләй авырая иде. Ниһаять, аның хәле шактый ук җиңеләйгән икән дигән сүз таралды, аннары хәтта терелә икән дип тә сөйләделәр. Томны мыскыл иткән кебек булды

инде бу, һәм аның бик тә ачуы килде. Ул шундук җәмгыятьне ташлап чыкты. Шуннан ни булды, дисезме? Төнлә судьяның хәле авырайган да, ул үлеп тә киткән. Моннан соң берәүгә дә ышану мөмкин түгел, диган карарга килде Том.

Судьяны зурлап җирләделәр. «Аек башлы яшьләр» судьяны соңгы юлга озату җыенында менә диган итеп катнаштылар, аларның элекке иптәше исә көнләшүеннән шартлый язды. Аның каравы Томның хәзер дүрт ягы кыйбла иде — монысы да бит аның гел юк эше түгел! Хәзер ул туйганчы тәмәкесен дә тарта, сүгенә дә ала. Әмма, гаҗәпкә каршы, боларның берсен дә эшлисе килмәде аның. Нәкъ менә бернинди тыю булмаганга күрә аның бөтен теләге юкка чыкты!

Озакламый Том менә нәрсәгә гаҗәпкә калды: көтеп алган каникулыннан ул тәмам туйды, җитмәсә вакыт дигәне дә бик акрын үтте.

Шуннан соң ул көндәлек язарга тотынды, ләкин өч көн буена бернинди маҗара да булмады, һәм Томга әлеге шөгылен ташларга туры килде.

Калага негр җырларын һәм негр биюләрен башкара торган труппа килде, ул бөтен кешене шаккатырды. Том белән Джо Һарпер да, үзләренең малайлардан торган оркестрларын җыеп, ике көн буена шуның белән мәш килеп йөрделәр. Данлыклы дүртенче июль көне бик үк уңышлы үтмәде, чөнки чиләкләп яңгыр койды, процессия булмады, дөньяның иң бөек кешесе (һәрхәлдә Том шулай дип уйлый иде) дип исәпләнгән Кушма Штатларының чын сенаторы Бентон әфәндедән аның күңеле биздe: ни өчен дигәндә, ул буе егерме биш футлы алып батыр булмыйча, уртача гына буйлы бер кеше булып чыкты.

Калага цирк килде. Шуннан күреп малайлар, тузган келәмнәрдән палатка ясап, өч көн буена циркны уйнадылар. Кергән өчен билет урынына малайлардан — өчәр, кызлардан икешәр булавка алдылар. Аннары ул циркттан да туйдылар.

Гипнозлаучы белән френолог килгән иде, алар киткәч тагын да ямансурак булып калды.

Кайчакларда бала-чага өчен кичке уеннар оештырылды; ләкин ул уеннар шулхәтле сирәк була, чираттагы уенны көткән вакытлар тагын да моңсурак тоела иде.

Бекки Тэтчер, үзенең ата-аналары белән бергә, туган шәһәрләре Константинопольгә китте; ул киткәч Том өчен дөньяда бернинди ямь калмады.

Кеше үтерү турындагы дәһшәтле серне саклау Том өчен җиңә алмаслык газап булды. Авыртуы басылмый да, төзәлми дә торган яман шеш кебек җәфалады ул сер.

Аннары Том кызамык белән чирләп китте.

Ике атна буена малай бөтен дөньядан, андагы бөтен хәлләрдән аерылып урын өстендә ятты. Аның чире бик каты булды, ул берни белән дә кызыксынмады. Ниһаять, аякка басып, алпан-тилпән килеп кала буйлап йөрергә чыккач, малай бөтен җирдә начарга таба үзгәреш булуын күрде. Калада динне торгызу эше яңадан башланган, һәм бөтен кеше — олысы, кечесе «дини» мәсьәләләр хакында гәп куертырга тотынган. Том, берәр генә булса да гөнаһлы бәндәне очратырга тырышып, каланың бер очыннан икенче очына кадәр үтсә дә, теләгенә ирешә алмады. Ул Джо Һарпер янына китте, ләкин Джо инҗил укып утыра иде, һәм кәефе кырылган Том бу моңсу тамаша яныннан китәргә ашыкты. Ул Бен Роджерсны эзләргә тотынды, Бен исә ярлылар янына йөри башлаган: ул аларга кәрзине белән дини брошюралар ташый икән. Ниһаять, Джим Һоллинсны эзләп тапкач, Томны ул, кызамык чирен ходай бөтен гөнаһларыңнан тәүбә иттерер өчен җибәргән, дип ышандырырга тырышты. Очраган бер малай Томның күңел түрендә яткан авырлыкка тагын берәр тонна авырлык өстәде. Тәмам рухы төшкән Том, юаныч эзләп, Һаклберри Финны тапкан иде, анысы да тәүрат сүзләре белән каршылады. Монысын инде Томның йөрәге бөтенләй дә күтәрә алмады, ул көчкә генә сөйрәлеп өенә кайтып җитте дә караватына килеп егылды; үзен бөтен каласында мәңге җәһәннәмдә янырга дучар ителгән бердәнбер гөнаһлы адәм дип хис итте.

Төнлә исә коточкыч итеп күкләр күкрәтеп яшенле яңгыр ява башлады.

Том башы-аягы белән юрган астына кереп, коты алынган хәлдә һәлакәтен көтте: бу мәхшәрнең үзе аркасында килеп чыгуына аның тамчы да шиге юк иде; гөнаһлары аркасында ходайның сабырлыгы җуелганына һәм хәзер аңа бернинди дә аяу булмаячагына ул чын күңеленнән инанган иде. Әгәр берәрсе кечкенә генә бөҗәккә каршы туптан ата башласа, моны Том көчне һәм снарядларны юкка әрәм итү дип исәпләр иде, әмма ходайның үзе кебек кечкенә генә бөҗәкне юк итәр өчен шундый кыйммәтле яшенле яңгыр оештыруын Том бер дә сәер эшкә санамады.

Әкренләп яшенле яңгыр басыла барды һәм, үзенең төп бурычын үти алмыйча, бөтенләй үк туктады. Томның башына, беренче булып, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтеп төзәлергә кирәк дигән уй килде. Икенче уй — бераз сабыр итәргә кирәк, дигән уй иде: әллә бәлки яңадан яшенле яңгыр бөтенләй булмас та.

Икенче көнне докторны яңадан чакырырга туры килде: Томның авыруы тагын көчәеп китте. Өч атна буена кузгалмыйча урын өстендә яту Томга мәңгелек булып тоелды. Ниһаять, исән калып өйдән чыга алуына да бөтенләй куанмады, чөнки хәзер үзенең япаялгыз икәнен — бер дусты да, иптәше дә калмаганын яхшы белә иде. Ул ялкау гына атлап урам буйлап китте дә бер төркем малайлар белән йөргән Джим Һоллинсны күрде. Алар кошчыкны һәлак иткән өчен бер мәчене хөкем итәләр иде. Мәченең корбаны да шунда ук аунап ята. Аннан арырак, аулак кына бер урында, Джо Һарпер белән Һаклберри Финн урлап алган кавыннарын ашап утыралар иде.

Бичаралар! Алар да, Том кебек үк, элекке чирләре белән чирли башлаганнар иде.





XXIV бүлек

Йокымсырап яткан дөнья ниһаять җир тетрәгәндәгедәй көчле итеп кузгалып куйды: кеше үтерүчене хөкемгә тарту көне билгеләнде. Калада гел шул турыда гына сөйләштеләр. Бу сөйләшүләрдән әсәрләнгән Том үзенә керер тишек тапмады.

Үтерүчегә кагылышлы һәр ишарә аның йөрәгенә килеп кадалды. Бу сөйләшүләр махсус, аны сынар өчен алып барыла сыман тоелды Томга. Дөрес, үтерү хакында Том беләдер дип кешеләр каян шикләнсеннәр икән, дип тә уйлый иде малай, шулай да, әлеге сөйләшүләрне ишетеп шомланмый да кала алмый һәм бизгәк тоткандагы сыман әледән-әле калтыранып куя иде. Икәүдән-икәү генә сөйләшер өчен дип Һакны бер аулак урынга чакырды Том. Шул хәлләрне белгән иптәше белән иркенләп бер сөйләшсә, ичмасам эчләре бушап калыр кебек иде. Шунын өстенә, Һакнын бу турыда берәүгә дә әйтмәвенә кабат ышанасы килә иде аның.

— Һак, син берәрсенә сөйләмәдеңме ул турыда?

— Нәрсә турында?

— Беләсең бит инде нәрсә турында икәнен...

— Нишләп сөйлим ди.

— Бер сүз дә сөйләмәдеңме?

— Ипидер, бер сүз дә сөйләмәдем. Нишләп төпченәсең әле син бу турыда?

— Болай гына, курыкканга күрә.

— Юк, Том Сойер, әгәр без моны тишсәк, ике көн дә яши алмыйбыз. Үзең дә беләсең бит.

Том тынычланып киткәндәй булды. Бераз эндәшми торганнан соң:

— Һак, сине бит бу турыда берәү дә тел яздыра алмас? — дип сорады.

— Минеме? Юк инде! Әгәр дә ул каһәр төшкән метис мине песи баласы урынына суга батырып үтерсен дисәм генә инде. Ә болай — ю-у-ук!

— Алай булса ярый. Телебезне тыя алсак, безгә берәү дә тимәс. Шулай да, әйдә тагын бер кат антыбызны ныгытыйк. Алай яхшырак булыр.

— Ярый алайса.

Алар тантаналы һәм коточкыч куркыныч итеп яңадан ант эчтеләр.

— Тагын ниләр сөйлиләр соң, Һак? Мин шулкадәр күп нәрсәләр ишетеп бетердем...

— Ни сөйләсеннәр? Мэфф Поттер үтергән диләр, башка сүз сөйләмиләр. Мин гел кара тиргә батам — кая булса да кереп качасым килә башлый.

— Шул-шул менә. Мин дә шулай. Эше харап бит инде ул бичараның. Кайчак син аны җәлләмисеңме?

— Җәлләмәгән кая! Юньле кеше дә түгел инде ул үзе югыйсә. Ә бит аның берәүгә дә этлек эшләгәне юк. Балык тотып акча юнәтә дә, салмыш булып тик йөри. Берәр эш эшләү турында уйламый инде уйлавын... Алайга китсә, барыбыз да шундый инде без. Барыбыз булмаса да, күбебез: поплар, мәсәлән, һәм башкалар. Ә шулай да, кешелекле дә сыман бит ул үзе: бер тапкыр барлы-юклы балыгының яртысын миңа биргән иде. Ничә тапкырлар мине яклады, бәладән коткарып калды.

— Минем дә очыргычларымны рәтләп, кармакларымны җебенә тагып биргәне бар аның. Аңа төрмәдән качарга ярдәм итә алсак, бик шәп булыр иде дә бит!

— Ничек ярдәм итәсең ди инде! Аннан ни файда: ул качар, ә аны барыбер тотып алырлар!

— Әйе шул, барыбер тотарлар. Тик менә кешеләрнең аны сүгүләрен тыңлап тору бик читен, бер гаепсезгә бит!

— Миңа да читен шул, Том. Беләсеңме... бөтен штатында иң мәрхәмәтсез явыз дип сөйлиләр аны хәзер. Нишләп монарчы асып куймаганнар икән, дип тә әйтәләр.

— Әйе, гел шуны гына сөйлиләр инде. Мин әле болай дип тә ишеткән идем: әгәр дә Мэффны төрмәдән чыгарсалар, аны Линч законы буенча суктырачаклар икән.

Малайлар әле тагын бик озаклап Поттер турында сөйләштеләр, ләкин аңа карап кына аларның хәле җиңеләймәде. Караңгы төшә башлагач малайлар бәләкәй генә ялгыз төрмә тирәсендә буталып йөри башладылар, алар, күрәсең, нинди дә булса уңайлы бер очрак барысын да рәткә салырга ярдәм итәр дип өметләнгәннәрдер. Әмма андый хәл булмады; берниндн фәрештәне дә, берниндн сихерчене дә бәхетсез тоткын кызыксындырмый иде, күрәсең.

Алар бер генә нәрсә эшли алалар иде, һәм инде алар аны берничә тапкыр эшләделәр дә: рәшәткә аша Поттерга беркадәр тәмәке белән берничә бөртек шырпы бирә алдылар. Ул астагы катта утыра, һәм аны берәү дә каравылламый иде.

Мондый бүләкләр өчен тоткынның рәхмәт укуы аларның элек тә намусына тия иде. Ә бу юлы исә аларның күңелен ул рәхмәтләр тагын да ныграк чәнчеде.

Поттер:

— Игелегегез өчен рәхмәт инде сезгә, балалар. Бөтен каласында мине сездән башка берәү дә кызганмый, һәм минем моны онытасым да юк,— дип сөйли башлагач, алар үзләрен иң җирәнгеч куркаклар һәм сатлык җаннар итеп хис иттеләр.— Мин еш кына үземә болай дим: бөтен малайларга да мин очырткычларын һәм башка шуныңише уенчыкларын рәтләп бирә торган идем, балыкның кайда шәбрәк эләккәнен дә күрсәтә торган идем, барысы белән дус идем кебек, ләкин барысы да карт Мэфф бәлагә таргач аннан йөз чөерделәр; ә менә Том исә бичара картны ташламады, Һак та ташламады. Юк, алар картны онытмадылар... Ул да онытмас аларны... Әйе, балакайлар, коточкыч нәрсә эшләдем мин: исерек булганмын, акылымда булмаганмын инде... башкача ничек аңлатасың инде моны; хәзер шуның өчен асып куярлар инде мине, шулай кирәктер дә инде ул. Шулай

әйбәттер дә ул, ягъни, мин шулай дип өметләнәм. Ярар ла инде, нәрсә бу турыда сөйләп торырга! Ник сезнең кәефегезне кырырга — без сезнең белән дус идек бит! Бер генә нәрсә турында әйтәсем килә сезгә: рәшәткә эченә эләгәсегез килмәсә, эчмәгез шул каһәр суккан аракыны! Әзрәк арырак китеп басыгыз әле — менә шулай; мондый бәлагә эләккән кешегә дусларының йөзен күрүдән дә зуррак юаныч юктыр; сездән башка беркем килми бит минем янга. Дусларымның мәрхәмәтле йөзе... дусларымның мәрхәмәтле йөзе... Берегез икенчегезнең аркасына менеп басыгыз әле, минем буем җитәрлек булсын. Менә шулай. Хәзер минем кулымны кысыгыз — сезнең кулларыгыз рәшәткә арасына сыя, минем кулым артык зур шул, сыймый. Кечкенә генә көчсез куллар, ә шулар Мефф Поттерга нихәтле ярдәм иттеләр, булдыра алсалар тагы да ярдәм иткән булырлар иде әле!

Том бик кәефсез хәлдә өенә кайтып керде һәм йокларга яткач коточкыч куркыныч төшләр күрде. Икенче көнне дә, өченче көнне дә ул иртәдән кичкә хәтле суд бинасы тирәсендә чуалды. Ниндидер җиңә алмаслык көч аны бина эченә тарта иде, әмма ул үзен тышкы якта калырга мәҗбүр итте. Һак та үзен шулай ук хис итә иде. Алар тырышып-тырышып бер-береннән качып йөрделәр. Вакыт-вакыт аларның тегесе дә, монысы да каядыр ерагракка китәргә тырышты, ләкин ниндидер дәһшәтле тылсым элекке урынына тартып китерде. Берәр ачык авызы суд залыннан чыгып сөйли башласа, Том аның һәрбер сүзен эләктереп алырга тырышты, тик хәбәрләрнең барысы да күңелсез иде; бичара Поттерның муенындагы элмәк кысылганнан-кысыла барды. Икенче көннең ахырына инде калада сүз гел шул турыда гына булды: индеец Джо үз сүзендә нык торды, Поттерга нинди хөкем чыгарачакларында бернинди шик тә калмаган иде.

Ул кичне Том өенә бик соң әйләнеп кайтты һәм бүлмәсенә тәрәзә аша гына керде. Ул бик нык дулкынланган иде һәм озак кына йокыга китә алмыйча ятты. Иртәгесен иртән бөтен кала суд бинасы алдына җыелган иде. Залга ирләр дә, хатын-кызлар да кереп тулган. Шактый озак көтәргә туры килде, ниһаять, бер-бер арт-

лы присяжныйлар керел, үзләренең урыннарына урнаштылар. Берничә минуттан коты алынып агарынган бичара Поттерны керттеләр; богауланган Поттерның бөтен кыяфәтенә өметсезлек билгеләре чыккан иде. Аны бөтен кеше дә күрә алырлык урынга утырттылар. Һәрвакыттагыча бернәрсәгә дә исе китми торган Индеец Джо да шулай ук кеше күрерлек урынга утырган. Яңадан тынлык урнашты, аннары судья килеп чыкты, һәм шәриф утырышны ачык дип белдерде. Һәрвакыттагыча суд әгъзалары үзара пышылдаша һәм ниндидер кәгазьләр актара башлады. Алар шул вак-төякләр белән мәшәләнгән арада залда шомлы тынлык урнашты.

Үтерү булган көннең иртәсендә Мэфф Поттерның иртүк елга буенда юынып маташканын күргән шаһитны чакырдылар. Мине күрүгә Мэфф Поттер шундук торып качты, дип таныклады шаһит. Тагын берничә сорау биргәч, прокурор яклаучыга мөрәҗәгать итеп:

— Хәзер сезнең чират, шаһитка сорауларыгызны бирә аласыз,— диде.

Гаепләнүче күтәрелеп карады да яклаучының:

— Минем шаһитка карата сорауларым юк,— дип җавап биргәнен ишеткәч, башын яңадан түбән иде.

Тагын бер шаһит үтерелгән кеше янында пычак тапканлыгын таныклады.

Яклаучыга мөрәҗәгать итеп, прокурор тагын:

— Шаһитка сорауларыгызны бирә аласыз,— диде.

Һәм яклаучы яңадан да:

— Шаһитка карата минем соравым юк,— дип җавап бирде.

Өченче шаһит, ант иткәннән соң, бу пычакны еш кына Поттер кулында күрә торган булуын әйтте.

Прокурор яңадан яклаучыга мөрәҗәгать итте:

— Шаһиттан сорау алырга мөмкин,— диде.

Поттерның яклаучысы бу шаһиттан дә сорау алудан баш тартты.

Залдагы кешеләрнең йөзенә ачу билгеләре чыкты. Нинди сәер яклаучы инде бу! Яклый торган кешесен элмәктән коткару өчен бернинди чара да күрмәс микәнни?

Берничә шаһит, үтереш булган урынга алып килгәч, Поттерның үзен бик тә сәер тотканын әйттеләр. Үз-үзен тотышыннан аның җинаятьче икәнен аңлап була иде, диделәр. Бу шаһитларны да сорау бирмичә кайтарып җибәрде яклаучы. Әлеге иртәдә зиаратта булган вакыйгалар вагына-төягенә кадәр шаһитлар тарафыннан сөйләнде, ләкин Мэфф Поттерның яклаучысы аларның берсенә дә бернинди сорау биреп карамады. Халыкның ачуы кабарды, һәм ул тавышлана ук башлады. Шуның өчен халык судьядан кисәтү алды. Шуннан соң прокурор болай диде:

— Бик тә ышанычлы шаһитлар, ант эчкәннән соң, бу коточкыч җинаятьнең гаепләнүчеләр эскәмиясендә утыручы әлеге бичара тарафыннан кылынуын таныкладылар. Минем башка сүзем юк: җинаять тулысынча расланды.

Мескен Поттер ыңгырашып куйды һәм куллары белән йөзен каплады, үзе әкрен генә әле алга, әле артка таба чайкалып торды. Хәтта ирләр борчуга калды, хатын-кызлар исә җылап ук җибәрделәр.

Шул чагында яклаучы урыныннан торып басты да судьяга мөрәҗәгать итеп болай диде:

— Хөрмәтле әфәнде! Суд утырышының башында мин үземнең клиентымның бу коточкыч үтерүне спиртлы эчемлекләр тәэсирендә, аңсыз рәвештә кылганын расларга ниятләнгәнемне әйткән идем. Ләкин мин үземнең ниятемне үзгәрттем һәм присяжныйлардан мәрхәмәт итүләре турында үтенмәячәкмен...

Һәм ул приставка:

— Томас Сойерны чакырыгыз! — дип мөрәҗәгать итте.

Бөтен кешенең, шул исәптән Поттерның да, йөзендә чиктән тыш нык гаҗәпләнү билгеләре чагылды. Залдагы кешеләрнең кызыксынулы карашы шаһитлар эскәмиясенә таба атлаган Томга юнәлде. Куркудан коты алынганга күрә, ул бик каушаган иде. Аны да ант иттерделәр.

— Томас Сойер, унҗиденче июньгә каршы төндә, төн урталарында, сез кайда идегез?

Индеец Джоның таш булып каткан йөзенә карагач Томның теле

аңкавына ябышты. Тыңлап торучылар тын да алмадылар, әмма Томның теле әйләнмәде. Шулай да берничә мәлдән соң малай бераз гына үзен кулга алды һәм алгы рәтләрдәге кешеләрнең кайберләре генә ишетерлек итеп:

— Зиаратта...— диде.

— Зинһар өчен, кычкырыбрак әйтегез. Курыкмагыз. Димәк, сез кайда булдыгыз?

— Зиаратта булдым.

Индеец Джоның йөзендә мыскыллы елмаю чагылып китте.

— Горс Уильямсның кабере тирәсендәрәк булмадыгызмы?

— Әйе, әфәнде.

— Зинһар өчен, кычкырыбрак сөйләгез. Нинди ераклыкта идегез сез ул кабердән?

— Менә хәзер сезнең белән икебез арасы кебек.

— Качып тордыгызмы, әллә ачыктан-ачык басып тордыгызмы?

— Качып тордым.

— Кайда?

— Кабер белән янәшәдә генә, карама агачлары артында.

Индеец Джо сизелер-сизелмәс кенә итеп сискәнеп куйды.

— Сезнең белән кем дә булса бар идеме?

— Әйе, әфәнде. Мин анда...

— Туктагыз, бер генә минутка сабыр итегез. Хәзергә юлдашыгызның исемен әйтүнең кирәге юк. Үз вакыты белән без аннан да сорау алырбыз... Зиаратка үзегез белән берәр нәрсә алып барган идегезме?

Том икеләнеп калды. Ул, күрәсең, уңайсызлана иде.

— Сөйләгез, дустым, курыкмагыз. Туры сүз таш ярыр, ди. Ни алып барган идегез соң зиаратка?

— Үлгән... мәче...

Залдагы халык күңелле итеп бер дулкынланып алды. Судья кыңгыравын шылтыратып куйды.

— Судка без шул мәченең скелетын китерербез. Ә хәзер, дустым, бер нәрсәне дә төшереп калдырмыйча бөтенесен дә бәйнәбәйнә сөйләп бирегез.

Том сөйли башлады. Башта ул тотлыгыбрак торды, аннары әкренләп җанлана төште һәм иркенләп сөйли башлады. Бераздан залда башка тавышлар тынып калды; бөтен күзләр аңа текәлде, тыңлаучылар авызларын ачып тын да алмыйча аның һәр сүзен йотып бардылар — малайның сөйләгәне, аның коточкыч хикәясе аларны шулкадәр мавыктырды. Том үтерү моменты турында сөйли башлагач, гомуми дулкынлану чигенә җитте:

— Мэфф Поттерның башына доктор такта белән китереп суккач, Индеец Джо докторга пычак белән ташланды һәм...

Трах! Индеец яшен тизлеге белән тәрәзәгә ташланды һәм, үзен тотып калырга тырышучыларны төрткәләп, тәрәзәдән тышка атылды да юкка чыкты!



XXV бүлек

Том яңадан мәшһүр каһарманга әйләнде. Өлкәннәр аны яңадан да иркәләп узындырдылар, балалар исә үлә язып көнләштеләр. Ул мәңгелек данга иреште: җирле гәзит аны күкләргә күтәреп мактады. Кайберәүләр, алданрак асып куймасалар, президент булыр бу, дип тә юрадылар.

Гадәттәгечә беркатлы, фикерен тиз үзгәртүчән халык, әле яңа гына кайнарланып тиргәгән һәм мәсхәрәләгән кебек үк, колачын җәеп Мэфф Поттерны иркәли дә башлады. Бу хәл кешеләрнең яхшылыгын гына күрсәтә, шуңа күрә моның өчен аларны шелтәләргә кирәкми.

Көннәрен сөенеп, күңелле итеп үткәрде Том, ләкин төннәрен куркудан җәфаланды. Индеец Джо өзлексез аның төшләренә керде һәм шәфкатьсез рәвештә үч алу белән янады. Караңгы төшкәч Томны берни белән дә кызыктырып урамга чыгарып булмый иде. Бичара Һак та куркудан үләргә җитеп йөрде, чөнки суд буласы көнгә каршы кичен Том бөтен вакыйганы бәйнә-бәйнә яклаучыга сөйләп биргән, шуңа күрә Һак үзенең дә бу эштә катнашуы беленмәгәе дип курыкты, хәлбуки индеецның качып китүе аны судта чыгыш ясаудан коткарды. Яклаучы мескен Һакка барысын да сер итеп тотарга вәгъдә бирде-бирүен, ләкин моңа ышанып буламыни? Вөҗдан газабы Томны, яклаучының өенә алып килеп, аның авызыннан (гәрчә алар әйтмәскә дип ант эчкән булса да) коточкыч серне тартып алганнан соң, Һакның кешелек дөньясына карата булган ышанычы нык кына какшады.

Һәр көнне, Мэфф Поттерның рәхмәтләрен ишеткән саен, Том дөреслекне әйтеп бирүенә куана иде һәм һәр төнне, телемне тыя алмадым, дип, үкенеп бетә алмыйча изалана иде.

Том ярты гомерен, Индеец Джоны бервакытта да тота алмаслар, дип куркып үткәрде, гомеренең икенче яртысын, аны тотмый калмаслар, дип яшәде. Бу кешенең үле гәүдәсен күргәч кенә тынычланачак иде ул.

Бөтен тирә-якны айкап эзләп бетерделәр, метисны тотып биргән кешегә бүләкләр вәгъдә иттеләр, ләкин барыбер тота алмадылар. Сент-Луидан бөтен нәрсәне белә торган могҗизаи-мөдәгыйне — полиция шымчысын чакырттылар. Ул эзләнде, иснәнде, мәгънәле кыяфәт белән башын чайкаштырган булды, үзе кебек үк белгечләр алдында зур уңышка ирешеп, ягъни җинаятьченең «эзенә төшеп», эшен тәмамлады. Ләкин бит «эзне» дарга асып куеп булмый! Шуңа күрә, шымчы китеп баргач та, Томның хәле үзгәрмәде: ул үзен һаман да коточкыч начар хис итте.

Шулай да көн артыннан көн үтә торды, һәм малайлар үзләрен борчыган куркынычны әкренләп оныта башладылар.



XXVI бүлек



Һәрбер малайның тормышында шундый бер вакыт җитә: берәр җиргә барып, казынып, яшерен хәзинә табу хыялы борчый башлый аны. Бу теләк көннәрдән бер көнне Томның да күңелен биләп алды. Ул Джо Һарперны эзләп тапмакчы булды, ләкин таба алмады. Том Бен Роджерска кагылды, ул да балыкка киткән булып чыкты. Ниһаять, ул очраклы рәвештә генә Канлы кул Һак Финнга барып юлыкты. Аның да кирәге чыгуы ихтимал иде, әлбәттә. Том аны аулак урынга алып керде дә үзенең яшерен планын сөйләп бирде. Һак риза булды. Күңел ачу вәгъдә иткән һәр эшкә катнашырга риза иде ул, тик ул эш акча гына сорамасын, ә вакыты аның җитәрлек иде. «Вакыт — акча» дигән әйтемне исә аңа карата кулланып булмый иде.

— Кай җирдә казыйбыз соң без аны? — дип сорады Һак.

— Теләсәң кайда!

— Ничек, хәзинә теләсә кая күмеләмени ул?

— Юк инде, Һак! Кайчакта аны берәр төрле утрауда күмәләр, кайчакларда иске сандыкка салып корыган агач төбендә яшерәләр; төн уртасында агач ботагыннан күләгә төшкән җиргә күмәләр; күбесенчә йорт иясе яши торган иске өйләрнең идән асларына күмәләр.

— Кемнәр күмә соң аны?

— Юлбасарлар, билгеле! Синеңчә, кем соң? Якшәмбе мәктәбе башлыклары дип уйлыйсыңмы әллә?

— Мин каян белим. Хәзинә минеке булса, мин аны күмеп тә тормас идем, акчамны үз кирәгемә тотып, рәхәтләнеп яшәр идем.

— Мин дә шулай итәр идем анысы. Ләкин юлбасарлар акчаны тотмыйлар, алар аны һәрвакыт күмеп куялар.

— Яңадан килеп тә алмыйлармы?

— Юк, үзләре килеп алырга хыялланып йөриләр, ә үзләре тора-бара күмгән җирләрен онытып җибәрәләр яисә үлеп китәләр. Шулай итеп хәзинә ята-ята да тутыга башлый. Аннары берәрсе искереп, саргаеп беткән кәгазь таба, анда хәзинәне нинди билгеләр буенча эзләргә икәне язылган була. Кәгазьнең үзен дә әле атна буена укыйсы була, чөнки анда ниндидер ыргаклар да иероглифлар гына төшерелгән була.

— Ир... ничек?

— Иероглифлар... төрле рәсемнәр ул... кеше танымаслык язулар... бер караганда алар сүз кебек тә түгел...

— Синең дә шундый кәгазь бармы әллә, Том?

— Юк шул.

— Хәзинә яшерелгән урыннарның билгесен син каян белерсең соң?

— Ә миңа ул билгеләрнең кирәге дә юк. Хәзинә берәр иске йорт астына яисә утраудагы берәр агач төбенә күмелгән була, ул агачның гадәттә бер генә ботагы була. Без инде Джексон утравында эзләп тә карадык, яңадан да эзләп карарга була; аннары елга аръягында бер иске йорт бар, анда корыган агачлар да теләсәң нихәтле.

— Агач төбе саен хәзинәме?

— Булды ди, булмыйни!

— Кайсы агач төбен казыйсы икәнен каян беләсең соң син?

— Бөтен агач төпләрен дә казыйбыз.

— Шулай итеп бөтен җәй дә үтеп китәр бит?

— Үтсә соң! Аның каравы күз алдыңа китер: менә дигән йөзләп доллар тутырылган бакыр казан яисә брильянт тулы сөрсегән сандык килеп чыкса, нишләр идең?

Һакның күзләре яна башлады:

— Менә шә-ә-әп! Гомерем буена җитәр иде. Тик нәрсәгә ул миңа брильянт? Син миңа йөз долларыңны бир дә, брильянтыңның миңа бушка да кирәге юк.

— Ярар, мин брильянттан баш тартмыйм, тыныч бул. Аның

берсе-берсе егермешәр доллар торганнары була. Бер доллардан да арзанрагы булмый да.

— Кит аннан! Булмасны!

— Чынлап менә, теләсә кемнән сора әнә. Синең әллә брильянт күргәнең юкмы, Һак?

— Юк бугай шул.

— Корольләрдә ул өем-өем була.

— Соң минем бит корольләр белән танышлык юк.

— Кая инде ул сиңа! Менә син Европага барып чыксаң икән, өере белән король күрер идең. Алар анда мыжлап тора, үзләре сикергәлиләр.

— Сикергәлиләр?

— Менә кызык! Нишләп сикерсеннәр ди инде!

— Үзең бит, сикергәлиләр дисең.

— Юкны! Европада күп алар дип әйтәсем генә килде минем. Әлбәттә инде алар сикергәләмиләр. Ник сикергәләргә ди аларга? Күрсәң иде син аларның анда күплеген, әнә теге — бөкре Ричард кебекләрнең...

— Ричард? Фамилиясе ничек соң аның?

— Фамилиясе юк аның. Корольләрнең гомумән дә фамилиясе булмый.

— Кит аннан?

— Ихлас минә!

— Алай булгач, мин король булырга теләмәс идем. Бәлки аларга негрлар кебек фамилиясез, исем белән генә йөрү ошыйдыр, әмма миңа ошамый. Иң яхшысы, син миңа нәрсәне әйт: кайда казымакчы буласың?

— Белмим әле. Әйдә булмаса елга аръягында калкулык өстендәге корыган агач төбен казый башлыйбыз.

Алар тутыккан киркә белән көрәкләрен алып өч чакрымдагы елга буена юнәлделәр. Тиешле урынга эсседән тирләп-пешеп, тыннары бетеп барып җиттеләр, якында гына үсеп утырган карама төбендә күләгәгә сузылып яттылар да тәмәкеләрен кабызып җибәрделәр.

— Их, рәхәт тә соң! — диде Том.

— Әйе шул! — дип, килеште аның белән Һак.

— Карале, Һак, әгәр дә без хәзинә тапсак, син үз өлешеңне нишләтәсең?

— Минме? Көн саен берәр сумса белән бер стакан содалы су сатып алам; цирк килгән саен циркка барам. Аптырама, ничек яшәргә икәнен белермен.

— Акча җыярга уйламыйсыңмы соң?



— Җыярга? Нәрсәгә?

— Ничек инде нәрсәгә! Кара көнеңдә дә акчаң булсын өчен!

— Нәрсәгә ул! Әгәр дә мин акчамны тотып бетермәсәм, кайчан да булса атам кайтып төшәр дә акчамны басып алыр. Аннары җыярсың бар, җыймый ни! Тиенен дә калдырмас! Ә син үз өлешеңне нишләтәсең, Том?

— Үземә яңа барабан, чын кылыч, кызыл галстук, бульдог көчеге сатып алам, аннары өйләнәм.

— Өйләнәсең?

— Тилергәнсеңдер син, Том!

— Күрерсең әле менә!

— Шуннан да ахмаграк нәрсә уйлап таба алмагансың инде. Менә минем әткәй белән әнкәйне генә алып кара. Бар белгәннәре сугышу иде. Мин моны бик яхшы хәтерлим.

— Анысы ярар ла. Мин өйләнәсе кыз сугышмый ул.

— Миңа калса, алар барысы да бер иш. Юк, Том, син уйла әле яхшылап. Уйла дим мин сиңа. Ул кызыйның исеме ничек соң?

— Кызый түгел ул, кыз.

— Ну, анысы инде аның барыбер. Кем кызый ди, кем кыз ди. Тегеләй дә ярый, болай да. Исеме ничек дим, Том?

— Берәр әйтермен әле, хәзер түгел.

— Ярый соң, анысы синең эш. Тик менә син өйләнсәң мин ялгыз калам бит.

— Менә тагы! Безгә күчәсең дә бергә яшибез... Ә хәзер җиткән кырын-ярын ятарга, әйдә, казый башлыйбыз.

Ярты сәгатьләр чамасы эшләп, алар шабыр тиргә баттылар, ләкин берни дә таба алмадылар; тагын ярты сәгатьләп казыдылар, һаман да берни килеп чыкмады. Ниһаять, Һак болай диде:

— Хәзинәләрне гел шулай тирәнгә күмәләрме?

— Юк, гел түгел, кайчакны гына. Бөтен кеше дә алай эшләми дә. Минемчә, без кирәкле җирне казымыйбыз.

Алар икенче бер урынны сайлап шул төшне казырга тотындылар. Хәзер эш авырлык белән булса да әкренләп алга барды. Берникадәр вакыт алар сөйләшмичә генә казыдылар, аннары Һак казудан

туктады да, көрәгенә таянып, маңгаендагы эре тир бөртекләрен сөртә-сөртә болай диде:

— Монан соң тагын кайда казыйбыз?

— Әйдә, Дуглас исемле тол хатынның йорты артындагы Кардиф тавында үсеп утырган карт агач төбен казып карыйбыз.

— Карап карарга ярый, минемчә. Ул хатын безнең хәзинәне талап алмасмы соң? Агач аның җирендә үсә икән бит?

— Талап дисеңме?! Алып карасын! Тапкан кешенең үзенә була инде ул хәзинә. Кем җирендә булса да.

Һак тынычланып калды. Эшне дәвам иттеләр. Бераз вакыттан соң Һак тагын сүз башлады:

— Шайтан алгыры, без тагын кирәкле урынны казымыйбыз бугай. Синеңчә ничек?

— Ничектер сәеррәк әле бу, Һак, бик сәер, аңлап та булмый. Җеннәр дә комачаулый инде ул. Минемчә, шулар шаярта безне.

— Нишләп инде? Көндез нинди пәри булсын ди? Көндез аларның тәэсир көче бетә бит.

— Анысы дөрес. Мин анысын уйламаганмын. Әйе, мин хәзер эшнең нәрсәдә икәнен беләм инде. Ишәк тә инде без синең белән. Төн уртасында иң озын ботакның күләгәсе кайда төшкәнен белергә кирәк иде бит башта, аннары шул урынны казырга.

— Димәк, без — тинтәкләр — көн буена бер файдасызга казыганбыз! Их, хәзер инде шушында төн уртасында килергә кирәк! Төн уртасы бик ерак бит әле. Син өеңнән чыгып китә алырсыңмы соң?

— Чыгам, билгеле! Барыбер бүген төнлә казырга кирәк, югыйсә мондагы без казыган чокырларны берәрсе күрсә, шундук эшнең нидә икәнен аңлар да хәзинәне казып алыр.

— Ярар, мин бүген төнлә сиңа мияулармын, алайса.

— Яхшы. Әйдә көрәкләрне куак төбенә яшереп куйыйк.

Билгеләнгән сәгатьтә төнлә малайлар шушы агач төбенә тагын килделәр. Күләгәгә утырып көтә башладылар. Урыны бик аеравык иде, вакыты исә — гомер-гомергә куркыныч саналган җиде төн уртасы иде. Шыбырдашкан яфраклар арасында җеннәр пышылдаша, һәр караңгы почмакка пәриләр посмандыр сыман, ерактан тонык

кына булып эт өргәне ишетелә, аңа каршы шомлы тавыш белән ябалак җавап бирә. Малайлар бик аз сөйләштеләр, аларга вакытның соң булуы нык тәэсир итә иде. Тиздән алар төн уртасы җитте дигән карарга килделәр; күләгә төшкән җирне билгеләп, казый да башладылар. Аларның күңелендә өмет чаткылары уянды: эшләве кызыграк була башлады, һәм алар тырышыбрак казырга тотынды. Чокыр тирәнәйгәннән-тирәнәя барды. Көрәк берәр каты нәрсәгә барып төртелгән саен аларның тыннары кысылды, әмма малайларның кабат-кабат күңелләре генә кайтты. Ниһаять, Том болай диде:

— Юкка гына тырышабыз без, Һак. Тиешле җирдән казымыйбыз бит.

— Ничек инде? Хата булырга мөмкин түгел. Нәкъ күләгә төшкән җирдән казый башладык бит.

— Шулай икәнен беләм, ләкин эш анда түгел.

— Нәрсәдә соң?

— Эш менә нәрсәдә: вакытны без чама белән генә билгеләдек бит. Йә бик иртә, йә бик соң булгандыр.

Һакның кулыннан көрәге төшеп китте.

— Дөрес... Хикмәт шундадыр. Димәк, бу эшне туктатырга туры килә. Төгәл вакытны бит без барыбер белә алмабыз. Аннары тирә-якта җен-пәриләр мыжлап торгач куркыныч та инде. Гел артымда кемдер торадыр сыман, әйләнеп карар идем, куркам, бәлки минем артка борылганымны гына көтәләрдер кебек. Аркам гел чымырдап тора.

— Мин дә шөр-шөринрәк шул, Һак. Беләсеңме, агач төбенә акча күмгәндә, саклап торсын дип, аның өстенә һәрвакыт мәет салып күмәләр икән.

— Йа Ходай!

— Әйе, әйе. Әллә ничә кешедән ишеткәнем бар бу турыда.

— Беләсеңме, Том, мәетләр булган җирне казу бер дә ошамый миңа. Алар белән шаярырга ярамый.

— Минем дә кузгатасым килми шул аларны, Һак Кинәт берәрсе чокырдан баш сөяген калкытыр да безгә берәр сүз кушар.

— Ташла әле, Том! Болай да куркыныч.

— Куркыныч булмый ни. Бала йоннары кабара хәтта.

— Әйдә, шулай итсәк яхшырак булыр, мөгаен,— диде Том.

— Кая барабыз соң?

Том бераз уйлап торды.

— Әнә теге, өрәкләр җыела торган өйгә.

— Кит әле! Сөймим шул өрәкләрне, Том. Мәетләрдән дә болайрак алар. Мәет әле бәлки берәр сүз әйтер дә, тик ул инде өрәк кебек кәфеннән генә синең тирәңдә уралып та йөрми, йөзеңә дә үрелеп карамый, тешен дә шыгырдатмый. Мин бу хәлгә чыдый алмыйм, Том, мин генә дә түгел, бүтән берәү дә чыдый алмас иде.

— Әйе анысы. Ләкин бит өрәкләр төнлә генә йөри; көндез алар безгә казырга комачау итмәс.

— Шулай да булсын, ди; ләкин бит бу йорт буеннан төнлә түгел, көндезен дә беркемнең узып йөрмәгәнен син яхшы беләсең.

— Кешеләр, гомумән, кемне дә булса үтергән җиргә барып йөрергә яратмыйлар. Ләкин бит ул йортта төнлә дә берни күренми, кайчакта гына тәрәзәсеннән зәңгәр ут чагылып китсә генә инде, ә болай чын өрәкләр юк бит анда.

— Беләсеңме, Том, әгәр син берәр җирдә зәңгәр ут күрәсең икән, якын тирәдә өрәк булуына да ышандыра аласың. Өрәктән башка кемгә кирәге бар аның, ул зәңгәр утның!

— Анысы шулаен-шулай аның, тик алар бит көндез барыбер күренмиләр. Нәрсәдән куркабыз соң без?

— Ярар алайса, телисең икән, әйдә казып карыйк. Тик барыбер куркыта инде.

Бу вакытта алар тау астына төшеп баралар иде. Аста, ай яктырткан үзәндә, бөтенләй бер читтә, баскычына хәтле куе чүп үлән баскан, ихатасыз-нисез, сихерләнгән йорт тора; аның морҗасы җимерелеп төшкән; тәрәзәсенең пыялалары коелган; түбәсенең бер почмагы да җимерелгән иде. Малайлар ташландык өйне ерактан шактый озак күзәттеләр, менә-менә тәрәзәдә зәңгәр ут җемелдәр дип алар тәмам ышанганнар иде; мондый урын һәм вакыт таләп иткәнчә, пышылдап кына сөйләшә-сөйләшә, алар иске йортны читтәнрәк әйләнеп үтәргә дип уңга таба борылдылар һәм өйләренә урман аша, Кардиф тавының икенче ягыннан кайтып керделәр.



XXVII бүлек

Икенче көнне төш турында малайлар тагын теге корыган агач төбенә килделәр — аннан көрәк белән киттмәннәрен аласылары бар иде аларның. Томның тизрәк өрәкле өй янына барасы килә иде. Бик үк ашкынып булмаса да, Һак та шунда омтыла иде. Ул кинәт кенә:

— Том, бүген нинди көн икәнен беләсеңме син? — дип сорады.

Том күңеленнән тиз генә атнаның бөтен көннәрен санап чыкты.

— Ой! Башыма да килмәгән, Һак!

— Мин дә уйламаганмын шул, менә хәзер башыма сукты: бүген бит җомга көн!

— Хәерсез! Ә бит менә ничек игътибарлы булырга кирәк, Һак! Мондый эшне җомга көнне башласак, мөгаен бәлагә тарыган булыр идек.

— Мөгаен гына түгел, һичшиксез тарыган булыр идек. Бәхетле көннәр буладыр ул, тик җомга көн түгел.

— Шулай икәнен аның белмәгән кеше юк. Син уйлап чыгармаган аны.

— Мин уйлап чыгардым, дип әйтәмме әллә? Аннары эш җомга көндә генә дә түгел. Мин бүген шундый әшәке төш күрдем... күселәр...

— Төштә күсе күрү — юньлегә түгел инде ул... Сугыштыларммы соң?

— Юк, сугышмадылар.

— Алай булса ярый әле ул, Һак! Төштә күселәр сугышмаса бәла-

каза йә була, йә юк. Безгә уяу булырга, хәвеф-хәтәрдән сакланырга кирәк. Бүген яңадан казымабыз инде, уйнарбыз. Робин Гуд турында ишеткәнең бармы синең, Һак?

— Юк. Кем соң ул?

— Англиянең иң атаклы кешесе булган ул. Юлбасар!

— Шундый булсаң иде ул мена! Юлбасар булып кемнәрне талаган соң ул?

— Епископларны, шәрифләрне, байларны да корольләрне. Ә мескен ярлыларны бервакытта да рәнҗетмәгән. Ярата торган булган ул аларны. Азык-төлеген, бар булганын һәрвакыт алар белән уртаклашкан.

— Менә әйбәт кеше булгандыр ул!

— Әйе шул. Ул дөньядагы бөтен кешеләрдән әйбәтрәк тә, намуслырак та булган, Һак. Хәзер андый кешеләр юк инде, менә нәрсә әйтәсем килә сиңа. Бер кулын каерып аркасына бәйләп куйсаң да, сыңар кулы белән теләсәң кемне тукмый алган... Бер ярым мильдән торып тис җәядән ун тиенлек акчага тидерә торган булган.

— Ни соң ул — тис җәя?

— Әллә тагы. Ниндидер үзенә бер төрле җәя шунда. Әгәр тәңкәнең урта бер җиренә тидермичә читенә генә тидерсә утырып җылый, хәтта сүгенә торган булган. Менә без шул Робин Гудлы уйныйбыз инде. Иң шәп уен шул. Өйрәтермен мин сине уйнарга.

— Ярар.

Алар кичкә кадәр Робин Гудлы уйнадылар, үзләре вакыт-вакыт сагышланып өрәкле өйгә таба күз салгаладылар, иртәгә анда нәрсә эшләячәкләре турында да сөйләшкәләп алдылар. Кояш көнбатышка таба авыша башлау белән малайлар, агачларның озын-озын күләгәләре аша атлап чыга-чыга, Кардиф тавындагы урман эчләтеп өйләренә таба юл тоттылар.

Шимбә көнне төштән соң малайлар тагы корыган агач янына килделәр. Башта алар күләгәгә утырып тәмәке кабыздылар, бераз гапләшеп алдылар, аннары, уңышка әлләни өметләнми генә, иң соңгы дигән чокырларында казынып маташтылар. Малайлар сөенә-сөенә шундук китеп тә барган булырлар иде, ләкин, Томның сүзенә кара-

ганда, еш кына шулай да була икән: берәү хәзинәгә килеп җиттем дигәндә генә казуын ташлап китә, ә икенче берәү килеп күрәген бер-ике генә тапкыр төртүгә байлык килеп тә чыга икән. Әмма ләкин бу юлы да аларның тырышлыгы уңыш китермәде. Хәзинә эзләүчеләргә ни эшләргә тиеш булса, шуларның бөтенесен дә намус белән башкарган малайлар, көрәкләрен иңбашларына салып, китеп бардылар.

Өрәкләр яши торган йорт янына килеп җиткәндә эссе һавада хөкем сөргән тынлык аларга шомлы да, куркыныч та булып тоелды. Бу ташландык буш йорт ниндидер авыр хисләр уята иде. Малайлар байтак вакыт өй эченә аяк басарга кыймый тордылар. Алар шыпырт кына ишек янына килеп, курка-курка гына эчкә күз салдылар. Идәнсез-нисез бүлмәнең стеналарыннан штукатуры коелган, миче ишелгән, аяк астын куе үлән баскан; тәрәзәләреннән пыялалары коелып төшкән; баскычы җимерелгән, бөтен җирдә пәрәвез оялары салынып тора. Малайлар тавыш-тынсыз гына эчкә керделәр, аларның йөрәкләре атылып чыгардай булып типте, һәр кыштырдаган тавышка колак салып, андый-мондый хәл була калса торып чабарга әзерләнеп, малайлар пышылдап кына сөйләштеләр.

Беркадәр вакыттан соң алар күнегеп киткәндәй булдылар, курыкмый башладылар. Тирә-якларына кызыксынып һәм шикләнеп карадылар, шул ук вакытта малайлар үзләренең кыюлыкларына сокландылар һәм шуңа гаҗәпсенделәр дә. Аннары аларның өске каттагы хәлләргә күз саласы килде. Бу инде күпмедер дәрәҗәдә үзеңнең чигенү юлыңны кисү дигән сүз дә иде, ләкин алар бер-берсен котыртыша башладылар һәм, әлбәттә, аның нәтиҗәсе бер булды: алар көрәккитмәннәрен ыргыттылар да баскычка барып менделәр. Өске катта да шундый ук вәйранлык хөкем сөрә иде. Бер почмакта алар ниндидер чолан сыман нәрсә барын ачыкладылар, карап торуга ул бик серле һәм кызыктыргыч сыман иде, ләкин аларның өметләре акланмады — чоланда бер нәрсә дә юк иде. Хәзер инде малайлар бөтенләй кыюланып киттеләр һәм, аскы катка төшеп, эшкә тотынырга дип кенә торганда кинәт:

— Ш-ш! — диде Том.

— Нәрсә бар? — дип пышылдады куркуыннан агарынган Һак.

— Ш-ш! Менә... ишетәсеңме?..

— Әйе!.. Әйдә, качыйк тизрәк!

— Тавышланма! Кыймылдама! Монда киләләр, туп-туры ишеккә таба!

Малайлар идәнгә сузылып яттылар да, идәндәге ботак тишекләреннән ни дә булса күрергә тырышып, куркуларыннан тыннарын кыстылар.

— Менә туктадылар... Юк... киттеләр... Киләләр. Тыныңны чыгарма, Һак. Их, ник кенә килдем монда!

Өйгә ике кеше килеп керде. Малайлар һәр икесе эчтән генә:

«Бусы — чукрак-телсез испан карты, калада бер-ике тапкыр күренгән иде, икенчесен күргәнем юк»,— дип уйлап алдылар.

«Икенчесе» дигәне — тузгыган чәчле, күңелгә ятышсыз, шакшы бер йолкыш иде. «Испан» дигәне плащка төренгән; аның чигә сакаллары ап-ак; эшләпәсе астыннан көмештәй ак озын чәчләре иңбашларына төшеп тора; үзе яшел күзлек кигән. Алар өй эченә килеп кергәндә «икенчесе» «испан» дигәненә әкрен генә нидер сөйли иде; бу адәмнәр ишеккә таба йөзләре белән стена буена идәнгә утырдылар; тегесе, «икенчесе» дигәне, һаман әле нидер сөйләп маташты. Хәзер инде ул алай ук сак кыланмады, һәм аның сүзләре малайларга аңлаешлырак булып ишетелә башлады.

— Юк,— диде ул,— мин барысын да уйладым, миңа бу эш ошамый. Куркыныч.

— Куркыныч! — дип мыңгырдады «чукрак-телсез испан» малайларның гаҗәпләнүенә каршы.— Их син, җебегән! — диде ул.

Бу тавышны ишетүгә алар авызларын ачып дерт итеп куйдылар. Бу бит Индеец Джо тавышы. Аскы каттагылар беркадәр тын тордылар. Аннары Джо:

— Теге соңгы эш нинди куркыныч иде югыйсә. Узды бит! — дип куйды.

— Ул бит бөтенләй башка. Анысы елга буйлап югарыга таба иде, һәм янәшә-тирәдә башка бернинди йорт та юк иде. Эш барып чыкмаган булса да беркем без маташкан дип уйламый иде...



— Көпә-көндез монда килеп йөрү дә куркыныч бит: күрүче-нитүче булса шикләнми калмый инде.

— Анысын беләм лә. Бүтән качар урын булмады бит. Минем бу алачыкта гомумән дә каласым килми. Кичә үк сызмакчы идем әле мин, тик шыпырт кына ычкыну турында уйлыйсы да түгел иде,— каһәр төшкән малайлар тауда казыныпмы-казыналар, йорт исә уч төбендәге кебек аермачык булып күренеп тора.

Бу сүзләрне ишеткәч «каһәр төшкән малайлар» яңадан калтыранып куйдылар. Эшләрен җомга көнне башламаулары исләренә төшеп, алар куанып бетә алмадылар.

Сукбайлар нindidер ашамлык чыгарып тамак ялгарга керештеләр. Озак кына уйланып утырганнан соң Индеец Джо болай дип сүз башлады:

— Менә нәрсә, балакай, килгән җиреңә кире кит әле син: елга буйлап үргә таба һәм миннән хәбәр көт. Ә мин тәвәккәлләргә булдым — кала буйлап йөргәләп алам, караштыргаларга кирәк бит,

ичмасам. Теге хәтәр эшне төпченебрәк белешкәч бар ягын да әйбәтләп уйлашырбыз да, ниһаять, тәвәккәлләрбез. Аннары Техас якларына чыгып ычкынырбыз. Бергәләп!

Шулай дип хәл иттеләр дә. Аннары алар икесе дә авызларын ачып иснәргә тотындылар. Индеец Джо болай диде:

— Үтерер йокы килә. Сакларга хәзер синең чират. Ул сайгак астыннан үсеп чыккан үлән арасына кереп ятты да шундук гырлый башлады. Иптәше аны бер-ике тапкыр селкетеп алгач, ул тынып калды. Тиздән боларның каравылда утырганы да йокымсырый башлады; әкрен-әкрен аның да башы салынып төште, бераздан инде алар икесе дә парлап гырлыйлар иде.

Малайлар җиңел сулыш алып куйдылар.

— Әйдә,— дип пышылдады Том.— Әйдә!

— Булмый! — диде Һак.— Уяна калсалар йөрәгем ярылачак.

Том күндерергә тырышты, Һак һаман да үз киресен итте. Ниһаять, Том иплəп кенә урыныннан торды да үзе генә китәргә җыенды. Ләкин ул беренче адымын атлауга ук калҗаеп беткән идән сайгаклары иләмсез тавыш чыгарып шыгырдап җибәрде, хәтта ки Том үзе дә коты алынып идәнгә сеңде һәм кабат китәргә маташып та карамады. Минутлар һич кенә дә үтә белмәде; малайлар сузылып идәнгә яттылар, һәм аларга инде вакыт тәмам бетеп, мәңгелек үзе дә картаеп чаларгандыр кебек тоела башлады.

Тора-бара юлбасарларның берсе гырлавыннан туктады. Индеец Джо торып утырды да як-ягына карангалады, башын тезенә салып йоклап утырган иптәшенә күз салды, караңгы чырай белән генә көлемсерәп куйды, аннары аңа аягы белән төртеп:

— Тор әйдә! Каравылчы, имеш! — дип куйды. Аннары,— Хәер, ярар әйдә... Берни дә булмаган,— дип өстәде.

— Йоклап ук киткәнмен икән!

— Шулайрак булган шул. Кузгалырга вакыт, дустым. Калган акчаны нишләтәбез соң?

— Белмим шул, шушында калдырыргадыр инде. Җыенып көньякка киткәләгәнче үзебез белән алырга кирәк түгелдер. Алты йөз илле көмеш тәңкәне үзең белән өстерәп йөрү җиңел булмас.

— Ярар... Тагын бер тапкыр моннан әйләнербез...

— Иң яхшысы элекке сыман төнлә килүдер инде... Шулай дөресрәк булыр.

— Шулаен шулай да, тик менә нәрсә бит: бәлки мин теге эшне тиз генә башкара алмам. Ни килеп чыгасын хәзердән үк белеп булмый. Ә менә акчаларыбыз начар яшерелгән. Әллә әйбәтләбрәк — тирәнрәк итеп күмеп куябызмы?

— Ярый торган эш,— дип килеште Индеец Джоның иптәше һәм, булмә аша үтеп, учак янына барып тезләнде дә, аның төбеннән бер кирпечне алып, капчык тартып чыгарды. Капчык эчендә нидер күңелле итеп чылтырап куйды. Юлбасар, капчыкка кулын тыгып, бер уч доллар алды да шуның кадәр үк Индеец Джога алып бирде һәм капчыкны Индеец Джоның үзенә тоттырды; бу вакытта Джо тезләнеп кәкре пычак белән почмакта җир казып маташа иде.

Малайлар бөтен кайгыларын һәм куркуларын оныттылар. Янып торган күзләре белән алар сукбайларның һәр хәрәкәтен күзәтә иде. Менә ичмасам чыкты җай! Мондый байлыкны алар күз алдына да китерә алмый иде. Йөзләгән доллар! Бу кадәр акча белән дөнья хәтле малайны баетырга була! Хәзинә бернинди мәшәкатьсез үзе кулга кереп тора бит. Кай җирдә казырга дип баш ватасы да юк. Алар минут саен бер-берсенә терсәкләре белән төртешеп тордылар, һәм аларның һәркайсысы моның: «Монда булуыбызга сөенәсеңдер инде!» дигән сүз икәнен аңлый иде.

Индеец Джоның пычагы нииндидер бер каты нәрсәгә барып төртелде.

— Оho! — дип җибәрде ул.

— Нәрсә бар? — дип сорады юлдашы.

— Черегән тактамы соң... Юк, нииндидер сандык бугай. Кая, кил әле, булыш, ни икәнен хәзер белербез. Юк, кирәкми, пычак белән төртеп тиштем инде.

Ул кулын тартмага тыгып җибәрде дә шундук тартып алды:

— Карале, акча бит монда!

Алар икәүләшеп Джоның учындагы тәңкәләрне карарга тотын-

дылар. Алтын бит! Өске катта яткан малайлар да шулай ук дулкынланалар һәм сукбайлардан ким сөенмиләр иде.

Индеец Джоның юлдашы болай диде:

— Моны сузарга ярамый. Хәзер үк эшкә тотыныйк! Мин әле генә шушында мич артында тутыгып беткән бер иске китмән күргән идем.

Ул йөгереп кенә малайлар куеп калдырган эш коралларын алып килде. Индеец Джо китмәнне әйләндереп-әйләндереп карады да, башын чайкап, борын эченнән генә нидер мыгырдана-мыгырдана эшкә тотынды.

Тиздән сандыкны тартып чыгардылар. Ул артык зур түгел иде, калай белән тышланган һәм, вакытлар узып черегәнче, бик нык булгандыр, күрәсең.

Сукбайлар берникадәр вакыт буена башлары күккә тиярдәй булып хәзинәгә карап, хозурланып тордылар.

— Ай-яй, дустым, монда бит меңләп доллар бар! — диде Индеец Джо.

— Бу тирәдә бер җәйне Морелл шайкасы йөргәнен сөйлиләр бит,— дип искәрде таныш булмаган сукбай.

— Беләм,— диде Индеец Джо,— күрәсең, шулар яшереп калдыргандыр.

— Хәзер сиңа теге эш белән маташып та йөрисе юк инде.

Метис чыраен сытты.

— Белмисең син мине,— диде ул.— Аннары син әлеге эш турында барысын белеп бетермисең. Эш монда талауда түгел, үч алуда.— Аның күзендә явыз очкыннар елтырады.— Миңа синең ярдәмең кирәк булыр... Ул эшне башкарганнан соң Техаска элдерербез! Бар, Нэнсиең, балаларың янына кайт та миннән хәбәр көт.

— Ярар, синеңчә булсын алайса. Ә моны нишләтәбез, яңадан күмеп куябызмы әллә?

— Әйе... (Өске катта — тантана, чиксез шатлану.) Юк, бөек Сахем[1] исеме белән ант итеп әйтәм, юк! (Өске катта — тирән

---

[1] *Сахем* — Төньяк Американың кайбер кабиләләре үзләренең төп юлбашчыларын шулай дип атаганнар.

кайгы.) Онытып җибәрә язганмын: китмәнгә бит яңа гына казылган балчык ябышкан иде. (Куркудан малайларның котлары ботларына җитте.) Каян килгән монда бу көрәк белән китмән? Каян аларга яңа гына казылган балчык ябышкан? Аларны монда кем алып килгән, һәм ул кешеләр кая киткән? Син ишеттеңме берәр нәрсә? Күрдеңме берәрсен? Ничек? Шушы акчаларны без кире күмеп куйыйк та, бүтән кеше килсен дә, җирнең яңа казылган икәнен күреп, аларны табып алсынмы? Юк инде, булмас, юк, юк! Без аларны минем өнемә күчерәбез.

— Менә дөрес! Нишләп мин шуны уйлый белмәгәнмен! Кайсысына, беренчесенәме?

— Юк, тәре астындагысына, икенче номерлысына. Беренчесенә күчерергә ярамас — бигрәк аяк асты.

— Ярар, тиздән караңгы да төшә инде, китәргә вакыт.— Индеец Джо аягына торып басты да әле бер тәрәзәгә, әле икенчесенә барып тышка карады.

— Бу китмән белән көрәкне монда кем алып килде икән, син ничек уйлыйсың? — дип сорады ул.— Бәлки алар хәзер дә өске катта яшеренеп яталардыр? Ничек уйлыйсың?

Малайларның тыны кысылды. Индеец Джо пычагына тотынды, беркавым икеләнеп торды да баскычка таба юнәлде. Качарга чолан бар икәнен уйласалар да, малайлар урыннарыннан кузгала алмадылар. Метисның авыр адымы астында баскыч шыгырдап китте. Коточкыч курку малайларны катып калган хәлдән чыгарды һәм алар, катгый карарга килеп, чоланга ташланырга дип торганда гына черегән баскыч тактасының шытырдап сынып, Индеец Джоның егылып төшкәне ишетелде. Ул сүгенә-сүгенә аягына торып басты. Ә аның юлдашы болай диде:

— Нәрсәгә дип менәсең инде анда? Утыралар икән — утыра бирсеннәр! Безнең ни эшебез бар анда! Монда сикереп төшеп бәлагә тарысылары килә икән, рәхим итсеннәр! Чирек сәгатьтән, караңгы төшкәч, безнең артыбыздан чапсыннар — мин анысына да риза. Минемчә, күрсәләр дә, алар безне албасты яисә өрәк дип, яки шуның ише берәр зат дип уйлаганнардыр. Әле дә булса артларына борылып карамыйча чабалардыр.

Джо бераз вакыт мыгырданып маташты да, аннары иптәшенең, вакытны әрәм итмичә, караңгы төшеп җиткәнче юлга җыенырга кирәк, дигән фикере белән килеште. Тиздән алар кыйммәтле сандыкларын алдылар да, өйдән чыгып, елга ягына таба китеп югалдылар.

Том белән Һак ничек кирәк алай аякларына торып бастылар да иркенләп, җиңел сулап куйдылар. Алар бүрәнә ярыгыннан озак итеп тегеләрне күзәтеп тордылар. Артларыннан барыргамы әллә? Юк инде! Муеннарын сындырмыйча гына җиргә төшә алуларына һәм икенче юлдан, тау өсте юлыннан өйләренә таба элдертә алуларына да бик канәгать иде алар. Юлда алар аз сөйләштеләр, чөнки хата җибәргәннәре өчен үзләрен битәрләделәр: ник кирәк булган инде аларга китмән белән көрәкне монда алып килергә? Шулай булмаса, Индеец Джоның башына куркыныч яный дигән фикер килеп тә карамас иде, югыйсә. Ул көмеш белән алтынны, үзенең «үч алу» ниятен тормышка ашырганга хәтле шушында күмеп калдырган булыр иде. Әйләнеп килгәч караса, хәзинәсеннән җилләр искән булыр иде! Нинди үкенеч! Нишләп шушында алып килделәр инде алар китмән белән көрәкләрен!

Әгәр дә «испан» яңадан калада күренә башлап, шәфкатьсез үчен тормышка ашыру чарасын эзләргә тотына калса, алар аның артыннан күзәтеп йөрергә булдылар. Бәлки алар шул рәвешле «икенче номерның» кайда икәнен белә алырлар. Кинәт Томның башына коточкыч фикер килде:

— Үч дигәннән, Һак, ә бәлки ул бездән үч алмакчы буладыр?

— Сөйләмә инде, Том! — диде Һак куркуыннан тын да ала алмыйча.

Бу турыда алар калага кайтып җиткәнче сөйләштеләр һәм, Индеец бәлки башка берәүне күздә тоткандыр, дигән фикергә килделәр, бәлки үчне Томның үзеннән генә алмакчыдыр, чөнки бит судта Том гына мәгълүмат бирде. Куркынычның бер аңа гына янавы Томга һич тынычлык бирмәде. Бергә-бергә җиңелрәк булыр иде, дигән карарга килде ул.

XXVIII бүлек

Бу көннең маҗаралары Томга төн буе тынычлык бирмәде. Төшләре дә аның бик газаплы булды. Дүрт тапкыр ул алам дип кулын сузды һәм, уянып, күңелсез чынбарлыкка әйләнеп кайту белән дүртесендә дә хәзинә юкка чыкты. Иртәгесен таңнан уянып, әле урын өстендә ятканда, кичәге маҗаралар гаҗәеп дәрәҗәдә томанлы, ерак булып күз алдына килде. Шуңа күрә бу хәлләр аңа башка дөньяда яисә бик күптән булгандыр кебек тоелды. Бәлки бу маҗараларны ул төшендә генә күргәндер? Артык күп иде шул андагы алтын — ул хәтле күп алтын өндә була алмас. Томның берьюлы илле доллар да күргәне юк һәм, ярлы гаиләдә туган теләсә кайсы малай кебек, «йөзләр» һәм «меңнәр» турындагы сөйләшү — бары тик сүз генә, андый зур акча гомумән дөньяда булмыйдыр да, дип уйлый иде Том. Берәрсенең йөз доллар саф акчасы булырга мөмкин, дип ул бер генә минутка да фараз итә алмый иде. Хәзинәләрне ничегрәк күз алдына китерәсең, дип сораганда ул аны берәр уч бакыр акчадан һәм елкылдап торган, кулга да тими торган томанлы өемнән гыйбарәт, дип әйтер иде. Әмма күбрәк уйлаган саен аның хәтерендә маҗараның бөтен ваклыклары ачыклана һәм төгәлләнә барды, ахыр чиктә бу хәлләр төш булмагандыр, дигән фикергә килде малай. Моны тизрәк тикшереп ачыкларга кирәк иде. Ул аннан-моннан гына тамак туйдыргандай итте дә Һакны эзләп табу нияте белән өйдән чыгып китте.

Һак яссы төпле көймә читенә утырган да күңелсезләнеп аягын суда болгап утыра иде. Том Һактан берни дә сорашмаска дигән карарга

килде. Кичәге хәлләр турында үзе башласын сүзне. Әгәр дә инде сүз башламый икән, Том чыннан да төш кенә күргән булып чыга.

— Исәнме, Һак!

— Саумы.

Малайлар беразга тынып калдылар.

— Их, Том, әгәр дә без шул каһәр төшкән китмән белән көрәкне агач төбендә калдырсак, акча безнең кулда буласы иде бит! Нинди үкенеч!

— Димәк, бу төш булмаган... юк, төш булмаган шул! Ә мин аның төш кенә булуын теләр идем. Валлаһи менә!

— Нинди төш тагын?

— Кичәгеләрне әйтәм. Мин инде әллә төштә күрдемме дип уйлаган идем.

— Төштә күрми ни! Аяк астында баскычы җимерелеп төшмәсә, күрсәтер иде ул сиңа төшеңне! Минем дә төн буена шул хәерсез сыңар күзле испан төшемә кереп, артымнан куып аптыратты, җәһәннәмгә олаккыры.

— Юк, олакмасын. Без аны табып акчасының эзенә төшәргә тиеш.

— Без аны мәңге таба алмыйбыз. Шуның хәтле күп акча кешенең кулына үз гомерендә бер генә тапкыр килеп керә ала, анда да без аны ычкындырып җибәрдек. Аны яңадан күрә калсам мин мөгаен аягымда да басып тора алмам.

— Соң мин дә инде; шулай да минем аны күрәсем һәм «икенче номерына» хәтле артыннан барасым килә.

— Икенче номер — хикмәтле нәрсә шул. Мин бу турыда уйландым инде, ләкин очына чыга алмадым. Синеңчә ничек, ни булыр икән ул?

— Белмим. Бик болганчык шул... Кара әле, Һак, бәлки ул йорт номерыдыр?

— Бәлки шулайдыр. Хәер, юктыр... юк, билгеле. Кая инде безнең калабызда йорт саннары?

— Шулай шул. Тукта, уйлап карыйм әле... Беләсеңме, бәлки ул берәр трактирдагы бүлмә саныдыр?

— Дөрескә охшаган бу фикерең. Бездә ике генә трактир бар бит, тикшереп чыгарга авыр булмас.

— Шушында көтеп тор, Һак. Мин тиз генә әйләнеп киләм.

Том шундук юкка чыкты. Урамда үзен Һак белән бергә күрүләрен теләми иде ул. Ярты сәгатьләр үтүгә Том әйләнеп килде. Трактирның әйбәтрәк дигәнендәге икенче номерда куптәннән бирле бер яшь адвокат яши икән. Трактирның начаррак дигәнендәге икенче номерында нindider сер бар икән. Трактир хуҗасының малае Томга менә нәрсәләр сөйләп биргән: бу номер гел бикле тора икән, көндезләрен анда беркем керми дә, чыкмый да икән. Мондый сәерлекнең сәбәбен ул аңлата алмаган; бу хәл Томны бераз гына кызыксындырды һәм, озак та уйлап тормастан, ул икенче номерда өрәкләр һәм җеннәр яши булырга тиеш, дигән карарга килде. Үткән төнне анда ут янганын хуҗа малае искәреп калган булган.

— Менә шуларны белдем мин, Һак,— диде Том.— Мөгаен, бу нәкъ шул безгә кирәкле икенче номердыр, дип уйлыйм мин.

— Шулайдыр, күрәсең, Том. Нишлибез соң инде без хәзер?

— Уйлап карыйк әле.

Том шактый озак уйлады һәм, ниһаять, болай диде:

— Менә нәрсә эшләргә кирәк безгә. Бу икенче номерның арткы ишеге трактир белән иске кирпеч складына арасындагы тыкрыкка чыга. Син мөмкин кадәр күбрәк ачкыч табарга тырыш, мин дә түткәйнең бөтен ачкычларын алырмын, һәм без бер караңгы төндә шунда барып әлеге ачкычларны яратырга тырышып карарбыз. Индеец Джо килеп чыкмасын, сак бул. Ул бит, исеңдәдер, калада үч алуның җае чыкмасмы, дигән иде. Күрсәң артыннан бар; әгәр ул шушы икенче номерга кермәсә, димәк, без ялгышканбыз булып чыга.

— Билләһи менә, үземнең генә аның артыннан барасым килми минем!

— Соң төнлә бит ул. Бәлки ул сине күрмәс тә; күргән сурәттә дә шикләнмәс.

— Ярар, әгәр караңгы булса, ул чакта барырмын мин аның артыннан. Белмим инде, белмим... Карап карармын әле.

— Караңгы була калса, мин дә барам, Һак. Белеп булмый бит, үч ала алмый калса, аның монда акчага дип килеп чыгуы бик ихтимал.

— Дөрес, Том, дөрес әйтәсең. Валлаһи дип әйтәм, барырмын мин аның артыннан!

— Шулай диген аны! Тик кара инде, Һак, ялгыша күрмә. Ә мин сиңа ярдәм итәргә тырышырмын, тыныч бул!



XXIX бүлек

Шул ук кичне Том белән Һак бик куркыныч эшкә чыктылар. Кичке тугызларга кадәр алар трактир тирәсендә арлы-бирле йөренделәр: аларның берсе читтән генә трактирга керә торган ишекне күзәтте, икенчесе тыкрыкка чыккан ишектән күзен алмады. Тыкрыкка берәү дә кермәде һәм берәү дә чыкмады; трактирга да испанга охшаган һичкем аяк басмады. Төн аяз булмакчы иде, һәм Том өенә кайтып китте. Әгәр бик караңгы була калса Һак тәрәзә катына килеп мыраууларга тиеш иде; Том, тәрәзәдән чыгып, алар бергә ачкыч яратырга барырга дип килештеләр. Әмма төн һаман шулай якты килеш кала бирде. Һак уникегә хәтле сакта торды һәм шуннан соң гына шикәрдән бушаган мичкә эченә кереп йокларга ятты.

Сишәмбе көнне дә малайларның эшләре пешмәде, чәршәмбе көнне дә. Аның каравы пәнҗешәмбе көнне төн караңгы булды.

Том, түткәенең калай фонарен һәм кирәк була калса дип утны каплар өчен зур сөлгесен алып, вакыты җиткәч өеннән чыгып китте. Ул фонарен Һак куна торган мичкә эченә яшерде, һәм алар икесе бергә сакка бастылар. Ярты төн җитүгә берәр сәгать кала трактир ябылды, һәм аның бөтен утлары сүнде. Тирә-юньдә караңгылык эченә чумды. «Испан» һаман күренмәде. Тыкрыкка берәү дә кермәде һәм берәү дә чыкмады. Бары да яхшы гына бара кебек. Төн дөм караңгы, тынлыкны сирәк кенә булып еракта күк күкрәгән тавыш кына боза.

Том фонарен алып мичкә эчендә килеш ут элдерде, аны әйбәтләп сөлгегә төрде, һәм ике батыр малай караңгылык эчендә трактирга таба якынлаштылар. Һак сакта калды, Том исә кармалана-кармалана тыкрыкка таба китте. Шомлы булып минутлар үтте, Һакка шундый авыр булып куйды, әйтерсең лә, аның өстенә тау-таш өелгән иде. Ул инде тизрәк фонарь уты җемелдәсен иде дип тели башлады; куркыныч булыр иде булуын, аның каравы Томның исән-сау икәнен белер иде. Том караңгыга кереп югалганнан соң инде әллә ничә сәгатьләр үткәндер кебек тоелды. «Мөгаен, ул һушсыз ятадыр, ә бәлки үлгәндер дә. Бәлки куркудан һәм дулкынланудан аның йөрәге ярылгандыр». Тәшвишкә калган Һак үзе дә искәрмичә тыкрыкка якынлашканнан-якынлаша барды; аның күз алдына коточкыч нәрсәләр килде, минут саен ул көтеп торды: менә-менә нидер булыр да, аның җаны атылып чыгар төсле тоелды. Ниндидер афәт якынлашканын сизенеп ул көчкә сулыш алды, йөрәге исә шартларга җитеп ярсып тибә иде.

Кинәт ут елтырап китте, Һакның янынннан ук кебек томырылып Том очып узды.

— Чап! — дип кычкырды ул.

— Тизрәк йөгер!

Кабатлап торасы да юк иде: бер әйтү җитте. Том кабатлап өлгергәнче Һак сәгатенә утыз йә кырык миль тизлек белән чаба иде инде. Каланың түбән очындагы ташландык бойня сарае янына барып җиткәнче малайлар бер дә туктамадылар. Алар сарайга кереп өлгерүгә каты итеп күк күкрәп, яшенле яңгыр коя башлады. Бераз тын алуга Том сөйләргә тотынды:

— И куркыныч та булды соң, Һак! Мин ике ачкычны яратып карадым, бик тә иплəп кенә маташырга тырыштым инде югыйсә, ләкин шундый да нык шыгырдаган тавыш чыкты, минем котым ботыма җитте, куркуымнан тын ала алмый тордым. Ә ачкыч борылмый! Кинәт нишләгәнемне аңышмастан ишек тоткасына ябышуым булды, ишекнең ачылып китүе булды! Ул бөтенләй бикле дә булмаган икән! Атылып барып та кердем, фонаремнан сөлгене тартып та алдым...

— Шуннан? Ниләр күрдең соң, Том?

— Мин әздән генә Индеец Джоның кулына китереп басмадым, һак!

— Булмасны!

— Булмас менә! Идәнгә сузылып яткан да үлгән кешедәй йоклый. Сыңар күзендә әлеге пластырь.

— И Ходаем, нишләдең соң? Уянмадымы?

— Юк, хәтта кыймылдап та карамады. Исерек булгандыр ул. Сөлгемне эләктердем дә син күр дә, мин күр.



— Сөлге минем башыма да килмәс иде.

— Шулай булмый ни! Югалтсам Полли түткәй нишләтә соң мине!

— Карале, Том, сандыкны күрдеңме соң?

— Як-ягыма каранырга вакытым булмады шул, һак. Сандыкны да күрмәдем, тәрене дә. Индеец Джо янында идәндә фәкать шешә белән калай кружка гына күрдем. Аннары ике бәләкәй мичкә белән бик күп шешә бар иде. Хәзер инде аңлыйсыңмы анда нинди рух хөкем сөргәнен?

— Нинди, Том?

— Аракы рухы! Бәлки Аеклык җәмгыятенең башка трактирларында шундый «рухлы» бүлмә бардыр? Син ничек уйлыйсың, һак?

— Бәлки шулайдыр да... Уйлап кына кара инде!.. Карале, Том, Индеец Джо сәрхуш булгач, сандыкны эләктерергә нәкъ вакыты түгелме соң?

— Бар, алып кара!..

Һак сискәнеп куйды.

— Юк... аласым килми...

— Минем дә аласым килми, һак. Аның янында бер генә буш шешә ята иде шул. Ул гына аз. Өчәү булса икән — эш башка булыр иде. Шул чакта ул җитәрлек дәрәҗәдә сәрхуш булыр иде, һәм мин, мөгаен, барган да булыр идем аның янына.

Алар эндәшмичә икәүләп озак итеп уйлаштылар, һәм, ниһаять, Том болай диде:

— Беләсеңме, Һак, әйдә, Индеец Джоның киткәнен тәгаен генә белми торып, гомумән маташмыйбыз. Бигрәк куркыныч бит. Әгәр дә без һәр төнне шулай күзәтсәк, аның урамга чыкканын кайчан да булса бер күрми калмабыз һәм шундук сандыгын эләктерербез...

— Ярар соң. Мин бүген төнлә дә һәм башка төннәрдә дә иртәнгә хәтле сакларга әзер, тик башка мәшәкатьләрен син үз өстеңә ал инде, яме.

— Ярый, шулай итәрмен. Синнән исә бер генә нәрсә сорала: андый-мондый хәл була калса, син Һупер-стрит урамы буйлап чабып килеп минем тәрәзәм катында мияуларсың, әгәр инде мин катырак йоклап киткән булсам бер уч ком алып тәрәзәгә ыргытырсың. Мин шундук сикереп торып йөгереп чыгармын.

— Ярар, шулай итәрмен.

— Менә нәрсә, Һак, яңгыр туктады инде, мин өйгә йөгерәм. Берике сәгатьтән яктыра да башлар. Син анда каравылла инде, яме?

— Саклыйм дигәч, саклыйм инде. Кирәк икән, шул трактир тирәсендә ел буе йөрермен. Көндез йоклыйм, төнлә саклыйм.

— Менә шулай. Ә йоклавын кайда йоклыйсың?

— Бен Роджерсларның печәнлегендә йоклыйм. Ул рөхсәт итә үзе. Аларның негрлары Джейк абзый да кумый мине. Кирәк чагында мин аңа су да ташышам. Кайчакларда сорасаң ашарга да биргәли ул, үзенең дә иписез утырган чагы булмаса. Әйбәт негр ул. Аның алдында борын күтәрмәгәнгә ярата ул мине. Кайчакта мин хәтта аның белән бергә ашыйм да. Тик син бу турыда берәүгә дә сөйләмә. Ачыккач ни генә эшләмәссең, бүтән чак булса мондый нәрсә турында уйлап та карамыйсың инде югыйсә.

— Кирәгең чыкмаса мин сине көндез уятып тормыйм инде, Һак... Кирәксезгә нигә борчырга. Әгәр инде төнлә берәр нәрсә күрә калсаң туп-туры миңа чап һәм мыраула.

XXX бүлек

Җомга көнне иртә белән Томның беренче ишеткән сүзе шатлыклы хәбәр булды: судья Тэтчерның гаиләсе кичә кичтән калага кайтып төшкән. Хәзинә дә, Индеец Джо да икенче планга калды, малайның уйларын шундук Бекки биләп алды. Том шундук кыз янына йөгерде, һәм алар, башка классташлары белән бергә туйганчы куышлы, качышлы уйнадылар. Көн ахырында Томның сөенечләренә тагын бер күңелле хәбәр килеп өстәлде: Бекки, ниһаять, күптән сорап йөргән пикнигын оештырырга әнисен күндергән иде. Кыз шатлыгыннан нишләргә белмәде. Том да бик бәхетле иде, әлбәттә. Кояш баеганчы ук инде чакырулар җибәрелде, һәм бөтен каланың бала-чагасы, сөенечтән нишләргә белмичә, ашыга-кабалана бәйрәмгә әзерләнергә тотынды. Дулкынлануыннан Том төн урталарына хәтле йокыга китә алмады: һак мыраулар дип ул бик өметләнде, чөнки иртәгә пикникта хәзинәне күрсәтеп Беккины һәм аның кунакларын шаккатырмакчы иде. Әмма аның өмете акланмады, бу төнне сигнал булмады.

Ниһаять, иртә белән сәгать уннарда судья Тэтчер өендә шат күңелле, тынгысыз компания җыелды. Барысы да инде әзерләнеп беткән иде. Ул заманнарда өлкәннәр, балаларның пикникларында катнашып, аларның кәефен бозмыйлар иде. Унсигезәр яшьлек ике-өч кыз һәм шулардан бераз гына өлкәнрәк егетләр карамагына балаларны һич тә шикләнмичә калдырырга мөмкин, дип исәпләнелә иде. Мондый бәйрәм шәрәфенә иске генә бер пароход яллардылар, һәм тиздән азыктөлек тутырылган кәрҗиннәр күтәргән күңелле төркем каланың

олы урамы буйлап кузгалып китте. Авыру сәбәпле, Сид бу күңелле бәйрәмдә катнаша алмады; аңа ямансу булмасын дип Мэри да өйдә калды.

Озатканда Тэтчер ханым Беккига болай диде:

— Кайтырга сез, мөгаен, бик соңга калырсыз инде. Бәлки сиңа пристань тирәсендә яши торган берәр иптәш кызыңда кунаргадыр?

— Сюзи Һарперларда куныймы соң?

— Бик әйбәт булыр. Тәртипле бул, кызым, әйбәт кенә йөр!

Урам буйлап барганда Беккига Том болай диде:

— Беләсеңме, Бекки, без менә нәрсә эшләрбез: Джо Һарперларга барганчы, тауга менеп Дуглас ханымда кунарбыз. Аның һәрвакыт диярлек каймаклы туңдырмасы була. Без килгәнгә ул бик тә сөенәчәк, менә күрерсең.

— Ярар, бик әйбәт булыр!

Бекки бер генә минутка уйга калды.

— Әнием ни дияр? — дип сорады ул аннары.

— Ә каян белер соң ул?

Кызый тагын бераз уйланып торды да икеләнеп кенә әйтеп куйды:

— Минемчә, бу бер дә әйбәт булмас...

— Нәрсә инде тагы «әйбәт булмас»! Әниең белмәгәннән ни була? Аңа бит синең исән-сау булуың кирәк. Башына килсә, үзе үк шунда барырга кушкан булыр иде ул сиңа. Билләһи менә!

Якты чырайлы, кунакчыл Дуглас ханым янына барырга бик кызыктылар алар. Туңдырма турындагы хыял һәм Томның үгетләүләре кызның икеләнүен җиңде. Бу кичке программа турында алар берәүгә дә әйтмәскә булдылар. Кинәт кенә Томның башына, Һакның бүген төнлә килеп сигнал бирүе бар бит, дигән уй килде. Бу уй аның көткән бәйрәмен әздән генә бозып ташламады. Шулай да ул Дуглас ханым өендә буласы күңелле кичәне корбан итә алмады. «Ә нигә корбан итәргә әле, дип фикер йөртте ул: әгәр кичә сигнал булмаган икән, ни өчен әле ул нәкъ менә бүген булырга тиеш?»Пароходта күңелле буласы билгеле инде, ә менә хәзинә табыламы,

юкмы — анысы әлегә мәгълүм түгел. Малайларга хас булганча, озак уйлап тормастан, Том көчлерәк вәсвәсәгә биреләсе итте: бу көнне ул акча сандыгы турында уйламаска булды.

Агым буйлап өч миль чамасы түбән төшкәч, пароход урман эчендәге бер алан каршысына килеп туктады. Балалар ярга чыгып таралыштылар һәм урман эче, текә тау битләре тиздән аларның көлешкән, шаулашкан тавышына күмелеп калды. Бөтен уеннарны уйнап бетергәч хәлдән тайган шаян балалар тирләп-пешеп, тамаклары ачып яңадан лагерьга җыелдылар һәм комсызланып өйдән килгән тәмле-тәмле ризыкларга ташландылар. Тәм-томны ашап бәйрәм иткәннән соң алар, җәелеп үскән имән төбенә ял итәргә утырып, гәп кора башладылар. Бераздан кайсыдыр:

— Кемнең мәгарәгә керәсе килә? — дип кычкырып җибәрде.

Барысының да керәсе килә булып чыкты. Шәмнәрен алдылар да шундук бөтен төркемнәре белән тауга үрмәләп менә башладылар. Тау битендәге мәгарәгә керү юлы шактый ук югарыда иде. Аның «А» хәрефен хәтерләткән авыр имән ишеге һәрвакыт ачык тора иде.

Баз кебек салкын кечерәк кенә алгы бүлмәгә килеп керделәр. Аның стеналарын каты известьташтан табигать үзе торгызган. Бу известьташ, салкын тир бәреп чыккандай, тамчылар белән капланган. Шушы караңгылык эченнән якты кояш нурларында коенып яткан яшел үзәнгә карап тору үзе бер шигърият һәм сихри халәт иде. Әмма тиздән тәэссорат йомшара төште, һәм бала-чага элеккечә үк шаяра һәм шуклана башлады. Берәрсе шәмне кабыза да барысы өерләре белән аның өстенә ташланалар һәм шуннан китә көрәш, шәм хуҗасы батырларча каршы торырга тырыша, әмма шәмне бик тиз аның кулыннан бәреп төшерәләр яисә өреп сүндерәләр иде. Караңгыда хахылдап көлгән тавышлар ишетелә, һәм ыгы-зыгы яңадан башлана. Ләкин дөньяда һәр нәрсәнең ахыры була. Процессия әкренләп баш галереядан текә тау бите буйлап аска таба төшә башлады. Бер-бер артлы тезелеп киткән утлар җемелдәшеп кыя ташлы стеналарны өстенә хәтле диярлек тонык кына итеп яктырта. Ул стеналар баш өстендә, сигезме-тугызмы фут бийеклектә, бер-берсенә килеп кушыла. Баш галерея үзе сигез-тугыз

футтан да ары түгел. Адым саен аннан уңга һәм сулга таба тагын да таррак юллар аерылып китә. Мак-Дугада дигән мәгарә берберсе белән кисешә торган, борылып-борылып киткән коридорлар лабиринтыннан гыйбарәт. Бу тарлавыклар, упкыннар, чаткыннар буталчыгында көннәр-төннәр буе йөреп тә, чыгу юлын тапмаска мөмкин дип сөйлиләр. Атлаган саен тирәнгәрәк, җирнең төбенәрәк төшеп тә, һаман шул бер үк нәрсәгә — лабиринт артыннан лабиринтка гына юлыгырга мөмкин. Аларның исә исәбе-саны юк. Мәгарәдәге бөтен юлларны берәү дә белеп бетерә алмый. Мөмкин эш тә түгел бу. Яшьләрнең күбесе аның фәкать бер өлешен генә белә, эчкәрәк керергә берәүнең дә йөрәге җитми. Том Сойер да мәгарәне башкалардан яхшырак белүе белән мактана алмый иде.

Бөтен компания баш галерея буйлап мильнең өчтән дүрте кадәр юл үтте, аннары аерым-аерым парлар һәм төркемнәр як-яктагы юлларга борылып керә башлады, караңгы коридорлар буйлап йөгерешеп, юл чатларында кара-каршы килеп, берсен-берсе куркытыштылар. Мәгарәнең хәтта барысына да таныш булган өлешендә дә берберенне ярты сәгатьләр буена югалтып торырга мөмкин.

Төркем артыннан төркем әкренләп чыгу юлына таба юнәлде; тыннары беткән, баштан-аяк шәм маена һәм кызыл балчыкка буялган шат күңелле балалар табигать кочагында үткәргән көннәреннән бик тә канәгать иделәр. Шунда гына вакытның тиз үтеп, инде караңгы төшәр чак җиткәнен искәреп барысы да гаҗәпләнделәр. Пассажирларны чакырып пароход кыңгыравы инде ярты сәгатьләп суга иде. Маҗаралар тулы көннең шундый рәхәт тәмамлануына барысы да бик канәгать булды. Кечкенә пароход шушы шаушулы йөкне бортына алып елга уртасына йөзеп чыкканда гомернең үткәненә капитаннан башка берәү дә әрнемәде.

Пристань буеннан утларын җемелдәтеп пароход узып киткәндә Һак инде үз постында иде. Пароходтан аңа бернинди дә тавыш ишетелмәде: арып хәлдән тайган яшьләр басынкыланып, юашланып калганнар иде. Һак башта, пристаньга туктамый торган нинди пароход икән бу, дип гаҗәпләнде, аннары аның турында бөтенләй онытты, ул үз эше турында гына уйлады. Болытлар куерып, төн

караңгылана барды. Сәгать унны сукты, тәгәрмәч тавышлары тынып калды. Анда-санда гына елтырап күренгән утлар бер-бер артлы сүнеп бетте, үтүче-сүтүчеләр бөтенләй күренми башлады. Кала йокыга талды, һәм безнең нәни каравылчыбыз тынлык һәм өрәкләр белән бергә-бер торып калды. Сәгать унберне сукты. Трактирдагы утлар да сүнде. Хәзер инде бөтен җир дөм караңгыга чумды, һакка инде бик озак көткәндер сыман тоелды, ләкин бернинди яңалык та булмады. Аның күңеленә шом керде. Нишләп йөри әле ул монда? Чыннан да, нишләп? Әллә барысына да кул селтәп йокларга гына ятаргамы?

Кинәт аның колагына нинди дер тавыш килеп ишетелгәндәй булды, һак шундук сагая калды. Тыкрык ягына чыга торган ишек әкертен генә ябылды. Малай кирпеч склады артына ташланды. Берәр минут үтүгә аның яныннан елт итеп кенә ике кеше үтеп китте; берсенең култык астында нидер бар иде кебек. Мөгаен, сандыктыр! Димәк, хәзинәне каядыр башка җиргә алып китәләр. Инде нишләргә?

Әллә Томны чакырыргамы? Алай итү үзе ахмаклык булыр иде: ул арада бит болар сандыкны әллә кайларга алып китәргә өлгерерләр! Аннары эзләп кара син аларны! Иң яхшысы — артларыннан барып эзләренә төшәргә; мондый караңгыда алар Һакны искәрмәсләр дә. Үз алдына шул рәвешле фикер йөртә-йөртә Һак почмактан чыкты да песи кебек посып тегеләрнең артларыннан китте. Ялан тәпиләре белән тавыш-тынсыз гына басып, ул, тегеләрне күздән югалтмаслык кына ара калдырып, алга таба атлады.

Яр буеннан бара торган урамнан өч квартал үткәч, сукбайлар сулга борылдылар. Кардиф тавына менә торган сукмакка җиткәнче алар турыга гына бардылар, аннары әлеге сукмактан өскә таба менә башладылар. Туктарып тормыйча гына алар Валлий картының ихатасы буеннан үтеп киттеләр һәм, адымнарын да әкренәйтеп тормыйча, һаман өскә таба менүләрен дәвам иттеләр. «Алай, димәк, алар акчаны элек таш чыгарган җиргә күмеп куймакчылар икән»,— дип уйлады Һак. Ләкин сукбайлар анда туктап та тормадылар. Алар һаман югарыга, тауның түбәсенә таба юл тоттылар; аннары, куаклар арасыннан боргаланып-сыргаланып киткән тар сукмакка таба борылып, шундук караңгыда күздән югалдылар. Һак, адымын кызулатып, алар артыннан куып җитә язды, чөнки алар аны барыбер күрмиләр иде. Башта ул йөгерде, аннары, тегеләргә барып төртелүеннән куркып, адымын акрынайтты; тагын бераз барды да туктый төшеп колак салды: бернинди тавыш-тын юк, йөрәгенең дөп-дөп итеп тибүе генә ишетелеп тора. Югарыдан, тау башыннан ябалак ухылдаганы ишетелде — бусы начар фал иде. Ләкин аяк тавышлары ишетелмәде. Шулай ук бары да бетте микәнни? Һак элдертергә генә дип торганда өч-дүрт адымда гына берсе йөткереп куйды. Һакның коты ботына җитте, әмма ул куркуын җиңде, ләкин бөтен тәне бизгәк тоткандагыдай калтыранды, һәм ул баскан җирендә туктап калды; аның җеп өзәрлек тә хәле калмаган иде, ул, егылып китмәгәем, дип курыкты. Хәзер Һак үзенең кайда икәнлеген аңлады: Дуглас дигән тол хатынның ихатасын әйләндереп алган койма буенда, кереп-чыгып йөри торган тишектән дүрт-биш адымнарда гына басып тора иде ул.

«Ярар, гел шушында күмеп куйсыннар, табарга ансатрак булыр»,— дип уйлады малай.

Аннары әкрен генә эндәшкән тавыш — Индеец Джо тавышы ишетелде:

— Шайтан алгыры! Бәлки анда кунаклар бардыр? Төн уртасына хәтле ут яндырмасалар!

— Мин бернинди ут та күрмим.

Бусы — теге, Том белән бергә сихерле өйдә күргән йолкыш тавышы иде. Һакның йөрәге куркудан туктап калгандай булды: менә кемнән үч алырга җыеналар икән алар! Әүвәл малайның башына күтәрелеп карарга дигән уй килде. Аннары ул Дуглас ханымның үзенә карата һәрвакыт мәрхәмәтле булуын исенә төшерде, ә бу кешеләр бәлки аны үтермәкче булалардыр? Димәк, ашыгыч рәвештә Дуглас ханымны кисәтеп куярга кирәк. Юк шул, моны эшләргә Һакның бервакытта да кыюлыгы җитмәячәк: тегеләрнең, аны күреп, тотып алулары ихтимал. Индеец Джо әлеге чит кешенең соңгы сүзләренә җавап биргәләгәнче Һакның башыннан менә шушындыйрак уйлар йөгереп үтте.

— Сиңа яктыны куаклар каплап тора. Мондарак кил... менә шулай. Күренәме хәзер?

— Күренә. Анда чыннан да кунаклар бар икән шул. Ташлап китсәк хәерлерәк булмас микән?

— Ташлап китәргәме! Моннан бөтенләйгә китәргә җыенгандамы? Мондый җай миңа бәлки яңадан мәңге чыкмас! Тагын бер мәртәбә әйтәм: миңа аның акчасы кирәк түгел, анысын үзеңә алырсың. Ләкин бит аның ире рәнҗетте мине... бер генә тапкыр да түгел... ул судья иде, һәм мине сукбайлыкта йөргән өчен төрмәгә утыртты. Ләкин әле ул гына да түгел, юк, болай гына түгел әле ул. Бу кечкенә өлеше генә. Ул мине ярырга кушты! Әйе, төрмә каршысына алып чыгып, негрны ярган кебек, чыбыркы белән ярырга кушты, һәм минем хурлыкка калуымны бөтен кала күрде. Ярды мине, аңлыйсыңмы? Ул миннән хәйләкәррәк булып чыкты: үлеп китте, әмма мин аның хатыныннан үч алачакмын!

— Үтерәсе булма! Ишетәсеңме! Кирәкми!

— Үтерәсе булма?! Әллә мин үтерәм дип әйттемме? Әгәр ире монда булса, аны мин үтергән булыр идем, ләкин хатынын түгел. Хатын-кыздан үч аласың килсә, аны үтереп тә торасы түгел. Гариплэндер генә син аны. Борынын, дуңгызныкы сыман итеп колакларын кисеп ал!

— Ходаем, бу бит инде...

— Синнән сораган кеше юк. Исән чакта телеңне тый! Мин аны караватына бәйләп куям. Кан күп югалтудан үлеп китә икән — монысы инде минем гаеп түгел.Ката бирсен шунда, аның өчен җылап тормам. Ә син, дустым, миңа булышырсың, шуның өчен алып килдем сине монда. Югыйсә, берүзем генә ерып чыга алмам. Карышасың икән — башыңа җитәрмен. Аңладыңмы? Сине үтерәм икән — аны да үтерергә туры киләчәк, аннары инде кем эше икәнен берәү дә белә алмас!

— Шунсыз булмый икән инде, киттек алайса. Әйдә тизрәк... Минем бөтен тәнем калтырый.

— Хәзер үкме? Кунаклар янынамы? Кара аны, сатасы булма мине, ышанып җиттмим әле мин сиңа. Юк, утлары сүнгәнне көтәбез, безнең ашыгасы җир юк.

Үтерү турындагы бу сөйләшүдән дә шомлырак тынлык урнашасын чамалады Һак. Шуңа күрә ул, тын да алмыйча, басар урын эзләп аягын артка таба сузды. Тигезлек сакларга тырышып уңга таба да, сулга таба да тайпылды һәм, егылырга җитеп, чайкалып куйды. Бик сакланып кына һәм шул ук вакытта тәвәккәлләп ул артка таба бер адым атлады.

Кинәт аның аягы астында чыбык шыртлап куйды. Һак тынын кысты да тыңланып туктап калды. Бернинди тавыш әсәре юк, тирә-юньдә тирән тынлык хөкем сөрә иде. Ул ике рәт булып үсеп утырган куаклар арасыннан иләп кенә, тар култыкта борылган корабль сыман итеп, борылды да, тавыш-тынсыз гына икенче якка таба китеп барды. Таш чыгара торган җиргә барып җиткәч ул үзен куркынычсызлыкта дип санады һәм бар көченә чабарга тотынды. Таудан түбән таба йөгерде дә йөгерде һәм, ниһаять, валлийлының ихатасына барып җиткәч, йодрыгы белән өенең ишеген төяргә

тотынды. Тәрәзәдән карт фермерның һәм аның эре бәдәнле улының башы күренде.

— Нинди тавыш бу? Кем анда? Нәрсә кирәк?

— Тизрәк кертегез! Барысын да сөйлим...

— Кем соң син?

— Һаклберри Финн. Тизрәк! Кертегез!

— Һаклберри Финн? Менә сиңа мә! Каршында бар ишекләр дә ачылып китә торган исем түгел лә бу! Шулай да кертегез үзен, егетләр. Карап карыйк, нинди хикмәт булды икән.

— Тик, зинһар өчен, мин сөйләгәнне беркемгә дә әйтмәгез.— Ишек ачып кертүгә Һакның беренче итеп әйткән сүзе шул булды.— Югыйсә миңа көн булмас. Үтерерләр мине! Ләкин ул тол ханым кайчакларда мине жәлли иде. Һәм мин сезгә барын да ничек бар, шулай сөйләмәкче булам. Мин сөйләгәнне берәүгә дә әйтмәскә сүз бирсәгез барын да сөйлим.

— Валлаһи дип әйтәм, юкка түгел бу, аның әйтер сүзе бар,— дип кычкырып җибәрде карт.— Йә, наный, ни беләсең, сөйләп җибәр, без берәүгә дә берни әйтмәбез!

Берничә минутлар үтүгә карт белән аның уллары үзләре белән ышанычлы корал алып тау башына менеп җиткәннәр иде инде. Алар курокларын корып куаклар арасындагы сукмак буйлап иләп кенә алга таба бардылар, Һак аларны шул урынга хәтле озатты да ары барудан баш тартты. Ул бер зур таш артына посып тыңлана башлады. Ялыктыргыч шомлы тынлык урнашты. Кинәт кенә атышкан һәм кемдер кычкырып җибәргән тавыш ишетелде, Һак моның дәвамын көтеп тормады. Ул сикереп торды да артына борылып та карамыйча түбәнгә таба томырылды.



XXXI бүлек



Якшәмбе көнне иртән, таң ата башлау белән, Һак, тау башына менеп, картның ишеген шакыды. Өйдәгеләр барысы да йоклый иде әле, әмма йокылары тыныч түгел, чөнки төнге мазасызлыктан әле тынычланырга өлгермәгәннәр иде.

— Кем бар? — дип сорадылар тәрәзәдән.

Һак куркынган тавыш белән әкрен генә:

— Зинһар өчен, кертегез, мин генә бу, Һак Финн,— диде.

— Бу исем алдында, балакай, безнең ишегебез көндез дә, төнлә дә — һәрвакыт ачык. Рәхим ит әйдә!

Нәни сукбайның колагына бу сүзләр бик тә сәер булып ишетелде. Җанга ятышлы мондый сүзне аның әле бервакытта да ишеткәне юк иде. Үз гомерендә берәрсенең кайчан да булса: «Рәхим ит!»— дип әйткәнен ул хәтерләми. Ишекне шундук ачып җибәрделәр, Һакка урындыктан урын бирделәр, карт белән аның әзмәвердәй уллары ашыгып-ашыгып киенә башлады.

— Йә, дустым, мин синең тамагың бик тә ачтыр дип уйлыйм. Иртәнге аш тиздән, кояш күренүгә үк әзер булыр — иртәнге кайнар аш. Без сине биредә кунарсың дип уйлаган идек.

— Минем котым очты, әлдерттем генә,— диде Һак.— Сез пистолетлардан атарга тотынгач мин җан-фәрманга йөгерә башладым һәм бертуктаусыз өч миль чамасы чаптым. Ә хәзер мин шул эш турында белешергә дип килдем, үле булсалар да, теге шайтаннарга очрамас өчен дип яктырганчы килдем.

— Мескенкәем, эләкте инде сиңа үткән төнне, төсләрең киткән әнә. Алай да... Менә сиңа ятыр урын, тамагыңны туйдыру белән ятып йокла! Юк шул, җаным, алар үлмәде шул, моның өчен без бик тә үкенәбез. Күрәсеңме, ничек килеп чыкты. Синең сөйләвең буенча без аларны кайда эләктерергә икәнен белә идек; без посып кына аларга бик якын килдек — анда, куаклар арасындагы сукмакта, күзеңә төртсәң дә берни күренерлек түгел. Унбишләп адым калуга туктадык һәм кинәт... нәрсә дип уйлыйсың? — килә генә бит төчкерәсем! Тегеләй, болай итеп карыйм төчкермәс өчен, ләкин бернинди чара юк — бар көчемә төчкереп җибәрдем. Пистолетымны әзер тотып алдан бара идем мин. Төчкереп җибәрүем булды, мошенниклар сукмак буйлап куаклар арасына томырылды, куаклар арасында чыбык-чабык шытырт-шытырт итте, мин улларыма: «Атыгыз, егетләр!» — дип кычкырдым. Һәм чыбык-чабык шыртлаган җиргә таба аттым. Егетләр дә атты. Ләкин бәдбәхетләр урман аша табан ялтыраттылар. Минемчә, без аларга тидерә алмадык. Кача башлаганчы алар да безгә таба берәр заряд җибәрделәр, ләкин ядрәләре тими үтте. Бәдбәхетләрнең аяк тавышлары басылуга, эзәрлекләүдән туктап, полицейскийларны аякка бастырдык. Алар, халык җыеп, яр буен камап алдылар; яктыруга шәриф урманны камап алачак, минем улларым да барырга җыена анда. Ул юлбасарларның кыяфәтен белсәк эзләргә ансатрак булыр иде. Ләкин бит син аларны караңгыда аермачык итеп күрә алмагансыңдыр?

— Юк, мин аларны калада ук искәреп алып артларыннан ияреп килдем.

— Бик әйбәт. Әйдә, сөйлә, сөйлә, дустым, кыяфәтләре нинди рәк аларның?

— Аларның берсе — чукрак-телсез карт испан, ул безнең калада бер-ике мәртәбә генә күренде, икенчесе — шундый мескен кыяфәтле, чиркандыргыч чырайлы бер йолкыш...

— Булды, сөйкемлем... Без икесен дә беләбез икән. Бер мәртәбә урманда очраткан идек; алар шул ирсез хатын йорты тирәсендә чуала иде, безне күрүгә үкчәләрен күтәрделәр!.. Ягез, егетләр, тизрәк шәриф янына киттек, ашарга иртәгә дә җитешерсез!

Валлийлының уллары шундук китеп бардылар. Алар ишеккә таба юнәлгәч, Һак алар артыннан омтылды:

— Зинһар өчен, минем аларны күрүем турында әйтә күрмәгез! — дип үтенде.

— Ярар. Теләмисең икән — әйтмибез! Ләкин бит сине моның өчен мактаган гына булырлар иде.

— Юк-юк! Алла хакы өчен, бер сүз дә әйтмәгез!

Егетләр чыгып киткәч Һакка карт болай дип мөрәҗәгать итте:

— Алар да әйтмәс, мин дә әйтмәм. Ләкин нишләп синең моны белдертәсең килми?

һак аңлатып тормады, тик бу адәмнәрнең берсе турында кирәгеннән артык белүен, һәм әлеге адәм моны сизә калса һакны һичшиксез үтерәчәге турында кабат-кабат әйтте.

Карт тагын бер мәртәбә серне сакларга вәгъдә итте; ләкин болай дип сорады:

— Алар артыннан күзәтергә ничек башыңа килде соң синең, дустым? Шикле күренделәрме әллә алар сиңа, ничегрәк булды ул?

Җайлырак җавап эзләп, һак эндәшмичә торды. Ниһаять, болай диде:

— Беләсезме, мин үзем дә бит сукбай, һәрхәлдә, барысы да шулай ди, һәм моңа каршы мин бер сүз дә әйтә алмыйм. Менә шулай кайвакыт мин төннәрен йокламыйм, урамнар буйлап йөрим һәм, ничек тә булса яңача яши башларга иде, дип хыялланам. Менә үткән төнне дә шулай булды. Йокыга китә алмыйча яттым-яттым да, шундый хәлләр турында уйланып, урам буйлап йөрдем. Ә вакыт инде төн урталары иде. «Аеклык» трактиры янындагы иске кирпеч склады буеннан үтеп барам шулай, стена буена бастым да уйланып торам... Кинәт күрәм — шушы ике кеше минем яннымнан йөгереп үтеп баралар, култык асларына нидер кыстырганнар. Мөгаен, урланган әйберләр, дип уйладым мин. Берсе тарта иде, күрәсең, икенчесе дә тәмәкесен кабызырга уйлады булса кирәк, шулай итеп алар миннән бер-ике адымда гына туктап калдылар. Сигара уты йөзләрен яктыртты, һәм мин чал бакенбардлы һәм күзенә пластырь куелган озын буйлысының чукрак-телсез испан икәнен таныдым. Икенчесе — әлеге сытык чырайлы йолкыш албасты иде.

— Сигара яктысында аларның сәләмәсенә хәтле күрә алдыңмы?

һак бер генә минутка каушап калды.

— Белмим дә инде, ничек итеп күрә алганмындыр...

— Шуннан? Алар китеп бардылар, ә син?..

— Ә мин алар артыннан... әйе... Шулай килеп чыкты инде, ниятләрен беләсем килде. Мин аларны тол ханым ихатасы янына хәтле күзәтеп бардым. Шунда мин караңгыда посып тыңлап тордым: теге, сәләмә киемлесе ханымны яклый, испан исә, мин аның

бөтен йөзен гариплəндерен, ямьсезлəп бетерəм, дип каргана... Соң бит инде мин боларны сезгə сөйлəгəн идем...

— Ничек инде!.. Чукрак-телсез сөйлəшəмени?

Һак тагын да коточкыч хата ясады. «Испан»ның кем икəне картның башына да килмəсен дип Һак бөтен көчен куйды, ə теле аны барыбер уңайсыз хəлдə калдырды. Ул ничек тə булса җаен табарга тырышты, лəкин карт аннан күзен дə алмады, Һак исə ялганына кереп батканнан-бата барды. Ахыр чиктə карт болай диде:

— Кара əле, сөйкемлем, курыкма син миннəн. Мин синең башыңдагы бер генə чəч бөртегеңə дə ягылмам. Юк, киресенчə, мин сине яклармын... Әйе, якалармын! Ул испан чукрак-телсез түгел бит, син моны үзең ялгыш ычкындырдың, хəзер инде моны төзəтеп булмый. Бу испан турында син нидер белəсең, лəкин əйтергə телəмисең. Юкка син миңа ышанмыйсың. Әйт дөресен, саттмыйм бит мин сине.

Һак картның намуслы күзлəренə карап алды, аннары аңа таба иелде дə колагына:

— Испан түгел ул, Индеец Джо ул! — дип пышылдады.

Валлий карт əздəн генə урындыгыннан егылып төшмичə калды.

— Хəзер менə мəсьəлə ачыкланды. Хəзер менə аңлашыла. Син кисеп алынасы колаклар-борыннар турында сөйлəгəндə мин моны син үзең генə, болай, матурлык өчен генə уйлап чыгаргансыңдыр дигəн идем, чөнки ак тəнле кеше шуның төсле итеп үч алмый. Әмма индеец! Монысы инде бөтенлəй башка мəсьəлə.

Иртəнге ашны ашаганда əңгəмəне дəвам иттерделəр, һəм шунда, сүз арасында, карт, кайтып китəр алдыннан фонарь кабызып, уллары белəн бергə койма тирəсендə кан эзлəре-фəлəн юкмы икəнлеген караганлыкларын, кан таплары булмавын, əмма бер төенчек табуларын əйтте.

— Нинди төенчек?

Әгəр сүз яшен булса да, Һакның агарынган иреннəреннəн ул шулкадəр зур тизлек белəн атылып чыкмаган булыр иде. Аның күзлəре түгəрəклəнде, тыны кысылды, һəм ул, җавап көтеп, картка текəлде. Валлий карты аңа таба өч... биш... ун секунд буена карап торды һəм аннары болай дип җавап бирде:

— Угры кораллары салынган төенчек... Ләкин сиңа ни булды?

Һак урындык аркасына сөялде, тирән итеп сулыш алды, әйтеп бетергесез сөенү хисе тойды. Валлий карты берникадәр вакыт аңа таба бик җитди итеп, кызыксыну белән карап утырды.

— Әйе, бер бәйләм караклар коралы. Бу хәбәр сине бик нык тынычландырды кебек. Ләкин нидән курыктың соң син? Синеңчә, без нәрсә табарга тиеш идек соң?

Һакны стенага терәделәр. Карт аннан сынаулы күзләрен алмады. Берәр төрле җавап уйлап табар өчен малай дөньяда ни генә бирмәс иде, әмма аның башына берни дә килмәде, картның сынаулы карашы исә аның җанына һаман тирәнрәк үтеп керә барды. Сүзләрне үлчәп торыр ара булмады, Һак, тәвәккәлләп, көчкә генә ишетелерлек итеп лепелдәгәндәй итте:

— Мин сезне... якшәмбе мәктәбе өчен дәреслекләр тапкансыздыр дип уйлаган идем,— диде. Җавап бик мәгънәсез килеп чыкты әлбәттә.

Бичара малайның бик тә күңеле төшкән иде, һәм ул елмая да алмады, карт исә шундый да күңелле итеп, шаулатып шаркылдап җибәрде ки, хәтта аның бөтен гәүдәсе чайкалды, һәм, ниһаять, туйганчы шаркылдаганнан соң ул, шушы хәтле сәламәт көлү — кесәңдәге акчаңа бәрабәр, диде, чөнки ул доктор өчен расход чыгарудан коткара, диде.

— Бичара! — дип өстәде ул.— Син шундый хәлсезләнгәнсең, төсләрең киткән... синең, мөгаен, бер дә кәефең юктыр. Шуңа күрә юк-барны лыгырдыйсыңдыр. Ярый, үтәр әле. Ял итәрсең, йокы туйдырырсың... рәтләнерсең.

Шундый тинтәккә калып, урынсыз хафалануы белән картта шик тудыруы турында уйларга да гарьләнә иде Һак, югыйсә явызларның сөйләшүеннән ул аларның төенчегендә бернинди дә хәзинә юклыгын аңлаган иде инде. Хәер, ул бит аның юравы гына иде, аермачык итеп белмәде ич ул аны. Менә ни өчен табылдык турында сүз чыгу аны шулай дулкынландырды.

Әмма, гомумән алганда, болай килеп чыгуына ул шат иде. Һәрхәлдә, табылдык төендә хәзинә юклыгын ул хәзер тәгаен белә иде.

Димәк, бары да әйбәт һәм бернинди югалту да юк. Әйе, эшләр әлегә шактый әйбәт сыман тоела: теге сандык, күрәсең, һаман да икенче номерда кала бирәдер, явызларның икесен дә бүген тотып төрмәгә утыртып куярлар, һәм шушы төнне үк Том белән бергә Һак бернинди мәшәкатьсез теге алтынны кулга төшерер.

Алар ашап туеп кына торганда ишек шакыдылар, Һак тиз генә качу ягын карады, чөнки үзенең төнге вакыйгаларга катнашы барын кемнең дә булса белүен ул һич кенә дә теләми иде. Валлийлыга ияреп өйгә берничә ханым белән әфәнде, шул исәптән Дуглас ханым да килеп керде. Карт шунда тау башында шәһәр кешеләренең төнге вакыйга булган урынны карап йөргәнен искәрде. Димәк, хәбәр инде таралып та өлгергән.

Килгән кешеләргә төнге вакыйга турында сөйләп бирергә туры килде. Үзенең тормышын коткарып калган өчен тол хатын картка рәхмәтләр укырга тотынды.

— Бер сүз дә әйтәсе булмагыз, ханым-әфәнде! Миңа һәм минем улларыма караганда икенче бер кешегә сез ныграк бурычлы, ләкин ул миңа үзенең исемен әйтергә рөхсәт итми. Әгәр ул булмаса, анда бару безнең башыбызга да килеп карыйсы түгел иде.

Бу сүзләр шундый да нык кызыксыну тудырды ки, хәтта төп вакыйга да икенче планга чигенде. Ләкин валлийлы карт кунакларның кызыксынуын гына арттырды, үзе исә серне чишмәде. Шунлыктан боларның кызыксынуы тиздән бөтен шәһәргә таралды. Әлеге вакыйга турында тәгәлрәк белгәч тол ханым болай диде:

— Мин караватымда укып яткан җирдән йоклап киткәнмен һәм бик тыныч кына йоклаганмын. Нишләп соң сез мине кереп уятмадыгыз?

— Кирәге юк дип санадык,— дип җавап бирде валлийлы.— Без болай дип уйладык: бәдбәхетләрнең кире әйләнеп килүе икеле — чөнки алар коралсыз калганнар һәм ишекне вата алмаячаклар иде. Ә сезне ник уятырга? Үтергәнче куркытыр өченме? Шуның өстенә, минем өч негрым сезнең йортыгыз янында иртәнгә кадәр каравыл торды. Менә хәзер генә әйләнеп кайттылар.

Аннары яңа кешеләр килде, һәм карт ике сәгать буена үзенең хикәясен кабатлап торырга мәҗбүр булды.

Каникул булу сәбәпле бу иртәдә якшәмбе мәктәбендә гадәттәге укулар юк иде, шулай булса да, барысы да иртүк чиркәүгә җыелды. Бөтен җирдә гел шул төнге мәхшәр турында гына сөйләделәр. Полициянең әле җинаятьчеләр эзенә төшә алмаганын барысы да белә иде инде. Вәгазь укылып беткәннән соң судья Тэтчерның хатыны халык белән бергә чыгу юлына таба юнәлгән Һарпер ханым артыннан куып җитте.

— Нәрсә, безнең Бекки сездә көн буе йоклар микәнни? — диде ул.— Хәер, мин аның бик нык арыйсын белә идем инде...

— Бекки дисезме?

— Әйе. (Куркынган караш.) Әллә ул сездә кунмадымы?

— Юк.

Тэтчер ханымның төсе китте, ул эскәмиягә барып утырды. Нәкъ шул вакытта иптәш хатыны белән ни турындадыр бик күңелле итеп сөйләшә-сөйләшә Полли түткәй узып бара иде.

— Исәнмесез, Тэтчер ханым! — диде Полли түткәй.— Хәерле иртә, Һарпер ханым! Минем малай тагын югалды бит әле. Күрәсең, бу төнне ул сездә... яисә сездә... йоклагандыр. ...Ә хәзер чиркәүгә керергә дә куркадыр — белә үзенә эләгәсен.

Тэтчер сизелер-сизелмәс кенә башын чайкады, һәм аның тагы да ныграк төсе китте.

— Бездә булмады ул,— диде Һарпер ханым, үзе дә борчыла башлап.

Полли түткәйнең йөзендә аермачык шомлану билгеләре чагылды.

— Бүген иртән син минем Томны күрмәдеңме, Джо Һарпер? — дип сорады ул.

— Юк.

— Соңгы тапкыр син аны кайчан күрдең?

Джо исенә төшерергә тырышып карады, ләкин аермачык кына әйтә алмады. Чиркәүдән чыгып килүчеләр тукталып калдылар, йөзләрдә борчылу билгеләре чагылды. Балаларга һәм кече укытучыларга сораулар яудырдылар. Кире әйләнеп кайтканда Бекки белән

Томның пароходта булу-булмавын берәү дә искәрмәгән икән: бик караңгы иде бит; барысы да җыелып беткәнме, дип тикшереп карарга берәүнең дә башына килмәгән. Һияять, яшь егетләрдән берсе, бәлки алар мәгарәдә калганнардыр, дигән сүз ычкындырды. Шулай диюгә Тэтчер ханым һушы китеп егылды, Полли түткәй кулларын уа-уа үкереп җылап җибәрде.

Шомлы хәбәр телдән-телгә, төркемнән-төркемгә, урамнан-урамга күчте. Биш минуттан инде бөтен кыңгыраулар чыңлады, бөтен кала аякка басты. Кардиф тавында булган вакыйга шундук бик кечерәеп калды, талаучылар турында шундук оныттылар. Атларны йөгәнләделәр, бәйләп куелган җирдән көймәләрне чиштеләр. Шомлы ачыш булуына ярты сәгать тә үтмәде, ике йөзләгән кеше инде елга буйлап һәм коры җир буйлап мәгарәгә таба юл тотты.

Кала үлеп беткәнгә охшап, бушап калды. Көн буена хатын-кызлар, юатырга тырышып, Полли түткәй белән Тэтчер ханымның хәлен белешеп тордылар: барысы да алар белән бергә җылашты — шуннан да яхшырак юату чарасын таба алмадылар. Төн буена ялкып бетеп, кала халкы хәбәр көтте. Һияять, иртәнгә таба, яктылык сирпи башлауга, мәгарәдән берничә генә сүздән торган хәбәр килде, анда: «Тагын шәм һәм азык-төлек җибәрегез!» — диелгән иде. Хәсрәттән Тэтчер ханым белән Полли түткәй акылдан шаша яздылар. Судья Тэтчер әледән-әле мәгарәдән, өметегезне өзмәгез, дип әйтергә кеше җибәрә торды, әмма аның ул сүзләре генә ханымнарны юата алмады.

Икенче көнне таңда шәм маена һәм кызыл балчыкка буялып беткән Валлий карты өенә әйләнеп кайтты, һак исә кичә ул яткырган урын өстендә кызышып саташып ята иде. Врачлар барысы да мәгарәгә киткәнлектән, авыруны карарга Дуглас ханым алынды. Ханым аның өчен хәленнән килгәннең барысын да эшләргә булды, чөнки яхшымы-яманмы, малай барыбер — Аллаһы Тәгалә бар иткән бер зат, дип фикер йөртте ул. Һакның үзенең игелекле сыйфатлары бар, диде Валлий карты, һәм тол ханым аның фикере белән тулысынча килеште:

— Сез хаклы. Аллаһы Тәгалә бар иткән һәр нәрсәдә аның үзенең тамгасы бар, ул бар иткән һәр нәрсәдә аның игелеге бар.

Көн урталарына таба арган төркемнәр шәһәргә әйләнеп кайта башлады, әмма хәлләре булганнар эзләнүләрен дәвам итә бирделәр. Мәгарәдә моңарчы берәү дә барып җитә алмаган иң ерак галереяларны дә айкап чыгулары турында яңа хәбәрләр килә торды; бөтен ярыкларны, барлык караңгы почмакларны актармакчы булдылар, коридор лабиринтларында еракта анда-санда утлар күренгәндәй булды, караңгы кичү юллары буйлап әледән-әле кычкырышкан һәм пистолетлардан атышкан тавышларның еракта тонык кына кайтавазы килеп ишетелде. Бер урында, мәгарәнең гадәттә туристлар кереп йөри торган җиреннән еракта, ташка шәм сөреме белән «Бекки һәм Том» дип язылган сүзләргә барып юлыктылар, шунда ук эрегән шәм маена буялып беткән тасма кисәге дә табылды. Тэтчер ханым тасманы танып алуга шундук үксеп җылап җибәрде. Һәлакәткә дучар булган сөекле баласының соңгы истәлеге бит бу! Ана өчен шуннан да кадерлерәк әйбернең булуы мөмкин түгел, чөнки Бекки өстенә һич көтмәгәндә коточкыч үлем килгәндә бу тасма — аның янында булган соңгы әйбере. Эзләгән вакытта еракта ниндидер җемелдәгән ут күреп, егермешәр кеше сөенә-сөенә кычкырышып, шунда таба ташлана, әмма, аһ, юк шул, алар иртәрәк сөенә: анда югалган балалар түгел, балаларны эзләп йөрүчеләр булып чыга, дип тә сөйләде кайберәүләр.

Шулай итеп, дәһшәтле өч көн белән шомлы өч төн үтеп китте. Эчпошыргыч озын булып сәгатьләр сузылды. Бөтен шәһәр ниндидер бер өметсез халәттә катып калды. Бөтенесенең кулыннан эш төште. Хәтта «Аеклык» трактирының хуҗасы яшереп спиртлы эчемлекләр сата икән, дигән очраклы ачыш та, никадәр генә коточкыч булмасын, берәүне дә шаккатыра алмады. Авырып яткан Һак, беркадәр вакытка рәтләнә төшкәч, куркыныч хәбәр ишетүдән шөлли-шөлли генә, «Аеклык» трактирыннан ни дә булса тапмадылармы, дип сорады.

— Таптылар,— дип җавап бирде аңа тол ханым.

Һак аңа таба сәер итеп карап алды да ятагында сикереп куйды.

— Нәрсә? Ни таптылар?

— Исерткеч эчемлекләр. Аракы... Трактир хәзер ябык. Ят әйдә, балакай, югыйсә котымны алдың.

— Тагын бер генә, бер генә сүз әйтегез, зинһар өчен! Кем тапты? Том Сойермы?

Ханымның күз яшьләре ага иде.

— Тынычлан, сөйкемлем, тынычлан, әйттем бит инде: сиңа күп сөйләшергә ярамый. Син бик каты авырыйсың...

«Димәк, аракыдан башка берни дә тапмаганнар, чөнки акча тапсалар бөтен калада мәхшәр кубар иде. Димәк, хәзинә мәңге бакыйга, мәңгелеккә юкка чыккан... Ә бу ханым ник җылый соң әле? Сәер хәл! Ник җыларга тиеш соң әле ул?..»

Шушы уйлар элем-чалым гына булып кыймылдаштылар Һакның күңелендә, һәм ул шундый да хәлсезләнде ки, хәтта үзе дә сизмәстән йокыга талды.

«Менә йоклап та китте, бичара,— дип сөйләнде ханым үз алдына.— Том Сойер тапкан, имеш! Бар инде хәзер, табып кара син Том Сойерыңны! Том Сойерны эзләп табарга өметләнгән һәм аны эзләп табарга көче, кодрәте җитәрдәй кешеләр аз калды инде хәзер».



XXXII бүлек

Хәзер инде Том белән Беккига әйләнеп кайтыйк, карап багыйк, нишләделәр икән алар пикникта. Башта алар мәгарәнең ян-якларындагы караңгы коридорлар буйлап йөрделәр, башкалар белән бергә инде мәгарәнең моңарчы таныш булган «Кунак бүлмәсе», «Чиркәү», «Галәветдин сарае» кебек беркадәр купшы исемнәр йөрткән могҗизаларын карап хозурландылар. Аннары барысы да качышлы уйнарга тотынды, Бекки белән Том да бу күңелле уенга бик тырышып катнаштылар, әмма тора-бара ул аларны туйдырды; шәмнәрен югары тотып, кыя ташлы диварларга сөрем белән язылган болганчык саннарны, исемнәрне, адресларны, әйтемнәрне укый-укый алар икәүләп бормаланып киткән галерея буйлап атладылар.

Сөйләшә-сөйләшә алга таба барып, стеналарда инде язулар да булмаган җиргә килеп чыгуларын алар сизми дә калдылар. Салынып төшкән таш астына шәм сөреме белән исемнәрен яздылар да тагын алга таба атладылар. Тиздән алар кечерәк кенә бер елга буена барып чыктылар, ул елга кыяның чыгып торган урыныннан йөзләрчә еллар буена ага-ага үзе белән бергә известьлы юшкын ташып ялтыравыклы таштан бөдрәләнеп, челтәрләнеп киткән Ниагара барлыкка китергән. Чандыр гәүдәле Том шарлавык артындагы тау ярыгы аша үтте дә Беккиның күңелен күрер өчен шарлавыкны шәм яктысы белән яктыртты. Шунда ул шарлавыкның ике стена арасында тар гына ярыктагы текә баскыч сыманрак бер нәрсәне каплап торганын искәрде. Шул мәлдә малайны ачышлар ясап шөһрәт казану

теләге белән алды. Бекки дә аның фикеренә кушылды, һәм алар, юлдан язмас өчен шәм сөреме белән тамга сала-сала, ачышларга таба юл тоттылар. Бормаланып киткән коридор буйлап әле уңга, әле сул якка таба бик озак атлый торгач, алар җир асты серләренә кергәннән-керә бардылар, тагын бер билге ясап, өскә чыккач сөйләп бирердәй яңа могҗиза эзли-эзли, тагын читкә борылдылар. Бер урында алар зур гына мәгарәгә юлыктылар, анда кеше боты сыман юан, елтырап торган сталактитлар түшәмнән салынып тора иде. Матурлыгына соклана-соклана алар мәгарәне тирәли әйләнеп чыктылар. Аңа бик күп коридорлар килеп тоташа иде, балалар шул коридорларның берсе буйлап киттеләр һәм тиздән алда гаҗәеп бер матур чишмә күрделәр. Чишмәнең төбен елкылдап торган кристаллар каплаган иде. Чишмә ниндидер бер биек мәгарәнең үзәгеннән агып ята; мәгарәнең стеналарын фантастик колонналар терәтеп тора. Ул колонналар, күп гасырлар буена су тамып тору нәтиҗәсендә, зур сталактитларның сталагмитлар белән кушылуыннан барлыкка килгән. Бу мәгарәнең гөмбәзе астында зур-зур бәйләмнәр булып ярканатлар асылынып тора, ул бәйләмнәрнең берсендә-берсендә меңәр ярканат булгандыр. Яктылыктан куркып, алар ачы итеп чыелдап утка таба ташландылар. Том аларның гадәтләрен яхшы белә һәм бу хәшәрәтләр тарафыннан нинди куркыныч янаганын аңлый иде. Ул Беккины кулыннан эләктереп алды да аның белән бергә коридорларның берсенә таба йөгерде.

Ярканатлар әле балалар артыннан бик озак куа бардылар, әмма качаклар минут саен юлда очрап торган яңадан-яңа коридорларга борылып-борылып керделәр һәм шулай итеп, ниһаять, явыз хәшәрәтләрдән качып котылдылар. Тиздән Том бер җир асты күле күреп алды, күлнең яр сызыклары тонык булып еракка, караңгылыкка китеп югала иде. Малай күлнең ярларын тикшереп-өйрәнеп карамакчы иде, әмма ул башта ял итеп алу мәслихәтрәк булыр дигән карарга килде. Җир астының үле тынлыгы шунда беренче тапкыр үзенең дымлы, ябышкак кулын балаларның күңеленә сузды.

— Ай, мин искәрмәгәнмен дә...— диде Бекки,— тавышлар күптән ишетелми түгелме соң инде?

— Шулай шул, Бекки! Уйлап кына кара — без бит алардан аста, бик тирәндә; мин хәтта кайсы якка — көньяккамы яки төньяккамы — кергәнебезне дә белмим... Без монда тавышларны ишетә дә алмыйбыз.

Бекки борчыла калды:

— Без монда күптәннәнме инде, Том? Кире әйләнеп кайтсак яхшырак булыр иде.

— Әйе, дөрес, иң яхшысы шул булыр. Мөгаен...

— Син юлны таба аласыңмы соң, Том? Монда юлларның барысы да кыек-мыек киткән, минем башым бөтенләй буталып бетте.

— Менә бу ярканатлар булмаса, юлны мин, мөгаен, таба алыр идем. Җилпенеп шәмебезне сүндерә калсалар, без нишләрбез? Әйдә, алар яныннан үтмәс өчен бүтән юл эзләп карыйк.

— Яхшы, ләкин адаша күрмик. Югыйсә коточкыч хәл булыр.

Һәм кызчык шул рәхимсез хәл турындагы уйлардан калтыранып куйды.

Алар ниндидер бер коридорга борылып керделәр дә озак кына сөйләшми бардылар; таныш кебек тоелмас микән дип, һәр кичүгә текәлеп карадылар; ләкин юк, бу — таныш булмаган урыннар иде. Һәр яңа юлны тикшергән саен Бекки нинди дә булса юанырлык чалым күрергә теләп Томның йөзенә текәлеп карады, ләкин малай аны:

— Юк, монысы әле безнең юл түгел, ләкин син борчылма, вакыты җиткәч табарбыз,— дип юата торды.

Әмма уңышсызлыкка очраган саен Том өметсезлеккә бирелә барды; тиздән ул, үзләренә кирәкле юлны табарына ышангандай, ничек туры килде шулай уңга-сулга борыла башлады. Ул элеккечә: «Әйдә, рәте чыгар әле», диде, ләкин аның күңелен авыр уйлар борчый иде, тавышында да элекке гамьсезлек ишетелмәде, әйтерсең лә ул «әйдә, рәте чыгар әле», дими, ә «бетте баш», дия иде. Бекки куркудан үлә язып аңа таба сыенды, бар көченә күз яшьләрен тыярга тырышты, әмма алар ага да ага иде. Һиһаять кыз:

— Ярканатлар булса булыр, әйдә, шул юлыбыздан кире китик, Том,— диде.— Болай без һаман ныграк адаша барабыз.

Том туктый төште.

— Тыңла әле,— диде ул.

Тирә-якта тирән тынлык хөкем сөрде, хәтта аларның сулыш алганнары да ишетелә иде. Том кычкырып куйды. Аның тавышы буш гөмбәзләр эчендә бик озак яңгырап торды да, ниндидер мыскыллы хахылдауга охшап, еракка китеп югалды.

— Ой, Том, кирәкми, шундый куркыныч! — диде Бекки.

— Куркыныч булса да кычкыру кирәк, Бекки, бәлки алар безнең тавышны ишетерләр.

Ул тагы бер мәртәбә кычкырды.

Аның «бәлки» дигән сүзендә иблис хахылдавына караганда да җан өшеткечрәк дәһшәт ишетелде: бу инде бернинди өмет тә калмаган дигән сүз иде. Балалар колак салып тыңлап тордылар, әмма берәү дә тавыш бирмәде. Том кире борылып адымын тизләтте. Ләкин аның бөтен хәрәкәтендәге һәм карашындагы икеләнү Беккига коточкыч хакыйкатьне ачты: Том ярканатлы теге мәгарәне дә таба алмый иде.

— Их, Том, нишләп соң син билгеләр ясамадың?

— Шундый ахмак инде мин, Бекки! Шул ук юл белән кире кайтырбыз дигән уй минем башыма да килмәде. Мин юлны таба алмыйм. Барысы да буталып бетте...

— Беттек бит, Том! Харап булдык бит! Без инде моннан бервакытта да чыга алмабыз! Их, нишләп соң без башкалардан аерылып киттек?!

Бекки җиргә утырды да шундый каты итеп җылап җибәрде. Том хәтта аптырап калды: Бекки аңа хәзер үк үлеп китәр яисә акылдан шашар кебек тоелды. Ул кызның янына утырды да иңбашыннан кочып алды. Бекки йөзен аның күкрәгенә яшерде һәм бөтен куркуларын, бөтен соңга калган үкенүләрен сөйли-сөйли үксеп-үксеп җылады, ерактагы кайтаваз исә аның үксүләрен зәһәрле хахылдауга әйләндерде. Том аны, көчеңне сакла, өметеңне өзмә, дип үгетләде, кыз исә, бу минем хәлемнән килми инде, дип җавап бирде. Сине бит мин шундый хәлгә төшердем, дип Том үзен-үзе әрли, битәрли башлады, менә шул нәрсә инде кызга барыннан да әйбәтрәк тәэсир итте. Кызчык көчен җыеп Том кая барса шунда барачагын әйтте,

тик ул үзен битәрләмәсен генә, чөнки Беккиның да гаебе аныкыннан ким түгел.

Алар тагын кузгалып киттеләр — болай, аяклары атлаган якка таба гына, бер урында туктап тормас өчен генә... Тиздән аларның йөрәгендә тагын өмет чаткылары кабынгандай булды, моның өчен сәбәп чыгудан түгел, чөнки өметнең үзенчәлеге шундый: яшь чакта һәм әле кыенлыклар кичерергә күнекмәгән чакта кешедә өмет кабат-кабат яңара торган була.

Бара торгач Беккиның шәмен Том өреп сүндерде. Мондый саклык күп нәрсәне аңлата иде. Тел белән әйтеп торуның кирәге булмады, Бекки болай да барысын аңлады, һәм аның тагы рухы төште. Томның кесәсендә бөтен бер шәм һәм тагын өч-дүрт шәм төбе барлыгын Бекки белә иде, шуңа карамастан малай сак булуны кирәк тапты.

Арыганлык үзен сиздерә башлады; шулай да балалар бирешмәскә тырыштылар: һәр минут кадерле чакта болай тик утырудан алар бик курка иде; кая булса да бару ничек тә яхшырак, чөнки аның котылуга китерүе дә мөмкин, тик утыру исә — үзеңне үлемгә дучар итү дигән сүз.

Ниһаять, Беккиның хәлсез аяклары алга таба атлаудан баш тартты. Ул ял итәргә утырды. Том аның янына урнашты, һәм алар өй турында, анда калган туганнары, дуслары турында, уңайлы урынҗир һәм, иң әһәмиятлесе — кояш хакында, якты дөнья хакында сөйләшә башладылар. Бекки җылап утырды. Том аны тынычландырырлык берәр нәрсә уйлап табарга тырышты, әмма бөтен тынычландырырдай сүзләр инде көчен югалткан, күп тапкырлар кабатланганга күрә алар инде мәрхәмәтсез мыскыллау булып яңгырый иде. Бекки, хәлдән тайганлыктан каныга башлап, йокыга ук китеп барды. Том бу хәлгә сөенде генә. Ул кызның сулып калган йөзенә карап утырды: матур төшләр тәэсирендәдер инде — баланың йөзенә гадәттәге тынычлык билгеләре урнашты, иреннәрендә елмаю чагылды. Аның йөзенә чыккан хафасызлык Томны бераз тынычландыра төште, һәм аның күңелендәге әрнү әз-әзләп басыла башлады. Ул уйлары белән үткәннәргә китеп барды һәм шул хатирәләр эчендә

кайнашты. Үткәндәге хатирәләре белән Том шулкадәр мавыккан иде ки, хәтта Беккиның, уянып, көлеп җибәргәнен дә искәрмәде. Ләкин көлү шундук кызның иреннәрендә катып калды һәм авыр ыңгырашу белән алышынды.

— Ничек йоклап киткәнмен мин! Мәңге дә уянмас идем. Юк, юк, Том, мин ялгыш әйттем. Алай итеп карама миңа! Мондый сүзне мин башка бервакытта да әйтмәм.

— Синең йоклап алуыңа мин бик сөенәм, Бекки: син ял иттең, һәм без хәзер һичшиксез юлны табарбыз, дип уйлыйм мин, менә күрерсең!

— Карап карыйк, Том; ә мин төшемдә шундый гүзәл ил күрдем! Без тиздән шунда барып җитәрбез кебек тоела миңа.

— Бәлки җитәрбез, ә бәлки җитмәбез дә. Йә, Бекки, алай моңсу итеп карама әле. Тагын эзләп карыйк!

Балалар торып бастылар да җитәкләшкән килеш кузгалып киттеләр, ләкин инде алар бернәрсәгә дә өмет багламыйлар иде. Алар мәгарәдә күпме вакыт булуларын чамаларга тырышып карадылар — берничә көннәрдер, ә бәлки атналардыр кебек тоелды аларга, хәлбуки алай булырга тиеш түгел иде, чөнки бит әле шәмнәре дә янып бетмәгән.

Вакыт бик күп үткән иде инде, ә күпме икәнен алар үзләре дә белмәделәр. Әкрен генә барып, тамчы тамуына колак салырга кирәк, диде Том. Эчәрдәй су чыганагы табарга кирәк иде. Тиздән алар чыннан да кечкенә генә бер инешкә барып юлыктылар, һәм Том ял итеп алырга тәкъдим итте. Икесе дә үлеп арыган булсалар да, Бекки, тагын бераз барырга мөмкин бит әле, диган булды. Томның баш тартуына кыз аптырады — ни өчен икәнен ул аңламады. Алар җайлап ял итәргә утырдылар. Том, бер кисәк кызыл балчык алып, шуның белән шәмне стенага ябыштырып куйды. Балаларны тагын күңелсез уйлар биләп алды, беркадәр алар сүзсез утырдылар. Бекки беренче булып сүз башлады:

— Минем бик ашыйсым килә, Том.

Том кесәсеннән нидер чыгарды.

— Исеңдәме? — диде ул.

Бекки хәлсез генә елмаеп куйды:

— Бу безнең пикник бәлеше бит, Том...

— Әйе шул... Ләкин мин аның мичкә кадәр булуын теләр идем, чөнки безнең башка азыгыбыз юк.

— Бер-беребезне төштә күрер өчен соңыннан мендәр астына салып ятармын, дип мин аны пикник вакытында яшереп куйган идем. Өлкәннәр шулай итә бит. Әмма бу безнең соңгы...

Бекки сүзен әйтеп бетермәде. Том бәлешне урталай бүлде. Бекки үз өлешен бик тәмләп ашап бетерде. Том исә авыз гына итте. Бәлеш артыннан эчеп куярга салкын су теләсәң нихәтле иде.

Берникадәр вакыттан соң Бекки ары китәргә дип тәкъдим ясады. Том җавап кайтармады, бераз эндәшми торганнан соң:

— Бекки, минем әйтәсе сүземне тыныч кына тыңлый алырсыңмы? — дип сорады.

Беккиның төсе китте, шулай да ул, мөгаен, тыңлый алырмындыр, дип җавап кайтарды.

— Менә шул, Бекки, безгә шушында, эчәргә су булган җирдә калырга туры килер... Бу инде безнең соңгы шәм төбе.

Бекки туйганчы күз яшьләрен агызды. Том аны будыра алганча юатырга тырышты. Ниһаять, Бекки:

— Том! — дип эндәшеп куйды.

— Нәрсә, Бекки?

— Исләренә төшәрбез дә, алар безне эзләргә тотынырлар.

— Әйе, әлбәттә эзләрләр.

— Бәлки алар безне эзли дә торганнардыр инде, Том?

— Әйе, мөгаен шулайдыр. Яхшы булыр иде ул.

— Безнең юклыкны кайчан искәрделәр икән алар? Син ничек уйлыйсың, Том?

— Пароходка әйләнеп кайткачтыр дип уйлыйм.

— Ул чакта бик караңгы булгандыр инде, Том. Безнең юклыкны күрделәр микәнни?

— Анысын белмим, әмма калганнар барысы да өйләренә әйләнеп кайткач, синең әниең шундук тавыш куптарыр, дип уйлыйм.

Беккиның куркынган чыраен күреп, Том үзенең хата җибәргәнлеген аңлады. Бекки бу төнне иптәш кызында кунарга тиеш иде, һәм аны бүген өйдә көтмиләр иде. Тынып калган балалар уйга баттылар. Кинәт Бекки яңадан үкереп җыларга тотынды, һәм Том аның да башына коточкыч уй килгәнлеген аңлады: Тэтчер ханым Беккиның Һарпер ханымнарда кунмаганлыгын якшәмбе көннең яртысы үтеп киткәч кенә беләчәк бит.

Балалар соңгы шәм төпчегеннән күзләрен алмадылар, аның рәхимсез рәвештә эреп бетә барганын күзәттеләр; ниһаять, ярты дюйм озынлыгындагы пилтә генә калды; хәлсез генә янган ут әле кабынып, әле нечкә генә төтен агымы чыгарып сүнә төшеп куйды, бер генә секундка тынып торгандай итте — аннары лып сүнеп, дөм караңгылык инде.

Бекки аңына килеп Томның кочагында җылап утыруын искәргәндә күпме вакыт үткәнен аларның берсе дә әйтә алмый иде. Алар икесе дә бик озак вакытлар буена нindидер бер йокылы-уяулы хәлдә булып, шул халәттән айнуларын һәм үзләрен бик тә бәхетсез итеп тоюларын гына беләләр иде. Том, хәзер якшәмбе көн, ә бәлки инде дүшәмбедер, диде. Ул Беккины сөйләштерергә тырышып карады, әмма кызчыкны кайгы баскан һәм ул инде бер нәрсәгә дә өметләнми иде. Аларның юклыгын әллә кайчан искәреп, хәзер инде эзлиләр булырга тиеш, дип ышандырырга тырышты аны Том. Ул бар көченә кычкырачак — тавышны ишетеп бәлки кем дә булса килер. Малай кычкырып куйды; ләкин караңгыда кайтаваз шундый куркыныч итеп яңгырады ки, хәтта ул яңадан кычкырып та маташмады.

Сәгатьләр артыннан сәгатьләр уза торды, һәм бичара тоткыннарны яңадан ачлык газаплый башлады. Томның үз өлешенә тигән бәлештән калган бәләкәй генә кисәге бар иде; алар аны икесенә бүлеп кабып йоттылар, ләкин аннан аларның ашыйсы килүләре көчәйгән кебек кенә булды.

Кинәт Том:

— Ш-ш-ш! Ишеттеңме? — дип сорады.

Икесе дә тыннарын да алмыйча тыңланырга тотындылар. Кемдер кайдадыр бик еракта кычкырган кебек булды. Том шундук җавап

бирде һәм, Беккины кулыннан алып, коридор буйлап кармаланып кына тавыш килгән якка таба бара башлады. Бераздан ул тагын колак салып тыңлады: тавыш тагын ишетелгәндәй булды һәм якында-рак сыман тоелды.

— Шулар бу! — диде Том.— Монда киләләр! Әйдә, Бекки, тизрәк, хәзер котылабыз!

Әсирләрнең сөенече чигенә җитте, ләкин ашыгырга ярамый иде, чөнки алар атлаган саен чокыр-чакырга очрадылар. Тиздән алар шундый бер чокыр буена килеп туктадылар — моннан бер адым да алга атларлык түгел иде. Бу чокырның тирәнлеге өч фут та, йөз фут та булуы ихтимал, ләкин барыбер аның аркылы үтеп китәрлек түгел иде. Том йөзтүбән сузылып ятты да булдыра алган хәтле чокырның кырыеннан аска таба салынды. Чокырның төбенә аның буе җитми иде. Килеп алганнарын шушында көтеп торырга туры килә. Алар тагын колак салдылар, ләкин тавышлар торган саен тонырак булып, ерактанрак ишетелә барды... Бер-ике минуттан инде тавыш бөтенләй тынды. Нинди үкенеч! Том тамагы карлыкканчы кычкырды, ләкин аңа җавап бирүче булмады. Шулай да ул Беккины үгетләп, өметләндереп карады; шомланып көтә торгач, инде гасырлар үткәндер кебек тоела башлады, тавышлар исә башка ишетелмәде.

Балалар кармалана-кармалана баягы кечкенә елга буена кире кайттылар. Сәгать артыннан сәгать үтте; балалар яңадан йокыга талдылар, аннары тамаклары ачып яңадан уяндылар. Том, инде хәзер сишәмбе җиткәндер, дип уйлады.

Кинәт аның башына бер уй килде. Шушы тирәдән берничә якка коридор сузылып киткән иде. Эшсезлектән һәм хәсрәттән иза чиккәнче шуларны тикшереп чыксаң, яхшырак булмасмы? Малай кесәсеннән очыргыч бавын алып кыя ташның чыгып торган очына бәйләде дә бауны сүтә-сүтә Бекки белән бергә алга таба атлады. Ләкин егермеләп адым үтүгә коридор бетте, аннары упкын башланып китә иде. Том тезләнде дә аска таба төшә торган стенаны капшый башлады, аннары, почмакның теге ягын капшап, бераз гына уңгарак тартылды, нәкъ менә шул мәлдә егермеләп адымда кыя

артыннан шәм тоткан бер кул күренде! Том сөенеченнән кычкырып җибәрде, ләкин кул артыннан кеше үзе дә күренде — Индеец Джо иде ул! Том тораташ булып катты, ул урыныннан да кузгала алмады, һәм шул минутта «испан» табан ялтыратып күздән югалгач, әйтеп бетергесез шатланды. Томның тавышын танымавы, судтагы таныклаулары өчен үтермәве малайга бик сәер тоелды; кайтаваз аның тавышын үзгәрткәндер, күрәсең. «Хикмәт нәкъ менә шунда булырга тиеш»,— дип фикер йөртте малай. Куркудан ул бөтенләй хәлсезләнеп калды. Су буена кире әйләнеп кайтырга көче җитсә индеец Джога очрамас өчен яңадан беркая да китмәскә булды. «Испан»ны күргәнен ул Беккига әйтеп тормады, болай гына, берәр файдасы булмасмы дип кенә кычкырдым, дип аңлатты.

Әмма ачлык һәм чарасызлык ахыр чиктә барлык куркулардан да көчлерәк булып чыкты. Кизләү буенда эчпошарлык озак итеп көткәннән соң балалар яңадан йокыга талдылар, һәм аларның кәефләре яңадан үзгәрде. Балалар ашыйсылары килүдән тәмам газапланып уянып киттеләр. Томга инде чәршәмбе җиткәндер, яисә пәнҗешәмбе, яисә хәтта җомга йә шимбә көн җиткәндер дә, аларны эзләүдән дә туктаганнардыр кебек тоелды. Ул тагын бер коридорны карап киләсе итте. Малайны инде хәзер бернинди Индеец Джолар да, бернинди хәвеф-хәтәр дә куркытмас кебек тоелды. Бекки бик тә хәлсезләнгән иде. Кызны сагыш һәм күңел төшенкелеге биләп алды, аның берничек тә күңелен күтәреп булырлык түгел иде. Ул шушында калып үлмәкче дә иде, инде хәзер көтәргә дә күп калмады, дип. Әгәр тели икән, ул Томга бау буйлап коридорларны тикшереп килергә дә рөхсәт итте, тик еш-еш кире әйләнеп килеп аның белән сөйләшкәләп торуын үтенде; аннары иң куркыныч минутлар килеп җиткәч үзенең янында китмичә, соңгы сулышка кадәр Беккиның кулын тотып торырга Томнан вәгъдә бирдертте.

Том Беккины үбеп алды, шунда аның тамагына төер утырды, һәм ул мәгарәдән чыгу юлын табып, үзләрен эзләүчеләрне каршыларга өметләнүен әйтте. Аннары ул бавын кулына алды да дүрт аякланып бер коридор буйлап үрмәләп китте. Үзе исә шул вакытта үләр дәрәҗәдә ач иде, һәм, озакламый һәлак булачакмын, дип уйлап сагышлана иде.

XXXIII бүлек

Сишәмбе җитте, көн инде кичке эңгер-меңгер белән алышынган иде. Питерсберг каласы һаман әле югалган балалар турында кайгырып күз яше агызуында булды. Шулай итеп балалар табылмады. Алар рухына бөтен җәмәгатьчелек чиркәүдә гыйбадәт кылды. Бик күпләр өйләрендә дә алар рухына чын күңелдән дога кылдылар, ләкин һәмишә мәгарәдән хәбәр-хәтер булмады. Кала кешеләренең күбесе эзләүләрен ташлап үзләренең көндәлек эшләрен дәвам иттерделәр, балаларны инде мөгаен табып та булмастыр, диештеләр. Тэтчер ханым бик авыр хәлдә иде һәм һәрвакыт диярлек саташып ятты. Ничек итеп кызына эндәшкәнен тыңлап торсаң йөрәкләр әрни, диләр, башын мендәреннән күтәреп эндәшә дә озак итеп тыңлап тора, аннары ыңгырашып башын кире мендәренә төшерә, диләр. Полли түткәй дә тирән сагышка бирелде, һәм аның агара башлаган чәче бөтенләй көмеш төскә керде. Сишәмбе көнне кич кала кара кайгыга батып, бернигә дә өметләнмичә йокыга ятты.

Төн уртасында кинәт ярсынып бер-бер артлы кыңгыраулар кага башлады, һәм минут эчендә урамнар аннан-моннан гына киенгән тантана итүче кешеләр белән тулды, алар бар көчләренә: «Чыгыгыз! Чык! Балалар табылды! Табылды!» — дип кычкыра-кычкыра чаң кактылар, быргы кычкырттылар, табага суктылар. Бөтен каланы тутырып кешеләр елгага таба, Том белән Бекки каршысына агылды. Том белән Беккины кала кешеләре сиртмәле арбага утыртып алып кайтып киләләр иде; каршылаучылар аларны уратып алдылар

да тантаналы рәвештә «Ура!» кычкыра-кычкыра иң олы урам буйлап өйләренә кадәр озата бардылар.

Калада утлар кабынды, берәү дә яңадан йокларга ятып тормады; кала кешеләренең тормышында бу иң тантаналы төн булды. Кешеләр берсе артыннан икенчесе судья Тэтчер өенә агылды. Алар, коткарылган балаларны кочаклап үбеп, Тэтчер ханымның кулын кысып нидер әйтергә тырыштылар, ләкин сүзләрен әйтә алмыйча күз яшьләренә төелеп чыгып китә бирделәр.

Полли түткәйнең куанычы эченә сыймый иде, Тэтчер ханым да шул дәрәҗәдә үк бәхетле диярлек иде. Бәхете түгәрәк булсын өчен аңа бер нәрсә: мәгарәгә җибәрелгән чапкынның бу сөенечле хәбәрне тизрәк аның иренә илтеп ирештерүе җитми иде. Том диванга менеп яткан җиреннән үзләре күргән гаҗәеп маҗараларны әллә ничә тапкыр арттыра-арттыра, бизи-бизи игътибар белән тыңлаучыларга сөйләп ята иде. Ниһаять, ул, Беккины калдырып, чыгу юлын эзләргә китүе турында сөйләде: бавы җитеп, ике галереяны үтүе турында; бавы тартылганчы сузып, өченче галереяга таба борылуы турында һәм кире борылырга уйлаганда гына алда, еракта, ниндидер көн яктысына охшаган яктылык күренеп китүе турында. Шуннан соң Том бавын алып ыргыта да үрмәләп яктылыкка таба китә, мәгарә авызына башын тыгып караса, аста җәелеп аккан Миссисипи елгасын күрә! Бу вакытта төн заманы булса, алдагы көн яктылыгын ул күрмәгән һәм коридор буйлап ары китеп әлеге тишеккә барып җитә алмаган булыр иде. Әйләнеп Бекки янына кайткач ул аңа бу шатлыклы яңалык турында сөйләп бирә, Бекки исә үзен яңадан мондый юк-бар белән борчымавын үтенә, чөнки инде аның бөтенләй хәле беткән, ул инде барыбер тиздән үләчәк һәм хәтта үләргә тели дә икән. Малай ничек итеп Беккины үгетләүләре турында сөйли; зәңгәр яктылык сирпелеп торган урынга барып җиткәч сөенечтән аның ничек итеп әздән генә үлми калуы турында; үзенең ничек итеп мәгарә авызыннан чыгуы һәм ничек итеп Беккины чыгаруы турында да сөйли; ничек итеп яр буенда утырулары һәм сөенечтән жылаулары хакында да; яннарыннан көймәдә ниндидер кешеләр үтеп баруын күргәч, аларга кычкырып, үзләренең яңа гына

мәгарәдән чыгулары һәм бик каты ашыйсылары килүен әйтә. Елга буйлап барганда мәгарә биредән биш чакрымда булганга башта тегеләр Томның сүзенә ышанмыйлар. Аннары алар балаларны үзләренең көймәләренә алалар, ниндидер бер йортка барып җиткәч тамакларын туйдырып, ике-өч сәгатькә йокларга яткыралар, ә инде караңгы төшкәч өйләренә кайтарып куялар.

Таң алдыннан, мәгарә эченнән бау буйлап барып, бер төркем ярдәмчеләре белән бергә судья Тэтчерны эзләп табалар һәм аларга да сөенечле хәбәрне тапшыралар.

Өч көн, өч төн буена мәгарәдә адашып йөрүләр һәм ачлык кичерүләр Том белән Бекки өчен эзсез генә үтмәгән булып чыкты. Алар, үзләрен бик арыган һәм ватылган хис итеп, чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрен көн буена урын өстендә ятып үткәрделәр, Том пәнҗешәмбе көнне кыска гына вакытка урыныннан торып йөрде, җомга көнне исә калага чыгып керде, ә шимбә көнне инде ул бөтенләй сәламәт иде. Аның каравы, Бекки якшәмбе көнгә хәтле бүлмәсеннән чыга алмады, һәм аның кыяфәте дә каты авыру кичергән кешенекенә охшаган иде.

Һакның авырып ятуы турында ишеткәч, Том җомга көнне керен аның хәлен белмәкче иде, ләкин малайны дустының йокы бүлмәсенә кертмәделәр; шимбә белән якшәмбе көнне дә ул дусты янына керә алмады. Аннары гына инде аны Һак янына көн саен кертә башладылар, ләкин үзеңнең маҗараларың турында сөйләп Һакны дулкынландырма дип, алдан ук кисәтеп куйдылар. Том тел язмасын дип, Дуглас ханым хәтта аны үзе күзәтеп торды. Өйдә ул Кардиф тавындагы вакыйга турында да, шулай ук кичү тирәсеннән «сукбай»ның гәүдәсен табулары турында да ишетте: күрәсең, качып барганда батып үлгәндер инде.

Мәгарәдән чыгуларына ике атналар үтүгә Том Һак белән күрешергә дип китте. Ул инде хәзер хәл җыйган һәм теләсә нинди дулкынландыргыч яңалыкны тыңлый алырлык иде. Том исә үзендәге яңалыклар дусты өчен кызыклы булыр дип исәпләде. Юл уңаеннан ул Беккиның хәлен белергә дип судья Тэтчерларга да кагылды. Судья белән аның таныш-белешләре Томга сүз каттылар һәм тагын да

мәгарәгә керергә исәбең юкмы, дип шаярттылар; Том, каршы булмас идем, дип җавап бирде. Аның шул сүзенә каршы судья болай диде:

— Син генә шундыйдыр дип уйламыйм мин, Том,— диде ул.— Әмма без чарасын күрдек инде. Моннан соң ул мәгарәдә берәү дә адашмас.

— Нишләп?

— Чөнки моннан ике атна элек мин андагы олы ишекне калай белән тышлатып, өч кат йозак белән бикләп куярга куштым. Ә ачкычлары миндә саклана.

Том ак җәймә кебек агарынып китте.

— Ни булды сиңа, балакаем? Тизрәк, берәрегез стакан белән су китерегез!

Су алып килеп Томның йөзенә бөркеделәр.

— Менә, ниһаять, аңыңа килдең. Ни булды сиңа, Том?

— Тэтчер әфәнде, мәгарәдә Индеец Джо калган иде бит!



XXXIV бүлек

Берничә минуттан бу хәбәр бөтен калага таралды, дистәгә якын көймәгә төялеп шундук Мак-Дугала мәгарәсенә таба юл тоттылар. Озак та үтми алар артыннан пассажирлар төягән кечкенә пароход та кузгалып китте. Том Сойер судья Тэтчер белән бер көймәдә барды.

Мәгарәгә керә торган ишекне ачкач эңгер-меңгердә элем-чалым гына булып аянычлы бер тамаша күз алдында пәйда булды. Индеец Джо, йөзен ишек ярыгына куйган килеш җирдә үлеп ята, әйтерсең лә ул иректе, сөенечле якты дөньядан соңгы минутына кадәр сагышлы күзләрен ала алмаган.

Томның күңеле нечкәреп китте, чөнки бу бәхетсез кешенең нилә кичергәнен ул үз тәҗрибәсеннән чыгып аңлый иде. Аның күңелендә кызгану хисе уянды, шулай да Том гаҗәеп бер җиңеллек һәм азатлык хисе кичерде. Судта җөрьәт итеп канэчкеч метиска каршы чыгыш ясаганнан бирле курку хисе үзен ничек изгәнен Том хәзер генә чын-чынлап аңлады.

Индеец Джоның янәшәсендә урталай сынган ау пычагы ята. Ишекнең авыр тупсасы кискәләнеп, чапкаланып беткән, бу эшне индеец, күрәсең, бик авырлык белән башкарган. Әмма аның хезмәте әрәмгә киткән, чөнки тышкы яктагы таш бусаганы Индеец Джо берни дә эшләтә алмаган. Пычагы гына шартлап сынган. Хәтта ки таш бусага булмаган суретта дә аның хезмәте әрәмгә китәр иде, чөнки Индеец Джо тупсаны кисеп чыгарса да, ишек астына сыя

алмас иде. Һәм ул шуны белгән дә; тупсаны вакыт узсын өчен һәм тинтерәп беткән башын эшләтер өчен генә юнган. Стена ярыкларында гадәттә туристлар кыстырып калдырган унлап шәм төпчеге була торган иде; хәзер монда бер генә шәм төпчеге дә юк. Бичара әсир аларны табып алып ашап бетергән булырга тиеш. Аннан башка ул әле берничә ярканат та тотып ашаган, җирдә аларның тырнаклары гына аунап ята иде. Бу бәхетсез кеше ачтан үлеп киткән ахрысы.

Мәгарәгә керүче юл янында гасырлар буена шушы төштә асылынып торган сталактиттан тамган тамчылардан өскә таба сталагмит өелеп үскән. Бичара тоткын сталагмитның очын сындырып алган да шуның өстенә бер таш куйган, ташны чокып ул савыт сыман сай гына бер нәрсә ясаган. Шул чокырга өч минут саен бер тамчы су тамып, егерме дүрт сәгать буена анда кечерәк аш кашыгы кадәрле су җыела. Бу тамчы пирамидалар төзелгән чакта да тама торган булган, Трояны җимергәндә дә, Римга нигез ташлары салынганда да, Гайсә пәйгамбәрне тәрегә кадаклаганда да, басып алучы Вилһелм Бөек Британияне оештырганда да тамган, Христофор Колумб диңгез буйлап сәяхәткә чыгып киткәндә дә, Лексингтон янындагы бәрелеш хакындагы хәбәр килеп ирешкән чакта да тамган алар. Ул тамчылар хәзер дә тама, әлеге вакыйгалар тарихның кичәге көненә әйләнгәч тә, үткәннең эңгер-меңгеренә, караңгы төненә кереп чумгач та тамачак әле. Шулай ук дөньядагы бөтен нәрсәнең дә үз максаты һәм вазифасы бар микәнни? Шушы адәмбөҗәк үзенең сусавын бассын өчен бу тамчы озак биш мең ел буена шулай сабыр гына тамды микәнни? Яңадан берәр ун мең ел узгач аңа тагын берәр яңа вазифа үтәргә туры килмәс микән? Барыбер түгелмени соң? Бәхетсез метисның кадерле су тамчыларын җыяр өчен ташны чокып савыт ясавына күп, бик күп еллар үткән булса да, туристлар хәзергәчә Мак-Дугала мәгарәсенең могҗизасын күрергә килгәндә кубесенчә шушы дулкынландыргыч ташка һәм әкрен генә эреп төшә торган шул тамчыга карыйлар. Индеец Джоның кәсәсе мәгарә могҗизалары исемлегендә беренче урында тора, хәтта «Галәветдин сарае» да аның белән тиңләшә алмый.

Индеец Джоны мәгарәгә керү юлына күмделәр; аны соңгы юлга озатырга кешеләр көймәләргә утырып та, повозкалар белән дә килделәр; алар тирә-юньдәге калалардан, поселоклардан, фермалардан — җидешәр чакрымдагы җирләрдән җыелдылар. Алар үзләре белән балачагаларын да, төрле ашау-эчү әйберләре дә алып килгәннәр, соңыннан алар «Индеец Джоны җирләү — аны җәзалап үтерүне күргән кебек үк канәгатьләнү хисе бирде», дип сөйләделәр. Аны җирләү бер эшне — губернатор исеменә үтенеч язып, Индеец Джоны ярлыкау турындагы эшне карауны туктатты. Бу үтенечкә бик күп кеше кул куйды, бик күп митинглар булды, кешеләр күз яшьләре агыздылар һәм төчеләнеп купшы сүзләр сөйләделәр, җылак ханымнардан торган комитет оешты. Алар матәм киеме киеп губернаторга барырга һәм аннан, өстенә йөкләнгән бурычын онытып, үзен шәфкатьле ишәк итеп күрсәтүен үтенергә тиеш иделәр. Индеец Джо шәһәрнең биш кешесен үтергән дип сөйлиләр, шуннан ни булган? Әгәр ул иблиснең үзе булса да, барыбер аны ярлыкау турында сорап кул куючы селәгәйләр һәм губернатордан шул турыда җылый-җылый үтенүчеләр табылыр иде.

Җирләгәннең икенче көнендә Том, бер мөһим эш турында сөйләшәсе бар, дип, Һакны бер аулак урынга алып китте. Һак инде Томның маҗаралары турында Валлий картыннан һәм Дуглас ханымнан ишетеп белгән иде; ләкин Том, син әле алардан барысын да белә алмадың, бер бик мөһим нәрсә турында белмәдең әле, менә шул турыда сөйләшеп аласы бар, диде. Һакның чырае караңгыланып китте.

— Ни турында икәнен беләм инде мин,— диде ул.— Син икенче номерда булгансың, һәм анда вискидан башка бер ни дә тапмагансың. Миңа моны берәү дә әйтмәде, ләкин виски турында ишеткәч, син икәнен аңладым; акчаны таба алмавыңны белдем. Том, ул акчаларны безнең гел күрәсебез юк, дип уйлыйм мин.

— Нишләп алай дисең, Һак, мин бит трактир хуҗасын чакмадым. Без пикникка киткән чакта шимбә көнне дә ишеге ачык булганын үзең беләсең бит. Ул төнне син сакларга тиеш идең бит, шуны хәтерләмисеңмени?

— Их, шулай бит әле! Чыннан да, аннан бирле бер ел гомер үткәндер кебек. Индеец Джоның эзенә төшеп, шуның артыннан Дуглас ханым йортына хәтле барган төнне иде бит бу!

— Әллә син аның эзенә төштеңме?

— Әйе шул, тик син шаулама. Индеец Джоның дус-ишләре булмый калмас, мөгаен, шуларның этлек эшләүләрен бик теләп тормыйм әле! Мин булмасам ул, мөгаен, Техаска барып җитәр иде инде.

Шуннан соң Һак сер итеп кенә Томганиләр булганын сөйләп бирде. Валлий картыннан Том әле шуларның яртысын гына белгән булган икән.

— Менә шул,— диде Һак яңадан төп мәсьәләгә кайтып,— икенче номердан мичкәсе белән вискины алып чыккан кеше акчасын да алып киткәндер; һәрхәлдә ул акча хәзер безнең өчен юк инде, Том!

— Ул акчаның икенче номерда булганы да юк, Һак!

— Ничек инде?

Һаклберри иптәшенең күзенә сынап карады.

— Том, әллә син яңадан ул акчаның эзенә төштеңме?

— Мәгарәдә ул, Һак!

Һакның күзләре очкынланып китте.

— Кабатла әле сүзеңне, Том!

— Акча мәгарәдә!

— Чын индеец сүземе, Том? Шаяртасыңмы, чынлап әйтәсеңме?

— Чынлап, Һак, бу хәтле дә чын сүзне минем әле берәүгә дә әйткәнем юк. Минем белән бергә барып акчаны алырга булышасың киләме?

— Килми димени! Тик анда тамгалар буйлап кына барырга кирәк, югыйсә адашуыбыз бар.

— Юк, Һак, моның безгә бернинди мәшәкате дә булмаячак.

— Менә ичмасам! Тик акча анда дип син каян алып әйтәсең?

— Тукта, урынына барып ирешергә генә ирек бир! Әгәр дә без аны таба алмасак, барабанымны да бирәм үзеңә, башка бөтен әйберемне дә. Валлаһи менә!

— Ярар алайса, килештек. Кайчан барабыз?

— Теләсәң хәзер үк. Хәлең бармы соң?

— Керә торган җирдән еракмы соң ул? Минем инде аягыма басканыма өч-дүрт көн бар, әкренләп йөрим хәзер, тик берәр мильдән ары китеп булмас шул.

— Кеше йөри торган юлдан барсаң биш мильләп булыр. Мин кеше йөрми торган кыскарак юлын беләм. Көймә белән алып барырмын мин сине. Барганда да, кайтканда да үзем ишәрмен. Сиңа бармак кыймылдатырга да туры килмәс.

— Әйдә, хәзер үк барыйк.

— Әйдә. Ипи белән ит, төрепкәләрне алырбыз, ике-өч капчык, очырткычка тага торган берәр йомгак бау, аннары теге күкертле шырпы дип атала торган әлеге яңа нәрсәне дә алырбыз. Шуны алмаганыма мин кат-кат үкендем.

Төш вакыты үтүгә малайлар каядыр киткән берәүнең көймәсен чишеп алдылар да юлга чыктылар. Мәгарәгә керә торган урыннан берничә миль читкә киткәч Том болай диде:

— Әнә шул текә ярны күрәсеңме? Мәгарәгә керә торган җирдән башлап шушында хәтле ник бер йорт яисә агач склады булсын! Куаклар да гел бертөрле. Әнә теге ишелеп төшкән җирдәге ак тапны күрәсеңме? Менә шул инде мин билгеләгән тамга. Хәзер без яр буена килеп туктыйбыз.

Алар көймәдән ярга чыктылар.

— Йә, Һак, син басып торган җирдән керү юлына кадәр ара кармак сабы буе гына. Үзең табып кара әле шуны!

Һак бөтен тирә-юньне актарып бетерде, ләкин мәгарәгә керү юлын таба алмады. Том горурланып куе сарылач куаклары арасына барып керде.

— Менә ул! — диде Том.— Кара әле, Һак, мондый җайлы тишекне бүтән җирдән таба да алмыйсың. Тик син шаулама гына. Мин бит инде күптәннән юлбасар булырга җыенам, җайлы урыны гына юк иде, ул урынны каян эзләргә икәне дә мәгълүм түгел иде. Хәзер инде, андый урыны табылгач, без берәүгә дә әйтмәбез. Джо Һарпер белән Бен Роджерска әйтсәк кенә инде — шайкасы да кирәк бит әле аның уен булгач! Том Сойер шайкасы — шәп бит, Һак, әйеме?

— Ярыйсы инде, Том. Кемне талярбыз соң без?

— Кемне дип инде! Засада ясарбыз — шулай итәләр аны.

— Кешеләр дә үтерербезме?

— Юк инде, гел түгел. Йолым түләгәнче әсирләрне мәгарәдә асрарбыз.

— Нәрсә соң ул йолым?

— Акча. Аларны таныш-белешләреннән бурычка акча алырга мәҗбүр итәсең; әгәр инде алар бер елдан соң да түләмәсәләр, үтерәсең. Бөтен кеше дә шулай итә. Хатын-кызларны гына үтермиләр. Хатын-кызларны үтерүен үтермиләр, аларны әсирлектә тоталар. Алар үзләре һәрвакыт чибәр булалар, үзләре бай һәм коточкыч куркак булалар. Аларның сәгатьләрен, әйберләрен талап аласың, тик алар белән итагатьле итеп, башыңнан эшләпәңне салып сөйләшергә кирәк. Юлбасарлардан да итагатьлерәк кеше юк инде ул дөньяда, бу турыда син теләсә кайсы китаптан укып белә аласың. Аннары ул хатын-кызлар шундук сиңа гашыйк булалар, мәгарәдә бер-ике атна яшәп карагач җылый да башлыйлар һәм гомумән инде аннары аларны аннан куып та чыгара алмыйсың. Куып чыгара калсаң, инде әйләнәләр-тулганалар да тагын кире әйләнеп киләләр. Бөтен китапларда да шулай дип язылган.

— Менә ичмасам шәп, Том. Пират булуга караганда болай шәбрәк, дип уйлыйм мин.

— Шулай шул! Өйгә дә якынрак, цирк та янәшәдә генә һәм башкалар.

Инде барысы да әзер иде, һәм малайлар өн эченә керә башладылар. Том алдан шуышты. Алар ничек кирәк алай үтәсе юлның ахырына кадәр барып җиттеләр, бауның очын бәйләп куйдылар да ары киттеләр. Берничә адым атлауга инде чыганак янына җиткәннәр иде. Том башыннан аягына хәтле калтырануын тойды. Ул Һакка стена буендагы кызыл балчык йомарламына ябышкан филтәне күрсәтте, филтәнең бер кабынып, бер сүнеп барган ялкынын күзәтүләре хакында сөйләп бирде.

Малайлар хәзер пышылдап кына сөйләшә башладылар, чөнки тынлык һәм мәгарәнең караңгылыгы аларның күңелен җәберли иде.

Икенче коридорга һәм упкынга кадәр барып җиткәнче алар һаман алга атладылар.

Том пышылдап кына:

— Хәзер мин сиңа бер нәрсә күрсәтәм, Һак,— диде.

Ул шәмен югары күтәрде.

— Почмак артынарак карарга тырыш. Күрәсеңме? Әнә тегендә, олы ташта, шәм сөреме белән билгеләнгән.

— Соң бу бит тәре!

— Ә икенче номерың кайда соң синең? Тәре астында, шулай бит? Нәкъ менә шушында күрдем дә инде мин индеец Джоны шәм тоткан килеш!

Һак озак кына итеп серле тамгага карап торды да калтыранган тавыш белән болай диде:

— Том, әйдә булмаса китик кенә моннан!

— Шулайдыр! Хәзинәне ташлапмы?

— Әйе. Индеец Джоның рухы шушы тирәдә генәдер ул.

— Юк, Һак, бу тирәдә түгел, бөтенләй дә монда түгел. Индеец Джо үлгән урында ул мәгарәгә керә торган җирдә, моннан биш миль ераклыкта.

— Бер дә түгел. Ул шушы тирәдә, акча тирәсендә. Минме инде белмим рухларның гадәтен, синең үзеңә дә мәгълүм бит ул.

Әллә дусты хаклы микән дип Том курка ук башлады. Нииндидер яманлык сизү аның күңелен рәнҗетте. Шунда кинәт аның башына бер фикер килде.

— Кара әле, Һак, ахмаклар да инде без синең белән. Индеец Джоның рухы тәре булган җиргә киләмени инде?

Дәлил бик нигезле иде. Ул Һакны да ышандырды.

— Мин уйламаганмын да, Том. Чыннан да, дөрес бит, монда тәренең булуы безнең файдага гына. Хәзер без төшәрбез дә сандыкны эзләп карарбыз, дип уйлыйм мин.

Кызыл балчыклы ярда баскыч ясый-ясый Том беренче булып төшә башлады. Аның артыннан Һак кузгалды. Олы таш ятып торган кечкенә мәгарәдән дүрт якка дүрт юл китә иде. Малайлар юлның өчесен тикшереп карадылар, ләкин берни дә тапмадылар. Ташның

нигезенә якынрак яткан юлда алар тирән булмаган уемтык күреп алдылар, шунда җиргә одеял җәелгән, бер иске подтяжка, дуңгыз тиресе, чиста итеп кимерелгән ике-өч тавык сөяге ята. Әмма ләкин монда сандык юк иде. Алар эзләделәр дә эзләделәр, тик юкка гына тырышканнар икән.

— Тәре астында диган иде бит ул,— диде Том.— Бу бит тәрегә иң якын урын. Ташның астында ук була алмый, чөнки ул җиргә тирән батып утырган.

— Алар бөтен җирне тагын бер кат күздән кичерделәр, аннары алҗып ял итәргә утырдылар. Һак берни дә уйлап таба алмады. Кинәт Том болай диде:

— Кара әле, Һак, ташның бер ягында эзләр дә бар, җиргә шәм майлары да тамган, калган өч ягында исә берни дә юк. Нишләп алай икән, син ничек уйлыйсың? Минемчә, акча таш астында булыр. Хәзер мин кызыл балчыкны казырга тотынам.

Һак җанлана төште.

— Моны син әйбәт уйлап таптың,— диде ул.

Том шундук Барлоу фирмасы чыгарган пәкесен эшкә җикте һәм, барлы-юклы дүрт дюйм казып төшүгә пычагы ниндидер каты әйбергә төртелде.

— Йә, Һак, ишетәсеңме?

Һак та куллары белән балчыкны казый башлады. Тиздән такталар күренде, аларны тартып чыгардылар. Таш астына таба сузылып кереп киткән киң, тирән ярык күренде. Том шул ярыкка төште дә шәмен мөмкин кадәр алгарак сузды, шулай да ярыкның икенче башын күрә алмады. Аннары арырак бармакчы булды, иелеп таш астына керә башлады; тар гына юл аска таба төшә иде. Том башта уңга таба борылды, аннары сулга, Һак та калышмыйча аның артыннан барды. Тагын бер кыска гына борылыштан соң Том кычкырып җибәрде:

— Йа Хода, карале монда, Һак!

Аларның каршында әлеге акча сандыгы ята иде, ул җыйнак кына бер куыш эченә куелган; шунда ук ядрәдән бушаган мичкә, күн тышлык эчендә ике мылтык, икеме, өчме пар иске мокасин, бер каеш һәм

стеналардан тамган тамчылар чылатып бетергән башка төрле иске-москы бар иде.

— Ниһаять, килеп җиттек! — диде Һак, ул инде карала төшкән вак акчаларны актара да башлаган иде.— Хәзер без синең белән байлар, Том,— диде ул.

— Һак, мин гел бу акчалар безнең кулга керер дип уйлый идем. Ышанасы да килми хәтта, ләкин бит кулыбызга керде инде! Менә нәрсә, монда актарынып торасы юк, әйдә чыгыйк. Яле, карыйм әле, күтәрә алам микән сандыкны.

Сандыкның авырлыгы илле кадак чамасы иде. Күтәрүен-күтәрде Том, ләкин аны кая да булса илтү, күчерү бик авыр һәм уңайсыз булыр иде.

— Шулай булыр дип уйлаган идем аны,— диде Том.— Өрәкле өйдән алып чыгып барганда аларның авыр итеп күтәргәннәре күренеп тора иде шул. Искәргән идем мин аны. Ярый әле капчыклар алып килергә онытмаганмын.

Акчаларны капчыкларга бушатып, малайлар аны тәре турындагы таш янына таба алып киттеләр.

— Әйдә, мылтыкларын да, бүтән нәрсәләрен дә алыйк,— диде Һак.

— Юк, Һак, аларын шушында калдырыйк, юлбасарлыкка чыккач кирәк булачак әле алар безгә. Әйберләрне без шушында саклый торган итәрбез һәм оргияләрне дә шушында уздырырбыз. Аның өчен монда бик кулай урын.

— Нәрсә соң ул «оргия»?

— Мин каян белим. Тик юлбасарларның һәрвакыт оргияләре була, димәк, безгә дә шулай кирәк. Әйдә, китик инде, Һак, югыйсә һаман шушында утырабыз.

— Сөндыр инде хәзер. Ашыйсы да килә. Көймәгә әйләнеп кайтыйк та шунда тамак ялгарбыз, тәмәке дә төрербез.

Озакламый алар ирекккә, сарылач куаклары арасына килеп чыктылар, иплэп кенә тирә-юньнәрен караштырдылар, кеше-фәлән юк икәнен күргәч көймәләренә кереп утырдылар да, тамак ялгап, чилем тартырга тотындылар. Кояш көнбатышка авыша башлагач

алар көймәләрен яр буеннан этеп алып киттеләр һәм кайту ягына таба ишә башладылар. Том караңгылы-яктылыда һаман яр буена якын торырга тырышып ишә, үзе күңелле итеп Һак белән гәп куертты, ә инде караңгы төшүгә көймәсен яр буена китереп туктатты.

— Менә нәрсә, Һак,— диде Том,— акчаларны без Дуглас ханымның печәнлегенә яшереп куярбыз, ә инде иртә белән мин килгәч без аларны санарбыз да бүләрбез. Аннары урманда кеше тапмаслык җиргә яшерербез. Син шушында саклап тор, мин йөгереп кенә Бенни Тэйлорның арбасын алып киләм; эһ дигәнче килеп җитәм мин.

Ул юкка да чыкты һәм, озак та тормый, арбаны тартып килеп җитте; ике капчыкны шунда салып өстен иске-москы белән капладылар да арбаны өстерәп алып китте. Валлий картының өе турына килеп җиткәч малайлар хәл җыярга туктадылар. Кузгалып китмәкче генә булганнар иде, баскычка карт үзе килеп чыкты да:

— Әй, кем бар анда? — дип кычкырды.

— Һак Финн белән Том Сойер!

— Бик шәп! Әйдәгез, балалар, бөтен кеше сезне генә көтеп тора. Ягез, әйдәгез алдан барыгыз, арбагызны үзем өстерәрмен. Иллә дә мәгәр авыр икән үзе. Нәрсә соң ул сезнең монда? Кирпечме, әллә тимер-томырмы?

— Тимер-томыр.

— Шулайдыр дип уйлаган идем аны. Безнең калада бөтен малай-шалай көчен кызганмыйча тимер-томыр җыярга әзер, шуның өчен аларга заводта тиеннәр генә бирәләр инде югыйсә. Ә шуннан ике өлеш артык түләсәләр дә, чынлап эшләргә риза түгелләр. Ягез, тизрәк кыймылдагыз.

Малайларның ни өчен ашыгырга кирәк икәнен беләселәре килә иде.

— Борчылмагыз, тиздән белерсез, менә Дуглас ханым өенә генә барып җитик.

Һак шомланыбрак болай диде (ул инде күптән төрле нахак бәла ягуларга күнеккән иде):

— Джонс әфәнде, без бит ярамаган берни дә эшләмәдек.

Валлий карты көлеп җибәрде:

— Белмим инде, Һак улым. Белмим. Әллә ханым сиңа начар карыймы?

— Юк. Ул миңа яхшы карый, анысы дөрес.

— Шулай булгач, эш нәрсәдә соң? Нидән куркырга?

Һак әле бу мәсьәләне чишәргә өлгерә алмады, аның башы әкрен эшли иде, ул арада инде Том белән аларның икесен бергә Дуглас ханымның кунак бүлмәсенә төрткәләп керттеләр. Арбаны тышта калдырып, Джонс әфәнде дә алар артыннан керде. Кунак бүлмәсендәге утлар гөлт иткән һәм анда каланың бөтен күренекле кешеләре җыелган иде. Тэтчерлар да, Һарперлар, Роджерслар, Полли түткәй, Сид, Мэри, пастор, җирле гәзит мөхәррире һәм башка бик күпләр шунда һәм барысы да бәйрәмчә матур итеп киенгән иде. Баштанаяк кызыл балчыкка һәм эрегән шәм тамчыларына буялып беткән кешеләрне ни дәрәҗәдә якты чырай белән каршыларга мөмкин булса, Дуглас ханым малайларны шулай каршылады. Полли түткәй оятыннан бурлат кебек кызарды, ачуланып кашларын җыерды да башын чайкап куйды. Шулай да, малайлар үзләрен башка кунакларга караганда уңайсызрак хис иттеләр. Джонс әфәнде болай диде:

— Том өенә дә кайтып җитмәгән иде әле, мин инде аны тапмам дип тә уйлаган идем, аннары аларны үземнең ишек төбемдә очраттым да шундук монда алып килдем.

— Бик яхшы иткәнсез,— диде ханым.— Балалар, әйдәгез минем белән.

Ул аларны йокы бүлмәсенә алып чыкты.

— Хәзер юыныгыз да өс-башыгызны алышыгыз,— диде ул аларга.— Менә сезгә ике пар яңа костюм, күлмәк, оекбашлар. Кирәкле нәрсәләр барысы да бар. Менә монысы Һакка дигән костюм. Юк, син рәхмәт әйтмә, Һак. Берсен Джонс әфәнде сатып алды, икенчесен — мин. Алар сезнең икегезгә дә таман булырга тиеш. Киенегез әйдә. Без сезне көтеп торабыз. Киенеп-ясаныгыз да безнең янга чыгыгыз.

Шулай диде дә ханым чыгып китте.

XXXV бүлек

— Том, табып булса, тәрәзәдән аркан буйлап төшәргә мөмкин. Тәрәзә бик биек түгел бит,— диде Һак.

— Юкны, нишләп әле тәрәзәдән төшәргә?

— Соң мин бит мондый компаниягә күнекмәгән. Чыдый алмам мин анда. Мин анда барыбер кермим, белеп тор!

— Юкны сөйләмә! Мин тамчы да курыкмыйм. Син дә курыкма. Мин бит синең белән бергә булам.

Ул арада малайлар янына Сид килеп керде.

— Том, түткәй көн буе сине көтте,— диде ул.— Мэри синең якшәмбе костюмыңны әзерләп куйды, гел синең өчен борчылып торды. Карагыз әле, нишләп ул сезнең өс-башыгыз кызыл балчыкка буялып беткән?

— Менә нәрсә, әфәндем, кеше эшенә тыгыласы булма. Нинди мәҗлес ул монда, син безгә шуны әйт, иң әйбәте шул булыр.

— Гадәттәгечә, ханым кичке аш җыя. Бүген — уллары белән бергә теге вакытта ханымны коткарып калган Валлий карты шәрәфенә; телисең икән, мин сиңа тагын бер нәрсә турында сөйлим.

— Йә, нәрсә турында?

— Менә нәрсә: Джонс әфәнде бүген кич белән бөтен кешене шаккатырмакчы була. Мин аның сер итеп кенә Полли түткәйгә сөйләгәнен ишетеп тордым. Хәзер ул сер дә түгел инде. Хәзер инде бөтен кеше белә. Белмәмешкә сабышса да, ханым үзе дә белә. Шуңа күрә Джонс әфәнде Һакның тәгаен монда булуын тели, чөнки Һактан башка аларның эшләре пешми, аңлыйсыңмы?

— Нинди сер ул, ни турында?

— Һак турында, бандитларның эзенә ул төшкән бит. Джонс әфәнде кӨтелмәгән хәбәре белән бӨтен кешене шаккатырам дип уйлый. Ә минемчә, берәүнең дә исе китмәячәк.

Сид сӨенеченнән хихылдап куйды.

— Сид, шуны бӨтен кешегә дә син әйттеңме?

— Кем әйтсә дә барыбер түгелмени? Беләләрме — беләләр!

— Сид, бӨтен калада шушындый кабахәтлекне бер генә кеше эшли ала, ул кеше — син! Әгәр дә Һак урынында син булсаң, шундук таудан тәгәрәп тӨшеп үкчәңне ялтыраткан булыр идең. Бандитларны күрүең турында берәүгә дә авызыңны ачмас идең. Син этлек кенә эшли аласың бит! Берәр яхшылыгы Өчен бүтән берәүне мактасалар, син аны күралмыйсың. Тиешлесен ал менә, рәхмәтеңнең кирәге юк, әйтеп торма!

Сидның колагыннан тотып артына типте дә Том аны бүлмәдән чыгарып җибәрде.

— Курыкмасаң, бар, Полли түткәйгә әләкләш, анысы Өчен үзеңә иртәгә тагы эләгер.

Берничә минуттан инде Дуглас ханымның кунаклары Өстәл янына утырышып тәмле итеп сыйланалар иде. Ул еллардагы һәм ул вакыттагы гадәт буенча балаларга бер читкә аерым Өстәл куйдылар. Вакыты җиткәч Джонс әфәнде кыска гына нотыгында аның үзенә һәм улларына шундый хӨрмәт күрсәткәне Өчен Дуглас ханымга рәхмәт әйтте һәм тантаналы рәвештә мәҗлестәгеләргә бик тыйнак тагын бер кеше барлыгын белдерде...

Һәм башкалар, вә башкалар. Аннары үзенә хас драматик осталык белән Һакның әлеге вакыйгалардагы катнашы турындагы серне ачты, әмма ул кешеләрне бик шаккатыра алмады, башка шартларда моның тәэсире болай гына булмас иде. Шуңа карамастан, Дуглас ханым бик табигый итеп гаҗәпләнүен белдерде һәм Һакка шулхәтле күп җылы сүзләр, рәхмәтләр әйтте, хәтта ки малай яңа костюм китергән түзеп булмаслык газапларын да онытты, чӨнки гомуми игътибарга һәм мактауларга бӨтенләй дә чыдарлык түгел иде.

Дуглас ханым Һакны тәрбиягә алырга теләвен әйтте, акча яклары рәтләнгәч, аңа берәр төрле эш башларга ярдәм итәсе булды. Шунда инде Томга да чират җитте:

— Һак аңа мохтаҗ түгел, ул үзе дә бай,— диде ул.

Кеше арасында үзеңне ничек тотарга кирәген истә тотканга күрә кунаклар бу үткен шаяртуны хуплап көлми калдылар. Әмма тынлык шактый ук уңайсыз килеп чыкты. Тынлыкны беренче булып Том бозды:

— Һакның акчасы бар. Сез бәлки ышанмассыз да, әмма аның акчасы күп. Көләсе юк, мин аны сезгә күрсәтә дә алам. Бер генә минут сабыр итегез.

Том ишектән чыгып югалды. Бар кунаклар да каушап һәм кызыксынып бер-берсенә караштылар, сораулы күзләрен Һакка төбәделәр. Малай исә берәгәйле телдән калды.

— Томга ни булган ул, Сид? — дип сорады Полли түткәй.— Ул... хәер, аннан ни көтәргә дә белмәссең. Бу малай белән бервакытта да...

Шул арада капчык авырлыгыннан сыгылып Том килеп керде. Полли түткәй сүзен әйтеп бетерергә дә өлгерми калды. Том алтын тәңкәләрне шыбырдатып өстәл өстенә койды.

— Менә, әйттемме мин сезгә?! Яртысы — Һакныкы, яртысы — минеке,— диде ул.

Бу күренештән кунакларның тыннары кысылды. Алар алтынга карап шаккаттылар, сүзләрен әйтә алмый тордылар. Аннары җыенысы берьюлы аңлатма таләп итәргә тотындылар. Хәзер барысын да аңлатып бирәм, диде Том һәм сөйләп китте. Хикәя бик озын, ләкин бик мавыктыргыч булды. Барысы да хәйран калып тыңлап утырдылар, берәү дә сүз кыстырырга кыймады. Хикәя тәмам булгач Джонс әфәнде болай диде:

— Мин тагы сезнең өчен бик шәп сюрприз әзерләп куйдым дип уйлаган идем, әмма ул бер тиенгә дә тормый икән. Моның белән чагыштырганда минем сюрприз — юк нәрсә икән.

Акчаны саный башладылар. Унике мең доллардан бераз гына күбрәк булып чыкты. Кайбер кунакларның моннан күбрәк капиталлары булса да, монда утыручы кешеләрнең берсенә дә берьюлы шушы хәтле күп акча күрергә туры килгәне юк иде.

XXXVI бүлек

Сент-Питерсберг дигән бәләкәй генә бу шәһәрчектә Том белән Һакның табылдыгы кешеләр аңында зур чуалыш китереп чыгаруына укучым шикләнмәсен. Шундый зур сумма — үзе саф акчалата — гаҗәп хәл бит! Ул турыда кешеләр өзлексез сөйләделәр, аннан көнләштеләр, исләре китте, кайберәүләрнең хәтта дулкынланудан аңнары чуалды. Шәһәрдә һәм тирә-юньдәге авылларда «җен-пәриләр» бар дип исәпләнгән бөтен йортларны нигезенә хәтле берәмтекләп сүтеп бетерделәр, хәзинә эзләп алар астындагы җир дә казылып бетте, ә эшне хыялый малайлар түгел, шактый гына төпле, җитди дип исәпләнгән кешеләр эшләде. Том белән Һак кая гына бармасын, аларга илтифат иттеләр, аларга сокландылар, авыз ачып карап тордылар. Элек аларның сүзенә игътибар итүчеләрнең булуын малайлар бөтенләй хәтерләми, ә хәзер кешеләр аларның һәр сүзен эләктереп алып, һәр сүзен җөпли иде; алар ни эшләмәсен — барысы да менә дигән булып чыга; алар, күрәсең, гади кешеләр кебек хәрәкәт итү һәм сөйләшү сәләтен югалтканнар иде; алай гына да түгел, аларның үткән гомерләрен казып чыгарганнар — анда да, имештер, оригиналь һәм талантлы булу өчен бөтен шартлары булган. Шәһәр гәзите аларның тәрҗемәи хәлен бастырып чыгарды.

Дуглас ханым Һакның акчасын банкка салды, Полли түткәйнең үтенече буенча судья Тэтчер да Томның акчасын банкка салды. Малайларның һәрберсенең хәзер бик зур килере бар иде — көн саен берәр доллар, якшәмбе көннәрендә исә — яртышар доллар. Хәтта пастор

да кулына аның кадәр акча ала алмый иде. Рәхәт чаклар иде ул — атнасына бер доллар да чирек бәрабәренә малай, тамагын да туйдырып, фатирда да тора ала иде, шуның исәбенә укый да, киенә дә, өстәвенә,чәч алдырып, мунча да керә ала иде.

Судья Тэтчерның Том Сойер турындагы фикере бик югары иде. Гади малай булса, аның кызын мәгарәдән алып чыга алмас иде, ди ул. Бекки, сер итеп кенә, мәктәптә аның аркасында Томны ярганнарын әтисенә сөйләгәч, судья шактый нык тәэсирләнде; аннары Томның Беккины кыйнаудан коткару өчен ялганлашканын акларга маташкач, судья бик нык хисләнеп Томның бу ялганлашуы эчкерсез, күркәм, изге ялган булган, ул Георг Вашингтонның балта мәсьәләсендәге мактаулы хакыйкате белән бер рәттә торып, тарих битләре буйлап шуның белән янәшә атларга лаеклы дип әйтте! Әтисенең әле бервакытта да, келәм буйлап атлап йөри-йөри, бу сүзләрне әйткәндәге сыман эре кыяфәтле, тәэсирле булганы юк иде, дип уйлады Бекки. Кыз шундук йөгереп барып барысын да Томга сөйләп бирде.

Судья Тэтчер Томны кайчан да булса бөек закон чыгаручы яисә бөек полководец итеп күрергә өметләнде. Том Милли хәрби академиягә эләксен өчен, аннары юридик фәннәрне илнең иң яхшы уку йортында өйрәнсен өчен һәм, шулай итеп, бу профессияләрнең берәрсенә яисә икесенә дә берьюлы әзерләнсен өчен судья бөтен көчен куячагын әйтте.

Һаклберри Финның байлыгы, ә бәлки, аның Дуглас ханым тәрбиясендә булуы, малайны җәмгыять эченә алып, юк, түгел, өстерәп, этәреп алып керде, һәм шуның аркасында Һак чутсыз газаплар чигә иде. Ханымның асраулары аны киендерделәр, юындырдылар, чәчләрен сыпыргалап-тарадылар, җирәнгеч дәрәҗәдә чиста җәймәләр җәеп йокларга салдылар; ул җәймәләрдә, иске дустын кыскан кебек, Һак йөрәгенә кысып сөярдәй бер генә тап әсәре дә юк иде ичмасам. Ашаганда тәлинкәдән ашарга, кулга чәнечке-пычак тотарга, авызыңны тастымал белән сөртергә, чәйне чәшкедән эчәргә; китаптан дәрес укырга, чиркәүгә йөрергә; шундый да итагатьле итеп сөйләшергә кирәк иде ки, хәтта малай сөйләшүнең тәмен югалтты; кая таба

гына борылма — бөтен җирдә цивилизация рәшәткәләре һәм богаулары аны ирегеннән мәхрүм итеп, кул-аягын бәйләп тора иде.

Өч атна буена бу кыенлыкларга ул батырларча түзде, аннары инде көннәрнең берендә сабырын югалтып чыгып качты. Бик нык борчылып, ханым аны ике тәүлек буена бөтен җирдән эзләде. Барысы да эзләштеләр малайны, эзләмәгән җирләре калмады, үле гәүдәсен табып булмасмы дип, хәтта елгага җәтмә салдылар. Өченче көнне иртән Том Сойер, иске бойня артындагы буш мичкәләргә тыгылып карарга уйлады, һәм шуларның берсеннән ул качкынны табып алды. Һак төнен шунда уздырган иде; ул инде азык-төлек затыннан кайбер нәрсәләр чәлеп иртәнге ашны да ашарга өлгергән, хәзер инде җәелеп ятып трубкасын төтәтә иде. Ул юынмаган, чәче-башы таралмаган, өс-башына да элекке ирекле, рәхәт чакларда киеп йөргән сәләмәләрен кигән. Том аны мичкәдән сөйрәп алды, күпме мәшәкать ясаганын сөйләп бирде һәм аның өйгә кайтуын таләп итте. Һакның тыныч һәм канәгать чырае шундук караңгыланып чыкты.

— Әйтеп тә торма, Том,— диде ул.— Мин инде тырышып карадым, булмый бит, булмый. Боларның берсенең дә миңа кирәге юк, мин андыйга өйрәнмәгән. Ханым бик ягымлы, рәнҗетми, тик аның тәртипләре минем өчен түгел. Көн саен иртән бер үк вакытта торырга, юынырга куша, чәчләремне тарый, инде бөтен чәчләрем йолкынып бетте, утын сараенда кунарга да рөхсәт юк; аннары тынны кыса торган костюм кияргә куша, аның аша тамчы да һава үтми сыман; үзе шундый чиста, шайтан алгыры, ятарга да, утырырга да, җирдә ятып аунарга да ярамый; ә баз өстеннән шуып төшмәгәнемә йөз еллап бардыр инде! Өстәвенә чиркәүгә йөр, анда тирләп-пешеп басып тор — ул вәгазьләрне җенем сөйми минем! Чебен-черки тотма, берәү белән дә сөйләшмә, җитмәсә, якшәмбе көннең көн буена салмыйча аягыңа киеп йөр! Ханым төшке ашын да кыңгырау шылтыратып кына ашый, йокларга ятуы да, торуы да тәртип белән генә — шуңа кеше ничек түзсен ди!

— Соң бит башкалар да шулай яши инде, Һак!

— Анысында минем бер эшем дә юк, Том. Мин башкалар түгел, мин бу хәлгә түзә алмыйм. Аркан белән арканлаган кебек. Азыгы да

инде бигрәк җиңел табыла — болай ашавы да кызык түгел. Балык тотарга — рөхсәт сора, коенырга — рөхсәт сора, кая гына барырга теләмә — барысына да рөхсәт сора, шайтан алгыры! Сүгенергә дигәндә инде — авызыңны да ачма, хәтта ки сөйләшәсе дә килми, күңелеңне күрер өчен чардакка менәргә туры килә, югыйсә егыл да үл генә. Тәмәке тартырга ханым рөхсәт итми, акырынырга рөхсәт итми, авызыңны ачып исни алмыйсың, киерелергә, кашынырга дисәң, бигрәк тә кунаклар алдында, анысы тагы юк (бу урында ул аеруча хисләнеп һәм гарьләнеп сүгенеп алды)... ә үзе гел дога укый, хәерсез! Минем әле андыйларны күргәнем юк иде. Гел генә кайгыртып, гел генә мәшәкатьләнеп тор инде! Болай итеп яшисең дә килми башлар. Качарга туры килде шул, Том, берни эшләр хәл юк. Тиздән әнә мәктәп ачылачак, анда да йөрергә кирәк булачак, шулай булгач, чыдый алмадым инде. Беләсеңме, Том, бу байлыкның бернинди яхшылыгын да күрмим, без юкка юньлегә уйлаганбыз. Ә менә бу киемем нәкъ мин дигәнчә, мичкәсе дә гел минем өчен генә, алардан аерыласым килми минем. Әгәр шул акча булмаса, мин бу мәтәвеккә килеп тә эләкми идем, Том. Ал син минем өлешне дә үзеңә, кирәк булганда унар центлап кына биреп торырсың, тик анысын да еш түгел, акчаның бушка килүен яратмыйм мин, аннары син ничек тә булса ханымны үгетләрсең — ачуланмасын инде ул миңа.

— Беләсеңме, Һак, мин моны булдыра алмыйм. Яхшы түгел. Син тагы бераз түзеп кара, бәлки ошап та китәр.

— Ошап китәр! Әйе, утырып кара әзрәк кайнар плитә өстенә, бәлки сиңа да ошар. Юк, Том, моннан ары теләмим мин ул байлыкны, бу каһәр төшкән тынчу өйләрдә яшәргә теләмим. Миңа урман, елга һәм менә шушы мичкә эчендә яшәү ошый, һәм мин шушында калам да! Шайтаныма китсен! Нәкъ менә хәзер, мылтыгыбыз да, мәгарәбез дә булгач, юлбасарлыкка җыенгач кына, кирәк бит шушындый мәгънәсезлек килеп чыгып барын да бозып ташларга!

Том уңайлы моменттан файдаланасы итте:

— Карале, Һак, мин бит баесам да барыбер юлбасарлыкка чыгам.

— Китчәле! Чынлап әйтәсеңме, Том?

— Минем шушы урында утыруым кебек үк чын. Тик беләсеңме, Һак, өс-башың начар булса без сине юлбасарлыкка ала алмабыз шул.

Һакның сөенүләре юкка чыкты.

— Нишләп ала алмыйсыз? Пиратлыкка ничек алган идегез соң?

— Анысы аның бөтенләй башка эш. Юлбасарлар, гомумән, пиратлардан күпкә өстен санала. Алар бөтен илләрдә диярлек бай нәселдән булалар — герцоглардан дисеңме, бүтән башкасыннан дисеңме.

— Том, син гел минем белән дус булдың. Ничек инде, син мине бөтенләй алмассыңмыни? Алырсың бит, Том, әйе бит?

— Алыр идем мин сине, Һак, һичшиксез алыр идем, ләкин бит кешеләр ни әйтер? «Том Сойерның шайкасын карагыз әле, гел йолкышлар гына!» диярләр. Синең турыда булыр ул сүз, Һак. Синең үзеңә үк ошамас ул, миңа да.

Эчтән өзгәләнгән Һак озак кына эндәшми торды. Ниһаять, ул болай диде:

— Ярар алайса, тагын берәр ай яшәп карыйм ханым йортында; әгәр мине шайкага алсагыз, Том, бәлкем ничек тә булса түзәрмен.

— Шулай итсәң яхшы булыр, Һак! Менә ичмасам! Әйдә, сине артык кысмасын дип, мин ханымнан сорап карармын.

— Чынлап та сорыйсыңмы? Менә ичмасам шәп булыр! Тәртипләре белән бик бәйләнмәсә, әкертен генә тәмәке дә тарта алсам, сүгенә дә алсам, ничек тә түзәрмен. Ә син шайкаңны кайчан җыясың, кайчан юлбасарлыкка чыгасың?

— Хәзер үк. Бәлки бүген кич үк җыелырбыз да багышлау үткәрербез.

— Нәрсә үткәрербез дисең?

— Багышлау.

— Нәрсә соң ул?

— Улмы? Барысы да бер-берсенә ярдәм итешергә һәм сине кисәкләргә туракласалар да, шайканың серен ачмаска ант итәләр; шайкабыздагы берәрсенә тия-нитә калсалар, ул кешеләрне һәм аларның туганнарын үтерергә сүз бирәләр.

— Менә кәефләнәбез икән ичмасам!

— Әлбәттә! Төннең нәкъ уртасында ант итәләр; урыны да иң куркыныч, иң кешесез урын булырга тиеш — иң әйбәте «жен-пәриләр» булган өйдә инде, тик аларны хәзер актарып-казып бетерделәр.

— Төн уртасында булуы да бик әйбәт анын, Том.

— Әйбәт булмый ни! Табут өстендә ант итеп, канын белән кул куярга кирәк.

— Менә ичмасам! Пират булуга караганда миллион тапкыр шәбрәк! Дөмегеп китсәм китәрмен, яшим ханымның өендә, Том; әгәренки миннән менә дигән чын юлбасар чыкса, һәм шул турыда кешеләр сөйли башласа, мине үзенә алганына ханым шат булыр, дип уйлыйм мин.



Йомгак

Бу хроника шушының белән тәмам. Әгәр аны тагын да дәвам иттерсәң, ул олы кеше тарихына әйләнәчәк. Олы кешеләр турында роман язсаң, ноктаны кая куясы алдан ук билгеле — аны туйда куясың; ә балалар турында язганда ноктаны уңайлы урында куярга туры килә.

Китапта яшәүче каһарманнарның күбесе әле дә исән һәм алар бүгенгәчә кайгы-хәсрәтсез бәхетле тормышта яши бирәләр. Бәлки авторның китаптагы кечкенә каһарманнарының язмышы белән тагы да шөгыльләнәсе һәм аларданниндирәк кешеләр чыгуын күрәсе килер, шуңа күрә тормышларының ул чоры турында хәзергә сөйләргә кирәкми.



ЭЧТӘЛЕК

Сүз башы 5

I бүлек 7
II бүлек 16
III бүлек 23
IV бүлек 31
V бүлек 43
VI бүлек 50
VII бүлек 63
VIII бүлек 71
IX бүлек 77
X бүлек 85
XI бүлек 95
XII бүлек 101
XIII бүлек 107
XIV бүлек 117
XV бүлек 125
XVI бүлек 131
XVII бүлек 138
XVIII бүлек 143

XIX бүлек 148
XX бүлек 158
XXI бүлек 161
XXII бүлек 167
XXIII бүлек 174
XXIV бүлек 178
XXV бүлек 186
XXVI бүлек 188
XXVII бүлек 197
XXVIII бүлек 207
XXIX бүлек 211
XXX бүлек 215
XXXI бүлек 224
XXXII бүлек 235
XXXIII бүлек 245
XXXIV бүлек 249
XXXV бүлек 260
XXXVI бүлек 263

Йомгак 269

Литературно-художественное издание

Для детей и юношества

Серия «Мировая классика на татарском языке»

Марк Твен

ПРИКЛЮЧЕНИЯ ТОМА СОЙЕРА

Роман

(перевод с английского на татарский язык)

Редакторы *Н. М. Вәлитова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Л. М. Тилк*
Корректорлары *А. М. Закирова, Г. Р. Мифтахова*

Нәшриятка 183 нче номерлы лицензия 1997 елның 7 апрелендә бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.02.03. Форматы $70 \times 90^{1}/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Корина» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 19,89 + форз. 0,29.
Нәшер-хисап табагы 13,08 + форз.0,49.
Тиражы 2000 д. Заказ Я-2.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.


Бөек пират
Томас Сойерның
хәзиналәр картасы
N
W
Z
O